Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

09
сентябрь 2018
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ЛОТФУЛЛА ФӘТТАХОВ «ИГЕННӘР ӨЛГЕРДЕ».

Фото shaimiev.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Милли сәясәт һәм каләм

16-18 августта Казан шәһәрендә VII милли һәм төбәк гаммәви мәгълүмат чаралары форумы узды. Анда Россиянең 19 төбәгеннән килгән 200дән артык делегат катнашты. Форумны оештыручы – РФ Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык ярдәме белән «ТАТМЕДИА» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

09 (297)

сентябрь 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

116

50 **ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ЛӘҺСТАНДА.**
Ләйсән Галиева

90 **ШАГЫЙРЬНЕҢ СОҢГЫ МУЗАСЫ.**
Сәмига Сәүбанова

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Илдар Юзеев**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Гәүһәршад.** *О.Иванова*
8 **Казан ханлыгының язмышы.** *Б.Хәмидуллин*
13 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**
14 **Татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре.** *Х.Габидуллин*
18 **Эчкен татарлары.** *Р.Исакаев*
22 **Ольга апа бәете.** *Ф.Хисамиева*
25 **Японияне ачкан татар галиме.** *Ф.Бәйрәмова*
30 **Терелэй күмелгән эшкуар һәм имам-хатыйп Хәбибрахман Арсаев.** *Г.Ризванов*
35 **Риза казый нәселе.** *Р.Шаһиев*
41 **Бүре кыйссасы.** *Р.Хәбибулла*
44 **Әхмәт бай.** *Р.Фәхреддин*

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

50 **Гаяз Исхакый Ләһстанда.** *Л.Галиева*
54 **1931 елгы мөселман конгрессы.** *Г.Исхакый*

ТАТАР ГАМЕ

57 **Галим Рөстәм Үтәмешев.** *Р.Мәһдиев*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

62 **Чуашлар.** *З.Бәшири*

ДИНИ МИРАС

69 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

72 **Әдәбиятыбыз күгендә якты йолдыз булды.** *А.Хәсәнов*
77 **Әбрар Кәримуллин хатлары**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89520365448

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

80 **Абдулла Алиш**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

82 **Батыр йөрәкле Зәйнәп.** *И.Салихҗан*
90 **Шагыйрьнең соңгы музасы.** *С.Сәүбанова*
99 **Истә, һаман да истә!**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

100 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

102 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
108 **«Мулла чишмәсе»**
112 **Киез итекләр иле**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Сентябрь*

Заказ №Е-2204. Тираж – 2050 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.08.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иреклe.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Игеннәр өлгерде».
Лотфулла Фәттахов рәсеме

Безнең мирас №9 сентябрь 2018



Илдар Юзеев (03.01.1933-21.12.2004)

ТУКАЙ ТЕЛЕ

Җиде бабамнар көйләгән шигырь һәм дога теле,
Мөхәммәтгариф мулла һәм Бибимәмдүдә теле.
Юк, түгел бу – читтән килгән килмешәк – нәнкә теле,
Бу – татарның җаны иңгән әткә һәм әнкә теле.
Безне олуг милләт иткән гадәт һәм йола теле,
«Әнкәй» дигән сүзне көткән Бибимәмдүдә теле.
Бу сүзем – шагыйрь әткәсе – изге бер мулла теле,
Бибимәмдүдә баласы – Апуш – Абдулла теле.
Җиһанда аз яшәп киткән Мөхәммәтгариф теле,
Гасырларны иңләп үткән шигърият, тарих теле.
Көзге җилләрне елаткан Мөхәмәтгариф теле,
Мәктәп баласын җырлаткан фән һәм мәгариф теле.
Туган тел аша ачылды читтәге дөнья теле,
Анда дуслар бик аз иде, инде бар дөнья тулы.
Милләтнең теле яшәсә, сау булыр дәүләт, иле.
Һәр бала сөйсә Тукайча үз телен, туган телен,
Тукай теле, татар теле булыр гел исән, тере!

2000 ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Гәүһәршад

Ольга Иванова

Гәүһәршад атын куалады да куалады. Шундый итеп җилдерде ки, артыннан тузан давылы өермә булып күтәрелде, хәтта аны саклап артыннан чабучы нугайларның да тыны кысылды. Якты чырайлы Казан капкалары кояшка каршы тутырып ачылган иде. Коры канау аша салынган агач күпердән әнә бер өркәчле дөя зур гына бүрәнә өемен тартып чыгып килә. Гәүһәршад аның яныннан, камчысы белән ялкау гына селтәнеп малкайны әйдәкләп баручы бәндәне чак кына аягыннан екмыйча, уктай атылып шәһәргә кереп китте. Әйдәкче, ачуланып, нидер кычкырды, куллары белән селтәнеп, үзе бер читкә сикереп өлгерде. Дөянең дәү өркәче артыннан хуҗабикәләре эзеннән очып килгән нугай җайдакларына аның куркынган күзләре генә карап калды. Агач күпердән ат тояклары шакылдап үтте, бөтен якка күбек чәчеп ыржайган ат танаулары белән озын куе яллары гына яшен яшьнәгәндәй җәлт итеп узып китте – һәм шуның белән дөнья тынып калды, җайдаклар шунда ук юкка да чыкты: әйтерсең лә күзгә генә күренеп алдылар.

Гәүһәршад хан ишегалдында атыннан сикереп төште дә, йөгереп килгән ат караучыга тезгенен ташлап, биек баскычлар, очсыз-кырыйсыз заллар тезмәсе аша йөгереп менде. Мәгәр зәңгәрсу нәфис пыяла бизәкләре, яшел нәкышләре уртасында мәрмәр фонтаннары атып торган зиннәтле заллар буш, аларда кеше әсәре юк иде. Ханның ал бүлмәсе дә тынлыкка чумган. Гәүһәршадның җиленнән йокымсырап утырган каравылчы дерт итеп уянып, телсез кебек, бакчага таба ишарәләп кенә күрсәтергә өлгерде. Гәүһәршад эчке ишегалдыннан ашыгып шунда таба узды һәм быел соңга калып килгән язда аеруча гөрләп чәчәк аткан агачлар күләгәсендә туктап калды. Ком сибелгән сукмаклар буйлап купшы киенгән түрәләр, ханның үз кешеләре мыштырдап кына килеп яталар иде. Сарай акылбашлары, йолдызсанарлар һәм дә шагыйрьләр, җайлы гына утырып, ни турындадыр гәп куерталар. Аларның каләмнәре, әңгәмәдәшләренең чираттагы акыллы сүзен кәгазьгә төшерергә ашыгып, шыгыр-шыгыр килә. Гәүһәршад һичкем янында тоткарланып тормады, үзенә баш иеп, сәламләп калучыларга да җавап бирмичә, алга таба ашыкты. Мөхәммәдәминне тизрәк күрергә ашкынып, аны – ханның күз явын алырдай сеңлесен беркайчан бу кадәр чәче-башы тузгыган хәлдә күрмәгән сарай әһленең аптырашлы карашларын да абайламады. Бер чаттан борылганда, Гәүһәршад вәкарь белән килеп баручы тавислар көтүен өркетте. Матур ачык зәңгәр бүрекле ата тавис куркудан сузып кычкырды да, купшы койрыгын да җыеп алырга онытып, яшь үлән өстеннән чабып китте. Күрексез генә ана кошлар, һәрвакыт тынлык, уйчанлык хөкем сөргән бакчадагы бу мәхшәрдән качарга ашыгып, аның артыннан йөгерделәр. Күрше сукмакта пәйда булган абыйсын күреп кенә, Гәүһәршад үзен туктарга мәҗбүр итте. Сулышын

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

«Мөхәммәдәмин хан». Рәссам Н.Фәхретдинова рәсеме

тыеп, өстендәге япмасын төзәтте, кинәт каушап, уңайсызланып, ат тире аңкып торган тузанлы киемнәреннән оялган төсле булды. Ә Мөхәммәдәмин, кулын бил турысына куеп, Кырымнан бүләк итеп җибәрелгән суганчаларның утлы кызалаклар булып чәчәк атуына соклана-соклана, шул ук сукмактан килә иде. Хаким көтмәгәндә сеңлесен күреп гаҗәпкә калды, аңа кырыс кына, гаепләгән төс беләнрәк сүз катты:

– Сарайга ни йомыш китерде сине, Гәүһәршад? Бер чакыруыма да җавап бирәсең килмичә, кыш буе күзгә күренмәдең ләбаса!

Ханәкә юри әкрен генә башын игән булды, шул арада зиһенен җыеп өлгерде: аның кодрәтле абыйсына чагып әйтәсе сүзләре тел очыннан очып чыгарга гына тора. Тик хатын, тиз генә аларны кеше аңларлык рәвешкә кертеп, Казанга үзен нинди кайнар теләк алып килгәнен аңлатырга тиеш иде. Сүзләр каядыр таралып онытылды, Гәүһәршадның миен бораулаган бер-ике бәйләнчек сорау гына калды: «Әни кайда соң? Нишләп Кырым вәлидәсен күрмим әле?»

Абыйсы хаклы иде: Мөхәммәдәминнең әниләре белән күрешергә кат-кат чакыруына баштарак ачыктан-ачык баш тарткан булса, хаким артык басым ясый башлагач, ул бөтенләй дәшми калу юлын сайлады. Вәлидәгә күптәнге үпкәләре йөрәгендә кайнап, һич тынмады. Гәүһәршад, анасы белән очрашмас, Нурсолтанның ирләр өстеннән аңлатып булмый торган көчен яңадан күрмәс өчен, – ә алар анасы булган җирдә телсез

бүкәнгә әйләнәләр дә куялар иде, – хәтта үз биләмәсеннән качып китте. Гәүһәршадка вакыт ерак Кырымдагы үткәннәрдә туктап калган кебек иде. Еллар узу белән, әнисенең хатын-кыз матурлыгы төссезләнә барасы, ә котылгысыз картлык аның кайчангыдыр җәлеп итү көчен дә суырып аласы кызының башына да килмәде. Ханәкә кышны, әни белән беркайчан да күрешмәм, дигән тулы ышаныч белән уздырды. Әмма ике көн элек Казаннан кайткан идарәчесе, Кырым вәлидәсе Мәскәүгә китәргә җыенып йөри, дип хәбәр биргәч, яшь хатынның күңелендә әллә нинди борылыш булды. Аны алыштырып куйдылармыни: сәгатьләр буе бер ноктага төбәлгән килеш, тулысынча хәрәкәтсез утыра, һичкем белән дә сөйләшәсе килми. Ә бүген таңда күзгә күренмәс нindидер көч ханәкәне яткан урыныннан төртеп торгызган кебек булды. Ул, ат сараена йөгереп барып, яраткан айгырын үзе җикте. Төнге каравыл уяткан тән сакчылары аның артыннан йөгерештеләр. Ә Гәүһәршадның ни сөйләп аңлатырлык, ни боерык бирерлек хәле юк иде, аңлашылмый торган көч, гүя аны канатларына утыртып, Казанга очыртып алып китте. Кызның, әнисенең күкрәгенә капланып, бәхетсез язмышын күз яшьләрен түгеп бушатасы, аның берүзенә генә бу рәхим-шәфкатьсез дөньяда яшәүнең никадәр авыр булуын, ялгызлыктан интегүен танныйсы, кызгандырасы килде. Юлына елгалар ташып чыкса да, күперләр янартау авызына әверелсә дә, аны берни дә туктата алмас иде, барыбер әнисенең тезләренә ятып еларга, аның ягымлы күз карашында юаныч табарга, ана назын тоярга, дип, тыелгысыз алга ашкынды ул.

– Вәлидә Нурсолтанны озатып каласым килгән иде, – дип әйтә алды, ниһаять, ханәкә абыйсына. – Әниебезне күреп каласым килә.

– Ләкин син соңардың, Гәүһәршад. – Мөхәммәдәмин борылды да сукмаклар буйлап кире китте. Хатын, агасының салкын гына әйткән сүзләре нәрсәне аңлатканын ахыргача төшенеп җитмичә, аның артыннан калмыйча бара башлады. Ә йөрәге, дулкынланудан томанланып киткән баш миеннән алдарак, барысын да аңлап алды. Тыелгысыз кайнар күз яшьләре яңаклары буйлап агып төште. «Ул киткән, – дип елады күңеле, – әниемне мин бүтән беркайчан да күрә алмаячакмын! Әйтергә теләгән сүземне аңа һичкайчан әйтә алмаячакмын. Ни өчен ана йөрәге минем газапларымны ишетмәгән дә нишләп соң бердәнбер кызын юатырга ашыкмаган?»

Мөхәммәдәмин, туктап, аңа таба борылды. Сеңлесенең күз яшьләре ханны башта аптырашта калдырды, ә тиздән үзенең дә күңелен кузгатты. Ул, башын чайкап, арган кыяфәт белән:

– Әйдә, ханәкә, минем белән, вәлидә Нурсолтан сиңа нәрсәдер калдырды, – диде.

Гәүһәршад, аңына килеп, хаким артыннан ашыгып атлады. Йөрәгендә өмет чаткысы уянды. Әнисе, мөгаен, аңа хат калдыргандыр, анда җылы сүзләрен, бәлки, васыятен язгандыр, Гәүһәршад ул хатны саклар, төннәр буе кат-кат укып чыгар, яралы җаны белән ярату һәм аңлашу хисләрен җанына сеңдерер. Ал бүлмәгә килеп кергәч, ханәкә, гаҗәеп бүләк көткән нәни кыздай, хәтта күзләрен йомды.

– Ал, Гәүһәршад, – Мөхәммәдәмин сеңлесенең учына бәрхет белән тышланган кап салды.

Ханәкә әкрен генә күзләрен ачты. Кап эчендә кыйммәтле матур алкалар ята иде.

– Ә... хат? – дип, карлыккан тавыш белән сорады Гәүһәршад.

– Хат юк, – дип, бераз гаҗәпсенеп җаваплады Мөхәммәдәмин.

Гәүһәршад көлеп җибәрде, башта әкрен генә, ышанып ук җитмәгән кебек, аннары шашынып кычкыра ук башлады. Ул, алкаларны бер почмакка атып бәрде дә, нәфрәтле карашы белән ханга текәлде:

– Мин аны күралмыйм! Бу хатынны күралмыйм, ул минем тормышымны бушлыкка әйләндерде!

Яңагын ханның кайнар уч төбе көйдереп алды. Гәүһәршад, янган битен каплап, хакимнең җен ачуы чыккан чыраена газаплы күзләрен төбәде:

– Син мине үтерә аласың, абый, әмма мин үз сүземнән беркайчан да кире кайтмаячакмын. Безнең әни – убырлы карчык! Ул мине күралмый, мин дә аңа чиксез нәфрәтем белән җавап кайтарам! А-а, башыма океан зилзиләсе орса да, ул минем нәфрәтемне юа да, сүндерә дә алмас!

– Телеңне тешлә, ханәкә! – Мөхәммәдәмин үкереп елаучы сеңлесенә карап авыр сулый иде. Күңел төпкелендә яшь хатынны кызгану хисе дә көйрәде. Ул ни дип кенә кычкырмасын, тәкәбберлек һәм гарьлектән ни генә әйтмәсен, сизгер йөрәге белән күрә: Гәүһәршад анасын ярата, ләкин бу хисләрен барысыннан да, хәтта үз-үзеннән дә яшерә. Аңарда ана җылысын һәм назын алып бетерә алмаган кечкенә кызчыкның канәгатьсезлеге, һичкайчан яратмаганлыкларын белгән сабый сагышы да бүгенгә хәтле кайнап тора.

– Сиңа хаммамга бару кирәктер, – диде хан, тонык тавыш белән. – Шапшак кыяфәтең, пычрак өс-башың күңелне кайтара, затлы нәселдән чыккан ханәкә.

Хатын авыр итеп, ирләрчә дип әйтерлек көрсенде дә:

– Йә, хаким, миңа чибәр вәлидәгез ташлаган пычракны юарга йөз мунча суы да җитмәс, – диде. – Туган чагымда ук ул миннән йөз чөерде, миңа иң кыйммәтле бирнәне – мәхәббәтен бүләк итәргә онытты.

– Нахак сүзләреңне тыңлап торуы авыр, Гәүһәршад. Безне Ходай үзе хөкем итсен, тәкъдиребезгә ниләр язылганын ул гына белә. Мин сиңа урын-җир әзерләргә кушам, юлдан соң ял итеп ал да кире кайтып кит. Сине якын араларда гына күрәсем килми, күңелең агу белән тулы, нәфрәтеңнән агуланып каласым килми, сеңелкәш. Һәм исеңдә тот, ханәкә, гасырлар буе акыл җыйган зирәк кешеләр тикмәгә генә: «Чиге булмаган усаллыкны эченә җыйган, кычыткан ефәгенә уралган кебек, шуңа чорналган бәндә тиздән үзен иң әшәке дошманы да төртеп төшерә алмаган базга сала!» – дип әйтеп калдырмаганнар. Хуш, сеңелкәш.

Ишек йомшак кына ябылды, ә Гәүһәршад урыныннан кузгалмады да. Йөрәгендә – салкын бушлык, әйтерсең лә яшь хатынга яшәү көче биргән сут тәмам агып беткән шикелле иде. Ул Венеция сәүдәгәрләре бүләк иткән кыйммәтле зур көзгегә таба салмак кына атлады. Көзгедән аңа суырылган чырайлы, күзләре шашынып янган йөз карап тора, чәчләре сарайда, бакчада әнисен эзләп бәргәләнгәндә пумалага әйләнеп чуалган. Нурсолтан аның тормышына бер дә күреп кала алмаслык шәүлә генә булып керде дә, үз артыннан бушлык һәм ачыну ачысын калдырып, мәңгелеккә югалды.

– Хуш, әни, – дип пышылдады кибеп ярылган иреннәр. – Абыйның вәгазе – минем өчен мәгънәсез сүз куерту гына, ул үзен алдап көн күрүче бушбугазлар төркеме белән уратып алган. Аларда акыл ияләрен күрә, ә үз сеңлесенең күңелендә нинди утлар янганын күрми. Ярар, шулай булсын, безнең гамәлләргә Ходай бәя бирсен, ә минем бүтән синең турыда искә төшерәсем килми, әни. Беркайчан да! Сезгә кадерле булган бар нәрсә миңа чит булыр. Мәңгелеккә*...

Дәвамы бар

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе* ■

———————————

*Рус елъязмаларында теркәлеп калганча, Нурсолтан Казаннан Мәскәүгә 1511 елның июнендә китә. Биш айдан артык Юрьевтагы кече улында яши, рус кенәзлегендә булуы Кырым, Мәскәү һәм Казан арасындагы сөйләшүләр белән үрелеп бара.

Казан ханлыгының язмышы

Булат Хәмидуллин

ТАТАР ХАННАРЫ: КИСКЕН МӨНӘСӘБӘТЛӘР, САФАГӘРӘЙНЕҢ КАБАТ ТӘХЕТКӘ КИЛҮЕ

Шул елның 29 июнендә Казан тәхетенә Шаһгалинең энесе, 15 яшьлек Касыйм ханы Җангали (Шәех Аллаһияр ханның икенче улы) утыртыла. М.Г.Худяков: *«Аның регентшасы Гәүһәршад була»*, – дип язса да, яшь хан үзенчәрәк идарә итә шул. Тәхеткә утыргач та Җангали фәкать Мәскәү кенәзлеге вәкиленең фикерен башкарып кына эш йөртә башлый. Казанда Мәскәүнең гаскәри берәмлеге урнаштырыла. Җирле идарәче бәк-морзалар тәхеттән әкренләп читләштерелә. Казан элеккечә Мәскәү йогынтысына бирелә. Яше җитеп, өйләнер теләге тугач та, бу хан Мәскәү бөек кенәзеннән рөхсәт сорарга мәҗбүр була. Шуннан соң гына Җангали анасының туган ягына – Нугай Урдасына, кыз сорарга, дип, үзенең якыннарын җибәрә. Ул 1533 елда дәүләтнең зур олыс идарәчесе, дәүләт башлыгы булган бәкнең урынбасары Йосыф морза кызы Сөембикәгә өйләнә.

М.Г.Худяков энесе Җангалинең Казан тәхетенә тәкъдим ителүеннән соң, Шаһгали белән бөек кенәз Василий III арасында үзара каршылыклар килеп тууы турында хәбәр итә. Шаһгалинең Казанда ныгып кала алмавын, казанлыларның яңадан аны чакырмауларын истә тотып, бөек кенәз аны бушап калган Касыйм ханлыгы тәхетен биләргә дә җибәрми. Шул җәһәттән Шаһгали нindидер чаралар күрергә керешкәч, 1533 елда бөек кенәз аны гаиләсе белән төньяк тарафка – Белоозеро дигән җиргә сөргенгә олактыра, аның якыннарыннан ике йөзләп кешене төрле тарафлардагы төрмәләргә ябарга дип әмер бирә. Байтак кына әсир ябылуда гүр иясе була. М.Г.Худяков китабында шул чор рус елъязмачысының Тверь төрмәсендә булган хәлләргә нисбәтле сүзләре китерелә: *«Того же года их татарок крестиша, а мужей их удушили в тюрьме – 72 человека... и малых деток 7 в том числе»*. Шаһгалине өч елдан соң, Иван IVнең анасы, регентша Елена Глинская идарә иткән чорда азат итеп, Мәскәүгә кайтаралар.

Р.Фәхреддин мәгълүматлары буенча, 1532 елда тәхеттән куылгач, *«Сафагәрәй хатынын атасына – Мамай морза йортына кайтарып җибәрә... Үзе Кырым вилаятенә – Сәхибгәрәй хан хозурына кайтып китә»*. Хан биредә дә тик ятмый. Сәхибгәрәй хан ярдәме белән ул 1533 елның августында Мәскәү кенәзлегенә һөҗүм оештыра. Р.Фәхреддин: *«Кырым гаскәре Мәскәү өстенә килде... Рязань вилаятен... биш көн эчендә тәмам җиңеп, сугышны тәмам итте»*, – дип яза. Шул ук хезмәттә күренекле рус тарихчысы С.М.Соловьёвның бу яу башында Сафагәрәй белән Исламгәрәй (Мөхәммәдгәрәй хан улы) торганлыгы турындагы фикере теркәлгән. Сафагәрәйнең шуннан соң Василий IIIгә атап язган хатының кыскача эчтәлеге дә Р.Фәхреддиннең әлеге китабының «Сафагәрәй хан» бүлегендә китерелә. Сафагәрәй «үлем көтеп ятмыш» Василий IIIкә: *«Казанда хан булып торганда синең җиреңә кермәдем, усаллык кылмадым. Киресенчә, син һәрвакыт миңа золым итеп тордың вә һәрвакыт өстемә гаскәр җибәрдең, хәтта мине ханлыкны ташлап чыгарга мәҗбүр иттең»,* – дип язган була.

---

*Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында

Шул елның 3 декабрендә кенәз Василий III вафат була. Мәскәү кенәзлеге тәхетенә аның өч яшьлек улы Иван IV утыртыла. (Әнисе ягыннан ул Алтын Урданың көнбатыш олысының бәкләр бәге һәм гаскәр башлыгы булган өлкән Мамай морза нәселеннән.) Кенәзлектә әнисе Елена Глинская, абзасы Михаил Глинский һәм боярлар идарә итә башлый. Рус елъязмаларына нигезләнеп, М.Г.Худяков, бөек кенәзнең үлеменнән файдаланып, Казан түрәләренең Мәскәү дәүләтенең даими басымыннан котылырга карар кылулары турында яза. *«Элек Василий III идарәсе белән тыгыз элемтәдә булган Казан бәк-морзалары да Иван IVтән йөз чөерде»*, – дигән юлларны укыйбыз. Рус елъязмаларында түбәндәге сүзләр дә бар: *«Говгоршад царевна и Булат князь и вся земля Казанская Ивану Васильевичу изменили»*.

Әйе, яуга барган, күрше дәүләтнең фәлән-фәлән шәһәр һәм авылларын талап, яндырып кайткан. Ә ханлыкның төп халкына ул барымта яуларыннан ни файда? Аннан талап алып кайтылган мал бит шул талауга баручылар өчен генә булган диярлек. Ил халкының күпчелегенә ул таланган малдан сукыр бер тиен дә кермәгән.

1535 елның көзендә эшлексез Җангали хан казанлылар тарафыннан үтерелә. Тарихчылар бу вакыйганы ханның Мәскәү таләбе буенча зур гаскәр туплап, аны Литва кенәзлеген яулашырга җибәрүе белән дә бәйлиләр: *«Джан Али посылает свои полки против Литвы, с которою воевала Россия»*, – дип язалар. Казан ханлыгы тәхетенә яңадан Сафагәрәй чакырып китерелә. Кайберәүләр шул елда ук ул яшь ханбикә Сөембикәне чираттагы хатынлыкка ала, дип тә исәплиләр. (Һади Атласиның «Сөенбикә» хезмәтендә ханның аңа кадәр 3 хатыны булуы, шулардан берсенең Әстерхан хан-солтаннары нәселеннән, икенчесенең Нугай Урдасы морзасы Мамай кызы булуы турында әйтелә. Мамай исә Сөембикә атасы Йосыф морзаның бертуганы була.) 1560 нчы елларда Казанда билгесез автор тарафыннан тупланган «Казан тарихы» («Казанская история», «История о Казанском царстве») китабында исә Сафагәрәйнең Сөембикәгә өйләнү вакыйгасы 1546 елда, Казаннан икенче мәртәбә куылгач та ярдәм сорап Йосыф морзага мөрәҗәгать иткәннән соң була, дип күрсәтелә. Уртак уллары Үтәмешгәрәйнең шул елларда туганлыгы да бу хәбәрнең дөреслеккә якын булуын дәлилли. Аңа кадәр Сөембикәнең Җангалидән туган кызы гына була. Тарихчы И.В.Зайцевның Әстерхан ханлыгы тарихына багышланган хезмәтендә ул кызның соңрак Әстерхан ханының бер улына ярәшелгәнлеге әйтеп үтелә. Кияүнең исем-атамалары, Шаһгалинең ул вакыйгада катнашуы теркәлгән хәбәр башка бер чыганакта да бар.

ЯВЫЗ ИВАННЫҢ ТӘХЕТКӘ КИЛҮЕ. СӘХИБГӘРӘЙНЕҢ АҢА ХАТЫ. МӘСКӘҮ-КАЗАН, КАЗАН-МӘСКӘҮ ЯУЛАРЫ

Әйтелгәнчә, 1535 елның көзендә Казан тәхетенә яңадан Сафагәрәй хан кайтарыла. М.Г.Худяков Казанның элек аңа каршы чыккан кайбер аксөякләренең туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булулары хакында яза һәм берничә исемне атап китә.

Шул ук кышта Елена Глинская хөкүмәте, Казан халкыннан үч алу нияте белән, воевода С.Гундоров җитәкчелегендә зур булмаган гаскәр җибәрә. Бу хәбәрне алуга, хан аңа каршы чыга, Сура елгасы тирәләрендә ул гаскәрне кире борып җибәрә һәм аны куа барып, Түбән Новгородка буйсынган биләмәләрне айкап кайта. Шуннан соң ул Мәскәү кенәзлегенең Балахна, Муром һәм Түбән Новгород биләмәләренә һәм шул җирләрдә тупланган гаскәри берәмлекләргә даими рәвештә һөҗүмнәр оештыра башлый. Ул һөҗүмнәр 1537 ел ахырынача дәвам итә. Рус елъязмачылары: *«Аның яуларыннан бигрәк тә Түбән Новгород төбәге авыл һәм шәһәрләре зур зыян күрде»*, – дип язалар. Мәскәү кенәзлегендә исә бу чорда әле хакимият ныгып өлгерми. Шул ук вакытта

кенәзлекнең төп хәрби көчләре Литва кенәзлегенә каршы сугышларга җәлеп ителгән була. Ике тарафта сугыш алып барудан котылу өчен, 1537 ел ахырында Мәскәү Литва кенәзлеге белән биш елга исәпләнгән солых килешүе төзи.

Шуннан соң мәскәүлеләр барлык көчләрне туплап Казанга яуга чыгарга җыенганда гына, 1538 елның мартында Кырым тарафыннан Казан белән солых килешүен төзү кирәклеге турында тәкъдим килә. Кырым ханы Сәхибгәрәй бу сөйләшүләрдә үзенең арадашчы вазыйфасын башкарырга алынуын хәбәр итә. Аның Мәскәүнең бөек кенәзе, җиде яшьлек Иван IV исеменә язган хаты сакланган. Әлбәттә, аның эчтәлеге кенәз исеменнән идарә итүче боярларга атап язылган: *«Без исән чакта Казан ханлыгы җирләре дә безнең җир була. Әгәр шул биләмәгә карата яманлык кылырга ниятләсәң, ике арада тынычлык бетәчәк, дуслык, арадашлык гамәлләренә чик куелачак. Ул вакытта без Мөхәммәдгәрәй хан кебек синең илдән тиз генә кайтып китмәбез, ул җирдә җәйне дә, кышны да уздыра башларбыз. Син әле бик яшь, белмисең, ә картраклар атаң белән бабаңның яулары Казанга ничаклы зыян китергәнлеген беләләр. Ул яуларда безнең кешеләр генә түгел, сезнекеләр дә бик күп кырылды бит. Сугышлар һәрчак күпләп кеше үлеменә, ике якның да халкы кимүенә китерә. Атаңнан калган ил хәзер сиңа тапшырылды, кеше язмышлары да хәзер синең кулда. Күрше бисерманнәргә карата да дошманлык кылудан саклан, юкса үзеңә кыенлык килер. Бер-беребез белән тарткалашмыйча, сугышмыйча килешеп яшик. Мондый килешү сиңа да файдага гына булыр. Казан иленә сугыш белән барырга ниятләсәң – үз язмышың, үз киләчәгең турында да уйлан. Минем язганнарымны истә тот»*. Шул хат ахырындарак Кырым ханы «Сафагәрәй кылган золымнарны онып», дип өстәргә дә онытмаган була.

Сәхибгәрәй ханның хатыннан аңлашыла ки: киләчәктә Мәскәү кенәзлеге Казан ханлыгына яу белән барулардан тыелырга, ул җирләрне үзенә буйсынуда тотарга хыялланудан ваз кичәргә тиеш. Югыйсә, Кырым һәрчак Казанга ярдәмгә килергә әзер булачак. Әйе, бу хатта Кырым ханлыгының, Мәскәүне читләштереп, Казан ханлыгын үз йогынтысына алырга ниятләве ачык сизелә. Ә Мәскәү кенәзлеге җитәкчеләренең исә элекке сәясәттән ваз кичәсе килмәгән. Шулай да 1538-1539 елларда күрше ике дәүләт арасында яу-сугышлар булмый әле.

Әмма Казанның үзендә җирле бәкләр һәм кырымлы түрәләр төркемнәре арасы яу кырын хәтерләтә башлаган була. Сафагәрәй көннән-көн җирле бәк-түрәләрне дәүләт белән идарә итү эшеннән читләштереп, алар урынына Кырымнан чакырып китерелгән якташларына өстенлек бирә башлый. Мөгаен, Казан түрәләре тарафыннан бер мәртәбә тәхеттән төшерелгәннән соң, аның күңелендә җирле халыкка карата ышаныч кимегән булгандыр инде.

1539 елның көзендә Сафагәрәй хан, солых килешүләрен өзеп, янә Мәскәү кенәзлеге биләмәләренә яуга чыга. Бу юлы аның гаскәрендә, казанлылардан тыш, Кырым белән Нугай Урдасы гаскәри берәмлекләре дә, башкорт, чуаш, мари, мордва, удмурт халыклары вәкилләре төркемнәре дә катнаша. Бу халыкларның күпчелек ыруглары Олуг Мөхәммәд заманында һәм аның улы Мәхмүд хан идарә иткән дәвердә үк үз теләкләре белән Казан ханлыгы биләмәсенә кушылган булалар. Әлеге яу да, зур сәяси максатны истә тотмыйча, Мәскәү кенәзлегенең чик буе шәһәр һәм авылларына «барымтага бару» белән генә чикләнә.

Дөрес, бу елларда Сафагәрәй хан Мәскәү кенәзлеге белән үзара мөнәсәбәтләрдә хәрби көчкә таянып кына калмыйча, дипломатик алымнар кулланып та үз ханлыгын дошман йогынтысына бирелүдән саклауда кайбер уңышларга ирешә. Ихтимал, Мәскәү кенәзлегенә каршы тору чараларында Нугай Урдасы, Әстерхан белән Кырым ханлыклары ярдәменнән тыш, ул Литва бөек кенәзлегеннән дә ярдәм көткән булса



кирәк. Бу күрше дәүләтләр арасында үзара тарткалашуның тынып тормавын белеп, хат-мөрәҗәгатьләрендә ул үзенең дә Мәскәү кенәзлеге төбәкләренә һөҗүм итү вакыйгаларын тәфсилләп язарга онытмаган. Янәсе, мин дә сезнең дошманыгызга тынгылык бирмим. *«Землю московскую завоевал, замки (города) имшие побрал... »* – дип яза ул бер хатында. Моңа каршы Литва кенәзенең ханга нинди җавап биргәнлеге генә билгесез. Һәрхәлдә, әйдә икебез дә бер үк вакытта ике тарафтан Мәскәү җирләренә һөҗүм итик, дигәнрәк җавап килмәгәндер. Ике дәүләт тарафыннан Мәскәүгә каршы андый яуның бергә оештырылуы хакындагы хәбәрләр тарих битләрендә теркәлмәгән.

Мәскәү гаскәрләре Казан тарафына яуга барырга әзерләнергә керешкәндә, бигрәк тә язга табарак, Идел өсте боздан арынып, дошман көчләре су буйлап яуга чыгар алдыннан хан еш кына ике арада солых килешүен төзү тәкъдиме белән чыга торган була. Сафагәрәй үзе яуларны күрше кенәзлекнең чик буе шәһәрләренә ул бераз тынычлана төшкәч оештырган. Сафагәрәйнең Мәскәү дәүләте белән шундый сәясәт алып баруы Шәриф Хаҗитарханиның «Казан вилаятенең җиңүе» дастанында, әйтелгәнчә, «оста каләм сахибе булган» дигән сүзләрдә чагыла. Шагыйрь ул әсәрен һәм хатын Төркия солтаны Сөләйман Канунига да атап җибәргән була. Шагыйрь хатының эчтәлеген бүген түбәндәгечә бәян итү урынлыдыр: *«Заман таләп иткәнчә, үз иленең иминлеге, җитешлеге һәм тынычлыгы өчен тырышып, Казан иле идарәчесе кайвакыт дошманнары алдында дус күренмәкче булыр иде. Кяферләр иленә ул үз дәүләтенең абруйлы затларын һәм илчеләрен җибәреп торыр иде. Үз иленең тынычлыгы өчен тырышканда ул бер әйтемгә ятышлы гамәл кылыр: дуслары белән турылыклы булырга, дошманы алдында рияланып якты чырай белән ягымлы йөз күрсәтергә тырышыр иде»*. Әлеге сүзләр Сафагәрәйнең ул чордагы тышкы сәясәтен бик ачык чагылдыра.

Сафагәрәй ханның Литваның бөек кенәзләре һәм бер үк вакытта Польша корольләре дә булган Сигизмунд I белән Сигизмунд IIгә язган дүрт хаты сакланган. Шуларның өчесе өлкән кенәз исеменә атап язылган була. Тарихчы Д.Г.Мостафина ул хатларның шул чор белорус-рус теленә тәрҗемәләрдә тарихта «Ярлык казанского царя» була-

рак теркәлүләре хакында искәртә. Галимә аларда Казан ханлыгының тышкы сәясәте, Мәскәү кенәзлегенә карата мөнәсәбәте ачык теркәлгән, ди. Әчтәлекләреннән чыгып, Д.Г.Мостафина Сафагәрәй бу хатларны 1538 елның апреле белән 1545 елның декабре аралыгында язган, дигән фикердә тора. Шуңа өстәп, архивта Казан бәкләре Булат Ширин белән Кадыштан һәм кайбер морзалардан юлланган тагын җиде хат булганлыгы да хәбәр ителә. Аларда, ханлыктагы 1530-1540 еллар дәвамындагы сәяси вакыйгалардан тыш, әлеге дәүләтнең эчке тормышына, андагы халыклар язмышына кагылышлы мәсьәләләр дә тасвирланган икән. Д.Г.Мостафинаның «Казан патшасы юлламасы» («Послание царя Казанского») хезмәтендә бәян ителгәнчә, Сафагәрәй хатларында шулай ук бу ике ил белән дә дошмани мөнәсәбәттә булган Мәскәү дәүләте биләмәсенә ханның яу белән бару очраклары, кайсы төбәкнең җир-биләмәләренә нindирәк зыян китерелү мисаллары теркәлгән, Мәскәү бөек кенәзенең солых килешүләрен төзү омтылышларын Сафагәрәйнең берничә мәртәбә кире какканлыгы турында мәгълүматлар бар. Әлеге документлар эчтәлегеннән Сигизмунд Iнең Сафагәрәйне Казан тәхетенә тәкъдим ителгәнче үк белгәнлеге дә шәйләнә: хан Литваның бөек кенәзенә: *«Кырымда яшәгән вакытымда ук Сез мине улым дип атый идегез»*, – дип язган. Шул сүзләрдән үк ханның ни өчен бу король-кенәзне олылавы аңлашыла да инде.

Сигизмунд Iгә язган хатында хан 1532 елда Казаннан куылганнан соң каенатасы, нугай морзасы Мамайга барып сыенганлыгын, ханлыкта калган кайбер түрәләр белән даими элемтәдә булганлыгын да хәбәр итә, Җангали үтерелгәннән соң Казандагы шул түрәләр тарафыннан тәхеткә кайтарылуын, үзенә каршы булганнарны җәзалау фактларын да искә ала, шуннан соң оештырылган яуларының Мәскәү кенәзлегенең төп көчләре урнашкан чик буе калаларына (Түбән Новгород, Муром, Балахна һ.б.) юнәлдерелгән булуын да бәян итә: *«О том же отцу своему поведаю, посылал...на землю Московскую 40 тысяч людей. Старшим был Козучак бек. Был он за рекой Окою, выжег замок Борсула...»* Хан хатында менә шундый җөмләләр дә очрый. Әйе, яуга барган, күрше дәүләтнең фәлән-фәлән шәһәр һәм авылларын талап, яндырып кайткан. Ә ханлыкның төп халкына ул барымта яуларыннан ни файда? Аннан талап алып кайтылган мал бит шул талауга баручылар өчен генә булган диярлек. Ил халкының күпчелегенә ул таланган малдан сукыр бер тиен дә кермәгән. Сафагәрәйнең Литва бөек кенәзлеге белән бергә күрше дәүләтләр тарафына зуррак максат куеп оештырган яулары бу хатларда да, рус елъязмаларында да теркәлмәгән.

М.Г.Худяков язуынча, олы максат куеп, күрше дәүләтне үз йогынтысына алу нияте белән оештырылган зур яулар саны буенча өстенлек Мәскәү кенәзлеге ягында. Казан ханлыгы яшәү дәверендә ул шундый тугыз яу оештырган, казанлылар исәбендә исә шундый җиде очрак кына теркәлгән, ди галим. Ә инде вак-төяк баскынлык яуларын оештыру буенча исә Казан ханнары өстен чыга. Бу җәһәттән бигрәк тә Сафагәрәй хан аерылып тора.

Бүгенге көн тарихчыларыннан В.В.Похлебкин исә, бу ике күрше дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләргә бәя биреп, Казан ханлыгы беркайчан да Мәскәү кенәзлеген яулап алу максатын куймаган (көчләр тигез булмау сәбәпле, бу ханлык ялгыз гына аңаирешә дә алмас иде), казанлыларның кайбер яу һәм һөҗүмнәрен генә саклык чарасы буларак кабул итәргә мөмкин, дигән фикерне алга сөрә. Әмма Сафагәрәй ханның ел аралаш диярлек оештырылып торган ул барымта-яуларын бу галимнең «кайбер яулар» дигән чикләү кысаларына гына сыйдырып булмый. Шулай да ханның әлеге яулары зур максат куеп оештырылган эш-гамәлгә дә керми.

Дәвамы бар ■

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

●Дөньяда тора белү – зур һөнәр, әмма үлә белеп үлү – аннан да зур вә кыйммәтле һөнәр.

●Мең ел торучы кебек эш эшләргә вә кәсеп кылырга кирәк вә шуның белән берлектә бу сәгатьтә дөньядан үтәчәк кеше кабиленнән ахирәт өчен дә хәзерләнү кирәк.

●Балалар – яшьләр, шуның өчен аларны бөтәйтеп калдырыйм, фәлякәткә[1] төшмәсеннәр, мохтаҗ булып, кеше ишекләрендә йөрмәсеннәр, дип кәсеп итү, байлык күбәйтү тиешле эш түгел.

●Ният дөресли алмыйм, ихласым юк, фикер кылырга көчем җитми, кебек сылтаулар белән фарыз гамәлләрне кую дөрес булмаса да, ихлас ният һәм фикерне хасил итәргә тырышу катгый рәвештә фарыз.

●Адәм баласы дөньяда тору нисбәтендә малга һәм озын гомер сөрүгә комсызлыгын арттыра барадыр. Инсаннарның яшьләре арту нисбәтендә гомер белән малга хирыслары арту – табигый эш. Мал вә гомергә хирыслык – әгәр дә ахирәткә кызыгу вә (Аллаһы Тәгаләгә) мәхәббәт белән китүгә чикләү булмаса, хурланган түгел, бәлки мәмдухтыр[2]. Әмма ахирәт сәфәрен дошман күрүгә сәбәп булган хирыслык, кирәк яшь вә кирәк карт кешедә булсын, әлбәттә, мәмдух булмас.

●Тәкәбберлек – бары үзен-үзе танымаудан гына була торган нәрсә. Үзен-үзе яхшы танучы кешенең тәкәббер булганы юк. Яхшы киемнәр киеп вә яхшы ат-арбаларда йөрү, зур вә кыйммәтле биналарда тору, халыкларны хур күрү вә хаклыкка каршылык булмаса, тәкәбберлек саналмыйдыр.

●Ашарга-эчәргә хәзерләгән нәрсәләр һәм киемнәр фани булачак вә тузачаклар. Шуның өчен ашау-эчү, кию-салу нәрсәләрен адәм баласының малым дип санап торуы аңсызлыктандыр. Бәлки адәм баласының бөтен малы ахирәт өчен биргән сәдакасы вә тоткан хәйяратыннан гына гыйбарәт булып, шуннан башка бернәрсәсе дә юк.

●Кабул булуы күрелсен йә күрелмәсен, һаман дога кылырга вә Аллаһыдан сорарга, ялынырга тиешле. Бәндәчелек вазыйфасы шушыдыр.

●Нинди генә эш булса да яхшы вә шартына җитештереп эшләргә – йә, ярар әле, ахирәт гамәле түгел, димәскә тиешле.

●Кирәк мөселман вә кирәк башка милләтләрнең җеназалары булсын, үтеп киткән вә очраган вакытта игътибарсыз вә илтифатсыз калу – әдәпсезлектер.

●Кешеләрнең гаепләрен эзләү – күңел бозык булуга дәлилдер.

●Дөнья – файда ителә торган базар вә ахирәтнең игенлегедер. Шушы базар вә шушы игенлектә файда итүчеләр бәхетлеләр вә зыян итүчеләр исә бәхетсезләрдер.

●Сәламәтлекнең нигъмәт икәнлеге – инкярны кабул итми торган хакыйкатьтер. Бәлаләр, фәлякәтләрдән иминлек тә тән сәламәтлегенә якын бер нигъмәттер.

●Бөтен сәгадәт – авызны бозык сүзләр сөйләүдән вә хәрам ризыклар ашаудан һәм дә хәрам юл белән шәһвәт (җенси теләк) әсире булудан сакланудадыр. Ошбу нәрсәләргә дучар булу һәртөрле фетнәләр вә фаҗигаләргә сәбәп икәнлеге ачык мәгълүм.

●Ахирәттә нинди рәвештә кубарылырга теләсә, адәм угылы дөньяда вакытта шул рәвештә йөрергә вә гомер сөрергә тиешле. ■

---

[1] Фәлякәт – бәла, бәхетсезлек.
[2] Мәмдух – мактала торган гамәл.

ТАССР 100 лет ел
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

ТАТАР ТЕЛЕН ГАМӘЛГӘ КУЮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ*

Хаҗи Габидуллин

ТАТАРСТАН ҮЗӘК УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ

Татарстан Җөмһүриятенең үзәк учреждениеләрендә татар теле бу биш ел буенча пассив формада гына гамәлгә куелды. Ягъни җөмһүрияттәге татарлар өчен һәм татар волостьлары өчен эш татар телендә йөртелеп, төп кәнсәләрия эше урыс телендә калды. Үзәк учреждениеләрнең татар телен гамәлгә куюга яраклы икәнлекләрен күрсәткән нәрсә – боларның аппаратларындагы татар эшчеләренең, гомумән, татар телен белә торган кешеләрнең процентыдыр. Татарстанның халык комиссариатларындагы һәм үзәк учреждениеләрендәге эшчеләрнең миллият составы турындагы мәгълүматлар 1925 елның 1 апреленә түбәндәге цифарларны бирәләр.

Халык комиссариатларындагы һәм үзәк учреждениеләрдәге эшчеләрнең миллият составы (43 халык комиссариатлары һәм үзәк учреждениеләр буенча 1925 ел, 1 апрель мәгълүматлары)

	Барлыгы	татарлар	урыслар	бүтәннәр
Җаваплы эшчеләр	660	132	446	82
%		20	67,5	12,5
Техник эшчеләр	2536	292	2103	141
%		11,5	82,9	5,6
Түбәнге катлау эшчеләр	1217	258	942	17
%		21,2	77,5	1,8
Барлыгы	4413	682	3491	240
%		15,4	79,1	5,5

*Бу мәкалә «За 5 лет к V годовщине провозглашения ТССР» (1925) исемле китапта рус һәм татар телләрендә басылган.

Авыл советлары, волбашкармалар, кантон идарәләрендә татар теле ничек итеп гамәлгә куелганлыгы турында журналыбызның 7-8 саннарыннан укып белергә мөмкин. – *Ред. иск.*

Казанда татар телен гамәлгә кую курслары. Җиденче чыгарылыш

Татарстанның биш ел гомере буенча совет аппаратларындагы татарларның саны турындагы аерым мәгълүматларны тиңләштереп карасак, без түбәндәгене күрәчәкбез.

Татарстан халык комиссариатларының һәм үзәк учреждениеләрнең аппаратларында эшләүче татарларның процент саны

	Җаваплы эшчеләр	Техника-кәнсәләрия эшчеләре	Түбәнге катлау эшчеләр	Татарларның уртача проценты
1921 ел, 1 гыйнвар	10,4	4,5	9,7	7,8
1922 ел, 1 гыйнвар	11,5	5,6	10,5	8,9
1923 ел, 15 май	15,6	6,7	12,1	9,7
1924 ел, 1 июнь	19,5	9,7	26,6	14,0
1924 ел, 1 үктәбер	18,6	8,7	22,4	13,2
1925 ел, 1 апрель	20	11,5	21,2	15,4

Бу саннар шуны күрсәтәләр: соңгы дүрт ел эчендә үзәк учреждениеләрнең аппаратларында татарларның процентлары арта, алар татарлаша барды. 4 елда татарларның саны икеләтә артты. Шулай да булса, бу аппаратлардагы татарларның проценты җитәрлек һәм кайбер ведомстволар линиясе буенча бер дә тиешенчә түгел.

ТАТАР ТЕЛЕН ГАМӘЛГӘ КУЮ ЭШЧЕЛӘРЕН ХӘЗЕРЛӘҮ

Татарстан аппаратларында, бигрәк тә волость һәм кантон аппаратларында татарларның аз булуын күз алдында тотып, татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе төрле специальностьлар буенча татар эшчеләре хәзерләү өчен курслар ачты. Бу курс-

Керәшен эшчеләренең төрле вакытта җыелган съездлары һәм киңәшләре керәшеннәр арасында да татар язуын кабул итү турында карарлар чыгардылар.

лар 1922 елның ахырларында ачылды һәм үзенең 3 ел яшәве буенча, 1923 елда 130 татар эшчеләрен хәзерләп чыгарды. Болардан 42се – волость эшчеләре, 32се – суд эшчеләре, 22се – салым эшчеләре, 34е – хисап йөртүчеләр һәм кәнсәләрия эшчеләре. 1924 елда 156 татар эшчеләре чыгарылды. Болардан – 18 хисап йөртүче, 23 волость эшчеләре, 23 страхование агентлары, 43 кооперация линиясе буенча инструктор һәм хисап йөртүчеләр, 45 волость һәм кантоннар өчен кәнсәләрия эшчеләре. 1925 елда 190 эшче хәзерләнде. Болардан – 33 салым эшчеләре, 59 хисап йөртүчеләр, 28 сугыш кәнсәләриясе эшен йөртүчеләр, 32 почта-телеграф эшчеләре. Волость секретарьларыннан 38 татар яңадан хәзерләнде.

Курсларда укучыларның составын күрсәтү өчен, бу курсларның 1925 ел 1 гыйнвардагы составы турында берникадәр мәгълүматлар бирәбез. Бу вакыт арасында курсантларның саны 168 кеше иде. Болар һәммәсе дә 18 яшьтән олыраклар һәм татар телендә, һәм урыс телендә иркен сөйләшәләр. Боларның 142се – ирләр, 26сы – хатыннар. Болар арасында 150 крәстиян, 16 эшче һәм 2 кеше бүтәннәрдән бар. Партиячелекләре буенча РКП(б) партиясендәгеләр һәм кандидатлар – 6, РЛКСМ членнары һәм кандидатлары – 83, партиясезләр – 79. Курсларга кергәндәге белемнәре: ибтидаи мәктәптән – 130, уртадан түбән – 35, урта мәктәп – 3. Бу курслар хәзерге вакытларда да эшли һәм боларда совет төзелешенең төрле тармакларында эшләүче татар эшчеләре хәзерләү дәвам итә. Үзенең өчьеллык гомере эчендә бу курслар өсләренә йөкләнгән эшне яхшы үтәделәр һәм боларның кантоннарда, волостьларда татар телен гамәлгә кую өчен эшләгән эшләренең бик зур әһәмияте булды. Киләчәктә бу курсларның эш мәйданын киңәйтүгә, ягъни аңа күбрәк эшчеләр әзерләп чыгаруда мөмкинлек бирүгә юл тотылачак.

Татар телен гамәлгә кую эшләрен хәзерләүдә кәсеп-техника мәктәпләрендә укучылар составының бик зур әһәмияте бар. Кәсеп-техника белемнәренең органнары соңгы ике ел эчендәге татар укучыларын кабул итүгә нык дикъкать бирә башлаганлыклары иң соңгы елларда гына булганга, алар бу көнгәчә җитәрлек санда татарлардан специалистлар хәзерләп җиткерә алмадылар. Тик авыл хуҗалыгы белемнәре линиясе буенча гына без конкрет нәтиҗәләр күрәбез: Татарстанның авыл хуҗалыгы техникумнары, авыл хуҗалыгының аерым тармакларындагы һәм җир төзү эшләре техникумнары хәзерге көнгә 40ка якын квалификацияле татар эшчеләрен хәзерләп җиткерделәр.

Хәзер инде Татарстанның югары мәктәпләренә килсәк, без шуны күрәчәкбез: болар эшчеләр хәзерләп чыгару ягыннан да, укучыларның составы ягыннан да татар телен гамәлгә кую моментын күзгә алып төзелмәгәннәр.

* * *

Татар телен гамәлгә кую курслары белән бәйләнештагы тагы да бер моментка тукталырга кирәк булачак. Бу – керәшеннәр арасында татар имлясын гамәлгә кую мәсьәләседер. Патша режимы, үзенең ярдәмчесе миссионерлык белән бергә, «Бүл дә хакимият сөр» дигән принцип буенча барып, турыдан-туры администрация көчләү ысуллары белән һәм икътисади яктан тәэсир итеп, татарларның бер өлешен чукындыру гына түгел, бәлки чукындырылган татарларга – керәшеннәргә татар язуын оныттыру юлында да чаралар күрде. Татар язуы урынына болар арасында төрле ысуллар белән үзенә башка «керәшен язуы» керде. Керәшеннәр саны болай да аз булу (ССҖ күләмендә бары 250-300 меңнәр, шулар хисабыннан Татарстанда – 100000) һәм керәшеннәр һәр җирдә та-

Татар телен гамәлгә кую юлында без түбән аппаратларда да, кантон, үзәк аппаратларында да һәм бөтен Татарстанда да, әкрен генә булса да, һаман алга атладык һәм байтак кына эш тә эшләдек.

тар халкы арасында сибелү-таралулары сәбәпле, көчләп кертелгән керәшен язуы һичбер төрле шартлар эчендә дә үсә алмады һәм аның киләчәге дә булмады. Шул сәбәптән керәшен эшчеләренең төрле вакытта җыелган съездлары һәм киңәшләре керәшеннәр арасында да татар язуын кабул итү турында карарлар чыгардылар. Керәшен комитеты секциясенең инициативасы буенча, татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе татар телен гамәлгә кую курсларының язгы вакытын, керәшеннәр арасында татар язуын гамәлгә кую юлында керәшен укытучыларын хәзерләү өчен файдаланды. 1922 елда керәшеннәрдән 70 мәктәп эшчеләре чыгарылды. 1923 елда – 96, 1924 елда – 143, 1925 елда – 60. Бу чаралар һәм татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе тарафыннан чыгарылган аерым кулланма Татарстан Җөмһүриятендәге бик күп керәшен мәктәпләрендә татар язуын гамәлгә куюга мөмкинлек бирделәр. Кайбер керәшен мәктәпләре татар язуын төп нигез итеп алуга күчтеләр.

* * *

Татарстан Җөмһүриятендәге ике дәүләт телен дә белгән булачак эшчеләрне әзерләү юлында 2 нче баскыч мәктәпләрдә һәм кәсеп-техника мәктәпләрендә, һәрбер укучы өчен мәҗбүри дәрес сыйфатында, татар теле кертелгән иде. Моның өстенә учреждениеләрдәге һәм предприятиеләрдәге урыс эшчеләренә татар телен өйрәтүләр дә булган иде. Бу соңгы чара мәгълүм сәбәпләр аркасында хәзергә күзгә күренерлек зур нәтиҗәләр биргәне юк әле.

Гаделия (суд), мәгариф, сәламәтлек саклау һәм бүтән ведомстволарның линиясе буенча татар телен гамәлгә кую нинди хәлдә икәнлегенә без монда тукталмыйбыз, чөнки бу мәсьәлә тиешле ведомстволарның үз хисапларында аерым әйтелгән.

Татар телен гамәлгә кую белән бәйләнештә булган моментларның берсе итеп татар теле өчен гомуми бер имля куелуын, элеккеге Һиндстан цифрлары урынына бөтен Яуропада кабул ителгән гарәпнең цифр системы кертелүен, татар хәрефләрендә реформа ясау юлында күп кенә эш эшләнүен, татар телендә язу машиналары хәзерләүне, урысларга татар телен өйрәтү өчен китаплар хәзерләүне, дәүләт һәм мәдәният эшләрендә кирәк булган атамаларның эшләнүен, Татарстан хөкүмәтенең бөтен декретлары һәм карарлары һәм бөтен кодекслары татар телендә чыгуны һәм татар телен гамәлгә куюның киләчәктәге эшен җиңеләйтә торган бүтән күп моментлар эшләнүен әйтеп үтик.

Татар телен гамәлгә кую буенча биш еллык эш планы Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе тарафыннан алдан эшләнеп, Татарстан үзәк башкарма комитеты тарафыннан расланды. Бу татар телен гамәлгә кую эшен моннан соң нык план нигезендә алып барырга мөмкинлек бирә.

Татар телен гамәлгә кую юлында Татарстан бишьеллык гомере буенча эшләнгән эшләрне бер җиргә җыеп китергәч, шуны әйтеп үтәргә кирәк: без түбән аппаратларда да, кантон, үзәк аппаратларында да һәм бөтен Татарстанда да әкрен генә булса да, һаман алга атладык һәм байтак кына эш тә эшләдек. Шулай да булса, алда бик күп эшләр бар әле. Татарстан Җөмһүриятенең бу эшләрен эшләп чыгар өчен алда күп кенә вакыт һәм көч кирәк булачактыр. ■

ЭЧКЕН ТАТАРЛАРЫ

Рафаил Исакаев

Өчкүл авылында эшкуар Марат Юнысов кордырган борынгы татар йорт-каралтысы

ЭЧКЕННӘРНЕҢ КАНТОН ХЕЗМӘТЕ

Эчкеннәрнең тормышына кагылган тагын бер мөһим вакыйга булып, хөкүмәтнең 1798 елның 10 апрельдәге Указы белән кертелгән бөтен чик буе хезмәте белән идарә итүнең кантон системасы гамәлгә куелу тора. Барлыгы 20 кантон оештырыла. Татар һәм башкорт казакларына, оренбург һәм урал казаклары белән берлектә, Россиянең көнчыгыш чикләрен саклау бурычы йөкләнә. Чик буе сызыгы Тобол елгасыннан аска таба Урал елгасы агымы буенча Каспий диңгезенә кадәр сузыла һәм биш аралыкка бүленә. Беренче аралык «Уст-Уйск крепостеннан алып Верхнеуральск каласына кадәрле ныгытма һәм редутларны» эченә ала. Аңа шулай ук Звериноголовск крепосте, Тоболь елгасындагы Алабуга редуты да керә. Безнең эчкеннәр беренче аралыкка эләгә. Эчкеннәрнең биләмәсе биш кантоннан торган беренче аралыкның дүртенче кантонына карый. Кантоннар исә йортларга, бүлекләргә һәм командаларга бүленеп, аерым Оренбург крепостеның даими булмаган көчләрен тәшкил итәләр. Аның командующие Оренбург хәрби губернаторы була. Чик буе хезмәтенә 4-5 хуҗалыктан бер кеше исәбеннән 20дән 50 яшькәчә сәламәт казаклар билгеләнә. Чик буен саклау 16 майдан 16 ноябрьгә хәтле дәвам итә. Аннан муллалар, кантон башлыклары һәм аларның ярдәмчеләре, йорт старшиналары азат ителә.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

Чынлыкта чик буе хезмәтенә күп очракта ярлылар һәм милексезләр җибәрелә, димәк, алар корал белән начар тәэмин ителгән һәм атлары начар була. Байлар, хәллеләр исә акча түләп котыла. Һәркем ике – юртак һәм йөк атына, кораллардан – сөңгегә, кылычка, мылтыкка, җәя белән укларга ия булырга һәм боларның барысы да үз хисабыңа алынырга тиеш була.

(Хәлдән килмәгән очракта, корал, кием-салым, азык-төлек белән бөтен авыл хисабына тәэмин итү карала).

1796 елның 11 февралендәге Указ нигезендә һәр кантонда тимерчелек, слесарьлар, корал төзәтү остасы һәм аның ике өйрәнчеген булдырырга боерыла.

Хәрби чакырулы казакларның хезмәте чик буен саклау белән генә чикләнми. Алар хәрби хәрәкәтләргә дә тартыла. Мәсәлән, Оренбург төбәгеннән Наполеон белән сугышка 7 мең татар һәм башкорт, 1 мең чиләбе белән оренбург казаклары һәм 600 калмык җибәрелә. Билгеле, чиләбе казаклары арасында эчкеннәр дә була, чөнки Эчкен волосте Чиләбе өязенә керә. Шуңа күрә Берлин һәм Париж урамнарын бабаларыбыз таптаган булырга бик мөмкин.

Безнең эчкеннәр күчмә халыкларның һөҗүмнәрен кире кайтарганда, Пугачев ягыннан крестьян күтәрелешендә, Наполеонга каршы сугышта катнашканда каһарманлыкларны еш кылалар.

ТЫНЫЧ ТОРМЫШ

Эчкеннәрнең тыныч тормышына әйләнеп кайтыйк. Сугыштан тыш, аларга сөрергә, чәчәргә, урырга, терлек асрарга да туры килгән бит. Иң мөһиме – балалар табарга, аларны үстерергә, йолаларыбызны һәм мәдәниятебезне киләчәк буыннарга да җиткерергә...

Без инде берничә мәртәбә эчкеннәрнең саны арта баруын билгеләп үткән идек. 1720 елда үзәк авыл Бәлкау өч өлешкә бүленә. Өчкүл исә 1740 елда икегә аерыла. 1795 елдан 1803 елга кадәрле аралыкта эчкен авылларының халкы 181 кешегә арткан, Өчкүлдә исә – 46 кешегә. Эчкеннәр бу вакытка инде үзенчәлекле этник төркем булып формалашалар, аерымланыбрак яшиләр һәм үз җирләрендә «ятларның» күренүен хупламыйлар. Берничә батрак кыргыз-кайсан гаиләсен исәпкә алмаганда, халык мишәрләрдән генә тора. Әлеге гаиләләр өчкүллеләрнең кан чисталыгын «бозалар». Бу кыргыз-кайсаннардан берничә катнаш гаилә барлыкка килә. Эчкеннәр бүгенге көнгә кадәр аларны «казах нәселе» дип йөртәләр. Кыяфәтләре дә кыргыз-кайсаннарныкы.

1802 елгы ызанлау (межалау) авылларның чикләре һәм җир биләмәләренең үлчәмнәре проблемасын хәл итә. Әмма межалау мәгълүматлары губерна үзәгендә саклана, ә халыкның, җир бәхәсләрен хәл итәр өчен, җирләренең тасвирламаларын үзләрендә булдырасы килә. Моннан тыш, 1812 елга 1802 елда куелган ызан билгеләре инде искерә һәм аларны алыштырырга кирәк була.

Бу проблемаларны хәл итү өчен, биш авыл ирләренең 1812 елда узган гомуми җыенында волостьның вәкаләтле заты сайланып, аңа волостьның мөһим җәмәгать эшләрендә алар мәнфәгатен кайгырту вәкаләте бирелә. Ул – Әлмән авылында яшәгән Фазыл Ибраһим улы Тенәкәчев. Элегрәк изге Мәккәгә хаҗга барган бу мөхтәрәм шәхес эчкеннәр мәхәлләсенең имамы һәм аның нәселе халык арасында танылган була. Хәлле гаиләдә туган Фазыл, Әлмән мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлагач, башта Бәләбәй төбәгендә Габделваһаб бине Шәриф хозурында, аннары Каргалы һәм ерак Әфганстандагы Кабул мәдрәсәләрендә гыйлем эсти. Белем һәм тәҗрибә туплап, Фазыл Тенәкәчев ватанына әйләнеп кайта. Россия дәүләтенең махсус илчелеге составында

ул, төрек солтаны белән килешер өчен, Истанбулга, соңрак Бохара әмире янына бара.

Фазыл Тенәкәчевнең үтенече буенча, Чиләбе өяз идарәсе, «Эчкен волосте территориясе планы»н төзер өчен, җир үлчәүче җибәрә. Нәтиҗәдә, Эчкен волосте биләгән мәйдан үзгәртелә, чик буендагы бәхәсле мәсьәләләр хәл ителә. Әлеге план буенча, биш авыл – Әлмән, Иминкүл, Тузавыл, Чияле һәм Өчкүл Чиләбе өязенең Эчкен волостен тәшкил итә. Авыл халкы нарат һәм каен агачыннан салынган йортларда яши.

Аерым очракларда берничә бүлмәдән торса да йортлар гадәттә кухня һәм йокы урыны булган тоташ бинаны тәшкил итә. Өчкүл авылында 1869 елда 113 йорт була.

Идән һәм түшәм, түбә нарат такталарыннан тора. Өй эчендәге һәм тышындагы төрле вак-төяк эшләнмәләр дә нарат агачыннан ясала. Мичләр өчен яндырылган кирпеч, ә нигез өчен Уралдан китерелгән таш кулланыла. Йортка кушып кәҗәнкә дә эшләнә. Кухняның зур өлешен мич биләп тора. Мичнең бер кырыена – учак өстенә чуен казан урнаштырыла, азык шунда пешерелә. Мичкә каршы сәке куела, ул йокы урыны да булып хезмәт итә.

Җәен ризыкны ишегалдында әзерлиләр. Моның өчен, түбә астында, миче булган казан урнаштыралар. Мул тормышлы өчкүлленең өе, ихтыяҗга карап, 2-3 өлешкә бүленә. Гаилә корган улга аерым бүлмә карала. Һәр бүлмәдә алгы стена буена сәке урнаштырыла, ул мебельне дә алыштыра. Сәкегә гадәттә киез һәм арзанлы келәм җәелә, ястык, мендәрләр һәм юрган куела. Хатын-кызлар көндез махсус бүлмәдә булып, үз эшләре белән шөгыльләнәләр һәм анда чит кешеләргә керү тыела. Йортлар бик чистапөхтә тотыла: мичләр атна саен агартыла, шомартылган идән такталары, буялмаган булса, сап-сары итеп юыла.

Төрле хуҗалык корылмалары булган ишегалды ике өлешкә – алгы һәм арткыга бүленә. Аның урамга караган алгы өлешендә зур такта капка белән өй, күрше йорт стенасы ягында амбар һәм келәт, эчтәрәк – кышын арба белән җир эшкәртү кораллары, җәен чана саклана торган сарай, шуннан соң утын өелгән һәм арткы ишегалдына керә торган капкалы лапас була. Койма белән әйләндереп алынган арткы ишегалдында бозаулар белән бәрәннәр өчен җылы абзар, сарык, сыер һәм ат абзарлары урнаша. Арткы якта мунча да салына.

КАРТ БАБАМ ГАБДУЛЛА ГАИЛӘСЕНДӘ

1869 елда Өчкүл авылы буенча «Статистик исемлек» төзегәндә карт бабам Габдуллага 57 яшь тула. Карт әбием Марзен белән аларның җиде балалары: дүрт кыз – Сәмига, Хәбирә, Сабира һәм Сәгыйрә, өч ул – Габидулла (минем бабам, 1846 елда туган), Хисмәтулла, Нигъмәтулла була. (Олы балалары – кызлары, кече балалары – уллары.) Кыз артыннан кыз туганга, булышучы ир балалар булмаганга карт бабам бик борчылган, ир балаларның тууын 10 ел көткән. Сөенеч китереп, 1846 елда беренче уллары туган. Ул вакытка инде кызлары, кияүгә чыгып, башка гаиләгә киткән, шуңа өйдә булышучы калмаган. 1869 елга, өлкән улларының ике хатынын кертеп, карт бабам гаиләсе 7 кешедән торган.

Эчкеннәрдә календарь елы хәмаль аеннан башланган. (Хәзергечә 25 гыйнварга туры килә.) Яңа елны өч көн бәйрәм иткәннәр: ат чабышлары, төрле ярышлар һәм уеннар үткәрелгән, бер-берсенә кунакка йөрешкәннәр, шулай итеп, көндәлек мәшәкатьләрдән арынып торганнар. Ул елны исә, карт бабам гаиләсендә өлкән улларының баласы (булачак бабам Габидулланың) тууын көткәннәр.

БАЛА ТУГАНДА ҮТӘЛҮЧЕ ЙОЛАЛАР

Бала туу гаиләдә һәрвакыт зур вакыйга саналган. Яңа елдан соң ике атна үткәч, өлкән киленнең – бабам хатыны Хатирәнең тулгагы башлана. Кече киленне кендек әбисен чакырырга җибәрәләр. Ул, йөгереп килеп җитеп, үз эше белән шөгыльләнә башлый: сабыйны кабул итеп, кендеген бәйли, аннары җылы су белән юып, әтисенең иске күлмәгенә төрә (бәхет юрау) һәм иреннәрен сыер мае белән майлый (авызландыру). Әгәр кайбер гаиләләрдә балалары үлеп барса, яңа туган нарасыйны «саклау» максатында сабыйны «сату» йоласын үтиләр: кендек әбисе баланы җылы итеп төреп, урамга алып чыга һәм аны чүп өеме өстендә калдырып керә. Сабыйны шунда ук башка хатын күтәреп алып, тәрәзәгә килә һәм аны сатып алырга тәкъдим итә. Аз гына сатулашып торганнан соң, хатын баланы тәрәзәдән бирә. Бу йола явыз рухларны алдау өчен үткәрелә: янәсе, сабый алар әзәрлекләгән хатынныкы түгел.

Ә «безнеке» кыз сатып ала. Бабам һәм әтием бик сөенәләр. Беренче көннән башлап, атна буе мунча ягалар. Кендек әбисе анда бала тапкан хатынны юындыра, аннары сабыйны коендырырга китерәләр. Бала тапкач, туганнары һәм күршеләре анага сабый ашы китерәләр. Бер атналап вакыт узып, бала тапкан хатын, ныгый төшеп, өй эчендә йөри башлагач, аның хәлен белгән хатыннарның барысын да «май ашату» йоласына – май белән сыйларга дәшәләр. Чакырылган кунаклар нарасыйга бүләкләр алып киләләр, ә аларны камыр ризыклары, чәй яки май һәм бал белән сыйлыйлар. Шул ук көнне кичен кызларны «бәби саклау» йоласын үтәргә чакыралар, аларга да чәй эчерәләр. Кызлар, шуннан соң уеннар оештырып, күңел ачалар. Йоланың максаты – баланы явыз рухлардан саклау.

Икенче мөһим йола – балага исем кушу. Аңа мулла белән ирләрне генә чакыралар. Атасы баланы мендәргә салып алып чыга, мулла, махсус дога укыганнан соң, сабыйның колагына өч мәртәбә: «Синең исемең «Хәерҗамал» булсын», – дип пышылдый. Шуннан соң мулла яңа туган сабыйны Метрика кенәгәсенә терки. Баланың әтисе моның өчен аңа сәдака бирә. Рәсми өлеш тәмамлангач, сый-хөрмәт белән чәй эчәләр.

Инде кышкы эшләр белән шөгыльләнер вакытлар да килеп җитә. Ирләр терлек карый, печән һәм утын китерә, кырга тирес чыгара, инвентарь, дирбия әзерли. Боларның барысы белән дә карт бабам идарә итә: ул эшне уллары арасында бүлә, күрсәтмәләренең үтәлешен күзәтә, үзе исә көче җиткән эш белән шөгыльләнә.

Хатын-кызлар өй эшләрен башкара: ашарга пешерә, чисталык саклый, тегә, кием ямый, сыер сава һ.б.

Дәвамы бар ■

ОЛЬГА АПА БӘЕТЕ

Бу бәет Татарстан Республикасының Кайбыч районындагы Хуҗа Хәсән авылы кызы Данилова (Кузнецова) Ольга Власовнага багышлана.

Кулларыма кәгазь, каләм алдым,
Ольга апага бәет язарга.
Пулеметчы татар кызы белән
Таныштырып сезне узарга.

Гасыр башы – сугыш арты сугыш,
Ачлык-ялангачлык илемдә.
Ишекләрне шакып үлем йөри,
Мәхшәр чоры туган җиремдә.

Язмышларның узмыш юлларыннан
Гомер елгалары агалар.
Тормыш дәвам итә, һәр иртәдә
Кояш чыга, таңнар аталар.

Хуҗа Хәсәндә дә таң атканда
Аваз сала бер кыз дөньяга.
Ольга атлы нәни кызчык туу –
Зур куаныч ата-анага.

Тик әлегә дөнья тыныч түгел,
Ачлык-ялангачлык еллары.
Бер гаепсез кешеләрне Себер,
Сөргеннәргә сөрү заманы.

Ольганың да газиз әтисенә,
Кулак исемнәре тагалар.
Бар мөлкәтне агентчылар талап,
Гаиләдән тартып алалар.

Сез – дошманнар, сез – кулаклар, диеп,
Балаларын үртәп көләләр.
Кавалерист, батыр көрәшченең
Газизләрен читкә этәләр.

Кызыл Армиянең батыр улы –
Влас абый бик тиз аклана.
Аның чын исеме, батырлыгы
Халык күңелендә саклана.

Кара шәлен япкан язмыш кына
Кайгы арты кайгы китерә...
Балаларын – йөрәк парәләрен
Ачы язмышларда бөтерә.

Унбер бала туып үссәләр дә,
Берәм-берәм кими баралар –
Төрле чирдән яки фаҗигадән
Мәңгелеккә китә балалар.

Пелагия апа ничек түзгән,
Үзәкләре ничек өзелгән?!
Һәр баласын гүргә салган саен,
Ана, диләр, үлеп терелгән.

Олы улы Семёны да, әнә,
Ил чигендә – хәрби хезмәттә.
Финнар белән каты бәрелештә
Орден алган улы, хөрмәттә.

Кырык беренчедә – тагын сугыш,
Туган илне кирәк сакларга,
Семёны да, Лёвасы да янә
Сугышалар алгы сафларда.

Кырык өчтә старшина Лёва
Ятып кала шәһри Краснодарда.
Ә капитан Семён Данилов
Күзен йома Псков кырында.

Инде хәзер Ольгага да чират
Килеп җитә илне сакларга.
Егерме бер яшьтә пулеметчы булып,
Укытучы баса сафларга.

Зур көрәшләр, югалтулар белән
Украина, Польша алына.
Ватан өчен, абыйлары өчен
Фашистларга үлем яудыра.

Германнарның бик күп шәһәрләрен
Фашистлардан азат итәләр.
Берлинны да штурм белән алып,
Рейхстагка әләм эләләр.

Дошманнарны тезләндерә халкым,
Утка тотып фашистны өнендә.
Җиңү бәйрәмен дә Ольга апа
Каршы ала Берлин җирендә.

Берлинны алуда катнашканга,
Күкрәгенә медаль тагыла.
Җиңү шатлыгыннан зәңгәр күктә
Салют арты салют атыла.

Сугыш бетте! Инде, туган җирем,
Геройларың кайта үзеңә.
Ватан Анам, газиз балаларың
Җиңү алып кайта иңендә.

Җиңү алып кайта улларың,
Йөзләрендә нурлар уйнатып;
Туган җирдән атлый батырлар,
Орден, медальләрен чыңлатып.

Тәннәрендә, ләкин тәннәрендә
Күбесенең яралары сызлый.
Чит җирләрдә, ятып калганнарның
Өзгәләнеп балалары елый.

Аналары, хатыннары гына
Әле исәннәрдер, диеп уйлый.
Бәлки әле кайтып килер, дип,
Көтә алар өметләрен җуймый.

Хуҗа Хәсәндә дә олуг бәйрәм,
Каршы ала халык батырларын.
Ватан өчен утка-суга кергән
Курку белмәс кыю кыз, улларын.

Пелагия апа кочып алган
Дөнья гизеп кайткан баласын;
Йөрәк түрләреннән өзелеп төшкән
Багалмасын, йөрәк парәсен.

Очрашудан, шатлык яшьләре
Тып-тып итеп җиргә тамалар.
Ул елларның ачы газабына
Ничек түзгән икән Аналар...

Хуҗа Хәсән – тәпи баскан җирем,
Шундый сагындырдың кызыңны.
Сагындырдың, бик тә сагындырдың
Гөл-чәчәкле болын, кырыңны.

Сагындырдың туган нигеземне,
Сагындырдың әткәм-әнкәмне.
Сагындырдың укучыларымны,
Мәктәбемне – белем чишмәмне.

Ольга апа шуңадыр да бәлки
Хезмәт юлын башлый мәктәптән –
Балаларга белем бирүдән,
Иң хөрмәтле, олуг хезмәттән.

Үзенә тиң сөйгән яры белән
Матур гына кора гаилә.
Бер-бер артлы бәләкәчләр туып,
Ата-ананы күмә бәхеткә.

Депутат ул авыл Советында,
Ә мәктәптә белем бирүче:
Ярдәм сорап килгән кешеләргә
Соңгы телемен дә бирүче.

Район советына сайлап куеп,
Дәрәҗәсен халык күтәрә.
Депутатның эшләнәсе эше,
Бурычлары тагын өстәлә.

Йөрәк кенә соңгы вакытларда
Чәнчеп-чәнчеп үтә үзәккә.
Ничекләр соң түзеп яшәргә,
Челтәрләнеп беткән йөрәккә.

Табиблар да Ольга апаның
Яшәү мөмкинлеген тапмыйлар.
Биш баланы ятим калдырып,
Йөрәк тибешләре туктыйлар.

Әниләре үлгәч, Пелагия әби
Тәрбияли ятим балаларны.
Инде егәр киткәч, хатын димләп,
Киявенә тапшыра оныкларны.

Зур гаилә йөген тартканда,
Алексейга – Валя таяныч.
Биш бала да хәзер үз янында,
Ата өчен бу – зур куаныч.

Тырышалар үз көчләре белән
Балаларны кеше итәргә.
Авыл советыннан, мәктәптән дә
Өмет юк бит ярдәм көтәргә.

Андый чакта кала икән бары:
«Ходай ярдәм итсен, – дияргә. –
Алгы көннәрендә ятимнәргә
Бәхет бирсен», – диеп теләргә.

Чын йөрәктән була теләкләре,
Балалары үсеп җитәләр;
Әти-әниләрен куандырып,
Олыларга ярдәм итәләр.

Еллар уза торгач, Ольга гына
Күпләр хәтереннән җуелган.
Җиңү бәйрәмендә исемен дә
Искә алучылар булмаган.

Вячеслав энесе тырышлыгы белән
Каберенә һәйкәл куелган.
Укытучы, пулеметчы, депутатның
«Ольга» исеме ташка уелган.

Мәктәпкә дә «Ольга» исемен
Теләүчеләр булган бирергә;
Кече сержант, бүлек командирын
Тарих битләрендә күрергә.

Юк икән шул, бу эш кыен икән,
Кирәк икән бик күп язулар:
Барып җитәр өчен түрәләргә,
Сират күперләрен узулар.

Үткәннән тыш киләчәкнең югын
Кайберәүләр икән төшенми.
Капчыктагы без ятмаган кебек,
Дөреслек тә җиргә күмелми.

Музейлар да калкыр – тарих йөзен ачар,
Җир тора бит һаман әйләнеп.
Исемнәр дә кайтыр – хезмәтләре балкыр,
Түрәләргә тормый бәйләнеп.

Барлыйк әле, данлыйк геройларны,
Тарихларга кертеп калдырып!
Исемнәрен килер буыннарга,
Алтын хәреф белән яздырып!

Фәйрүзә Хисамиева ■

ЯПОНИЯНЕ ачкан татар галиме

(Әбрар Кәримуллин язмаларында япон темасы)

Фәүзия Бәйрәмова

Әбрар Кәримуллин Япониянең башка галимнәре белән дә даими аралашып торган, дидек, шуларның тагы берсе – ***Ивао Камозава***. «Япония вә төрки-татарлар» мәкаләсендә Әбрар ага бу дусты турында да җентекле мәгълүмат биргән. Аның язуынча, Хосей университеты профессоры, «Фәнни география» журналының баш мөхәррире Ивао Камозава Япониядәге татарлар белән күптән кызыксына һәм алар турында шактый язган икән.

«Казанда «Татар энциклопедиясе» төзү башлануын, аңа Япониядәге татарлар турында мәкалә кертергә җыенуыбызны яздым һәм ярдәм итә алмассызмы, дип язган идем, – дип хәбәр итә Әбрар ага. – *Ул 100 биттән артык бер тикшеренүен җибәрде. Ивао Камозава татарлар белән күптән кызыксына икән. Без карый торган белешмәдә аның 1983 һәм 1984 елларда япон телендә «Япония татарлары турында язмалар» дигән бер серия мәкаләләре басылуы да шуны раслый».*

Инде Әбрар аганың нинди белешмә турында әйткәненә игътибар итик. Әйе, бу саллы, ике томлык белешмәне аңа япон галиме Хисао Комацу җибәрә. Ул «Япониядә Үзәк Азияне өйрәнү буенча библиография» дип атала, 1988 елда Токиода басылган, япон телендә. *«Анда 1879 елдан алып 1937 елның мартына хәтле Үзәк Азиягә багышланган һәм Япониядә басылган хезмәтләрнең библиографиясе китерелгән,* – дип яза Әбрар Кәримуллин. – *Ул япон телендә булса да, белешмәгә кергән һәр мәкалә һәм китап исеме инглиз теленә дә тәрҗемә ителгән. Шулай да ул журналлар һәм җыентыкларның исемнәре фәкать японча гына. Шуңа күрә аларның исемнәрен күрсәтә алмыйбыз».* (*Мәкаләнең ахырында: «Библиографиядә 1879 елдан алып, 1987 елның мартына кадәр Үзәк Азия халыклары тарихына караган 15 мең хезмәт теркәлгән»*, – диелгән. Безгә калса, 1987 ел датасы дөрес булырга тиеш, чөнки белешмәдә шул елларда чыккан хезмәтләр дә күрсәтелгән. – *Ф.Б.*)

Әбрар Кәримуллин «Япония вә төрки-татарлар» дип аталган мәкаләсендә бу белешмәгә шактый зур урын биргән. Белешмә-библиографиядә Үзәк Азия халыкларының, шул исәптән, Россиянең көньяк далаларында яшәүчеләрнең тарихы, теле, дине, мәдәнияте, сәяси тормышы, этнографиясе һәм географиясе мулдан бирелгән, аларның күпчелеген япон галимнәре үзләре язган. Шулай ук бу өлкәләрдә яшәүче җирле халыклар турында Европа һәм урыс галимнәренең дә хезмәтләре бирелгән.

«Белешмәдә материалларның абсолют күпчелеге Маньчжурия, Төньяк-Көнбатыш Кытай, Урта Азия, Себер халыклары турында, – дип яза Әбрар Кәримуллин. – *Сирәк кенә булса да Кавказның аз санлы халыкларына караган материаллар да очрый. Башкорт, чуаш халкына караган берәр мәкалә дә бар. Белешмәдә «татар»лар турында материаллар чагыштырмача күп».*

Әбрар Кәримуллинның «Япония вә төрки-татарлар» мәкаләсендә ул илдә яшәгән милләттәшләребез турында да күп мәгълүмат бирелгән. Исегезгә төшерәбез: бу бит – 1991 ел, тимер капкалар яңа ачылып кына килә торган вакыт, халык яңа, дөрес

Азагы. Башы журналның 8 нче (2018) санында.

мәгълүматка сусаган, һәр биргәнне йотып кына бара. Шушындый вакытта Япониядән килгән хәбәрләрнең Әбрар Кәримуллин кебек милләтпәрвәр галим кулына эләгүе – үзе үк зур бәхет, чөнки ул аларны яшереп тотмый, «тиешле» урыннарга да илтеп тапшырмый, ә, эссесен дә суытмыйча, халыкка җиткерә. Әйткәнебезчә, бу мәкаләсендә дә ул заманында Японидә яшәгән Габдерәшит Ибраһим, Гаяз Исхакый, Мөхәммәт Габделхәй Корбангалиевләр турында шактый җентекләп яза. Әлбәттә, алар турында язганда, Әбрар Кәримуллин иң беренче чиратта шушы «Япониядә Үзәк Азияне өйрәнү буенча библиография»гә таянган, чөнки анда кырыкка якын хезмәт татарлар турында булып чыккан.

Әйтик, Габдерәшит Ибраһимның 1909 елда Токио журналында басылган «Татарларның азатлык өчен тырышулары» мәкаләсе, Әбрар Кәримуллин язуынча, *«Япониядә татарлар турында чыккан беренче мәкалә»* булган. Мөхәммәт Корбангалиевнең «Һинд-Европа халыклары һәм Урал-Алтай халыклары», «Урал-Алтай халыклары һәм Россия Азиясе», «Панисламизм һәм Идел-Алтай халыклары» дип атллган зур-зур мәкаләләре әле 1923 елда ук Токиода басылып чыга. Шулай ук бу ике шәхеснең Япониядә мәчет-мәдрәсәләр ачтыруын, дәреслекләр язып бастыруын, милләтне диндә калырга нык ярдәм итүен дә әйтеп үтәргә кирәк. Гаяз Исхакый исә гомумән Япониядә зур эшчәнлек җәелдереп җибәрә, милли корылтайлар уздыра, татарча газета чыгара башлый, халык белән очрашулар оештыра. Белешмә-библиографиягә таянып, Әбрар Кәримуллин аның турында болай дип яза: *«Аның бирегә килеп чыгуы япон зыялылары игътибарын да үзенә тарта: Гаяз Исхакый япон галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре белән аралаша. Япон җәмәгатьчелеген безнең халык язмышы белән таныштыру йөзеннән язган «Маньчжуриядә яшәүче төрек-татарларның азатлык өчен көрәше» исемле мәкаләсе 1934 елда япон телендә басылып чыга. Шушы елны ук аның «Идел-Урал» дигән монографиясе Токиода аерым китап буларак япон телендә нәшир ителә»*.

Хәзерге вакытта Гаяз Исхакыйның Япония чоры шактый җентекле өйрәнелгән, әмма узган гасырның 90 нчы еллар башы өчен Әбрар аганың язганнары зур яңалык иде. Бу мәкаләдә тагы бер нәрсәгә игътибар иттек – анда сүз Муса Бигиев турында барырга тиеш. *«1941 елда Токио журналларының берсендә татар кешесе Ярулла Мусаның «Төрек татарлары» дигән шактый күләмле мәкаләсе бирелә. Менә шуны японнарга безнең халык турында мәгълүмат бирүне башлап җибәрү дияргә мөмкин»*. Төрки дөньяда Муса Бигиевнең – Ярулла (Җәруллаһ) Муса дип йөртелүе билгеле, бәлки ул япон белешмәсенә дә шул исеме белән кертелгәндер. Муса Бигиевнең Габдерәшит Ибраһим белән якын дуслар булуын, ул елларда аның Рәшит казый янына Япониягә барып чыгуын да әйтеп үтәргә кирәк.

Бу елларда Япониядә татар тарихы, аның әдәбияты һәм мәдәнияте белән кызыксыну иң югары ноктасына җиткән, дигән фикер кала. Әйтик, 1922 елда ук Әмир Телиоглы дигән кеше «Россиядә төрки-татар милли хәрәкәте» дигән китабын Япониядә бастыра; 1937 елда Мәскәүдә чыккан «История Татарии в материалах и документах» китабы Япониядә дә дөнья күрә, чөнки бу – патша Россиясенең урыс булмаган халыкларны изүе турында дөрес китап була; 1940 елда япон галиме ***Йошиасу Миясака*** аның турында зур мәкалә яза; 1944 елда миссионер П.Знаменскийның «Казанские татары» китабы япон теленә тәрҗемә итеп чыгарыла, аны Япониядәге «Үзәк Азияне өйрәнү төркеме» оештыра, чөнки бу китапта татарлар турында күп дөрес мәгълүмат бар; шулай ук 1938 елда «Идел-Урал милли хәрәкәте һәм Габдулла Тукай», 1939 елда «Идел-Урал татарларының трагедиясе», 1940 елда «Татар автономияле республикасының хәзерге хәле» язмалары Япониядә басылып чыга.

Әбрар Кәримуллин 1920-1940 елларда татар тарихы белән кызыксынган һәм бу

Лариса Усманова – милләтебезнең Япониядәге тарихын өйрәнүче галимә. 23-24 июль, 2018 ел

хакта хезмәтләр язган япон галимнәрен дә әйтеп үтә. Менә алар – ***Кожи Окуба***, ***Джиро Мурато***, ***Йошиасу Миясака***. *«Япон галимнәреннән беренче булып, татарлар турында Кожи Окуба язган булырга кирәк,* – дип хәбәр итә галим. – *Ул 20 нче елларда Маньчжуриядә яши, биредә татарларның язмышы, тормышы белән яхшы таныш була. Ике хезмәте библиографиягә теркәлгән: «Төрки-татарларның Харбиндагы тормышы», «Ерак Көнчыгыштагы төрки-татар халкы хәрәкәте» 1924 елда басылганнар. Маньчжуриядә яшәүче татарларның тормышы, аларның милли-мәдәни эшләре башка япон галимнәрен дә кызыксындырган. Джиро Муратоның 1929 елда «Чанчунның һәм Каюангның мәчетләре», 1930 елда «Маньчжурия мәчетләренең тарихын өйрәнү» дигән мәкаләләрен күрсәтергә була. Маньчжурия татарларының сәүдә эшләре дә японнарның игътибарыннан читтә калмаган.* ***Казаки Сонодaның*** *1940 елда чыккан «Маньчжуриядә сәүдә эшләренең уңышлары» дигән мәкаләсе шул хакта». Әбрар Кәримуллинның бу мәкаләсеннән күренгәнчә, япон галимнәре ислам дине һәм татарлар турында да хезмәтләр язганнар. «1942 елда япон телендә Йошиасу Миясаканың «Ислам әдәбияты турында язмалар: татар милли шагыйре» дигән мәкаләсе күренә. Япон галимнәре Габдулла Тукай исемен татар милли азатлык хәрәкәте белән бергә карыйлар».*

Әбрар Кәримуллин «Сөенечле күренеш һәм... битарафлык» исемле язмасында башка бер япон галиме турында хәбәр итә: *«Соңгы вакытта мин Япониядән килгән тагын бер япон галиме* ***Кацунари Нишияма*** *белән таныштым... Ул да Япониядә безнең тарихыбызны өйрәнүче галимнәр төркеменә керә дияргә була»,* – дип яза. (Шәһри Казан, 1991, 6 ноябрь.) Әбрар аганың язуынча, Кацунари Нишияма да Казанга үз хисабына килгән, архивларда һәм китапханәләрдә эшләгән, галимнәр, татар зыялылары белән очрашкан. Хоккай университетында – приват-доцент һәм Саппоро сәнгать институтында вице-профессор булып эшләгән бу япон галиме Россиядә егерменче гасырдагы революцияләр, халык хәрәкәте һәм төрки халыклар тарихын өйрәнә икән. *«Аның сүзләре белән әйткәндә, «Россия-СССР тарихын төрки халыклар тарихыннан башка аңлау мөмкин түгел». Менә шунлыктан ул, славист тарихчы булу белән бергә, тарихчы-тюрколог та. Аның Казагыстан, Урта Азия халыклары тарихына караган материалларына тукталмыйча, турыдан-туры яки өлешчә безнең халык тарихына караган берничә хезмәтен генә искә алып үтик. Менә алар: «Россия революцияләре һәм Урал, Идел буенда милли мәсьәлә» (Саппоро, 1985 ел), «Башкортстан АССРның формалашуы: бер партияле система һәм милли мәсьәлә» (Токио, 1987 ел), «Русь революциясе милли окраиналарда: колониаль революция мәсьәләләре» (Токио, 1991 ел) дигән мәкаләләр».*

Әйткәнебезчә, Әбрар Кәримуллин узган гасырның 90 нчы елларында Ерак Көнчыгыш, шул исәптән Япония темасы белән шактый гына шөгыльләнеп ала. 1990 нчы елны «Идел» журналының 5-6 саннарында аның «Язмыштан узмыш...» дип аталган күләмле мәкаләсе басылып чыга, ул Ерак Көнчыгыш илләрендәге татарлар тарихына багышлана. Соңыннан бу фәнни-популяр хезмәт Әбрар Кәримуллинның «Язмыш, язмыш...» китабында да дөнья күрә. Автор бу язмасында заманында Кытай, Корея, Япониядә яшәгән милләттәшләребез турында җентекләп яза, аларның тарихларын, тормышларын, язмышларын бәян итә. Мәкаләдә, беренче тапкыр, дистәләгән, хәтта йөзләгән татарның исеме телгә алына, алар салдырган мәчет-мәдрәсәләр, бастырган китаплар, чыгарган газеталары, кылган гамәлләре сокландыргыч та, язмышларына күрә, кызганырлык та итеп тасвир ителә. Әмма шул ачык күренә – татар кайда да югалып калмый, үзе килеп урнашу белән, янына милләттәшләрен тарта, мулласын чакырта, мәчет-мәдрәсәләр төзеп куя, эшен ача, сәүдә итә, абруйлы көн күрә...

Бу мәкаләнең «Япониядә» һәм «Ерак Көнчыгыш илләрендә татар басма сүзе» бүлекләре тулысынча диярлек Япониягә һәм анда яшәгән татарларга багышланган. Монда безнең игътибарны җәлеп иткән берничә мөһим хәбәр бар, беренчесе – 1904-1905 елгы урыс-япон сугышында японнарга әсирлеккә төшкән татар солдатларының саны 15-20 мең булуы турында хәбәр; икенчесе – Габдерәшит Ибраһимның 1906 елда Япониягә шул әсир татарларны эзләп баруы; өченчесе – 1948 елда Япониядә 1 миллион мөселман булуы турында хәбәр. Бигрәк тә менә бу соңгысы аерым игътибар сорый. Әбрар ага бу мәгълүматны каян алган соң?

«Моннан 30 еллар элек мин Парижда дөньядагы мөселман халыкларының тарихы, социаль һәм икътисади (экономик) хәле һәм сан исәбе турындагы бер китап белән танышкан идем. «Annuaire du Monde Musulman Statistique, historique, social et econotique» дигән хезмәт; авторы – Massingon L. Анда 1948 елда Япониядә 1 миллионга хәтле мөселман булуы, шуларның 400 меңе – Токиода, 300 меңе – Кобедә, 100 меңе Осакада яшәве язылган. Японнарның мөселман диненә күчүе татарлар йогынтысында булды, диелгән. Шушы ук китапта Япониядә «Яңа япон мөхбире» дигән газета басылуы, күрсәтелгән шәһәрләрдә татар җәмгыятьләре эшләве, 1934 елда Коръәннең япон теленә тәрҗемәсе басылуы турындагы хәбәр дә бар. Ислам динен кабул иткән японнарга гарәп, төрки телләрне, ислам дине тарихын өйрәтүче мәктәпләр эшләве искә алынган. Японнарның мөселман диненә күчүендә Рәшит казый зур роль уйнаган. Япониядә дин иреклe бит. Татар мәчетләренә, кызыксынып, японнар да кергәләгән, тора-бара, Аллага иман китергән японнар мәчетләргә даими йөри башлаган, кайберләре Мәккә вә Мәдинәгә хаҗга да барып кайткан.

Татар яшьләре япон уку йортларында укыйлар. Рәшит казыйның улы, мәсәлән, Токио университетын тәмамлаган. (Рәшит казый соңыннан Япониягә килеп урнаша, Токиода яшәп, 1944 елда вафат була, Токио мөселманнар зиратында җирләнә.)» (Әбрар Кәримуллин. Язмыш, язмыш... – Казан, 1996, 38-39 бб.)

Дөрес, Габдерәшит Ибраһим турындагы мәкаләләремдә мин узган гасырның 30-40 елларында Япониядә бер миллионга якын мөселман булуын язган идем инде, әмма чыганагын күрсәтмәгән идем. *«За этот период многие представители японской элиты, включая военных и интеллигенцию, приняли ислам. По утверждению некоторых зарубежных ученых, в тот период в Японии уже насчитывалось около одного миллиона мусульман. В этот период активно разрабатывается «азиатская» теория в исламе, согласно которой народы Евразии должны были объединиться под лидерством Японии на платформе ислама».* (Фаузия Байрамова. Нераскрытая история татар. – Казань, 2013, стр.72.) Бу мәкаләнең төрекчәсен ошбу җыентыктан укырга мөмкин: Bayramova Fauzia. Buyuk Tatar Misyoneri / Abdurresit Ibrahim. – Konya, 2012. Әмма кайберәүләр Япониядә

Япониядәге татар тарихын өйрәнү дәвам итә. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Япония-Татарстан бәйләнешләре турындагы конференциядә катнашучы бер төркем галим. 23-24 июль, 2018 ел

ул илләрдә бер миллион мөселман яшәгәнгә ышанып та бетмәде, чөнки, чыннан да, бу бик зур сан бит! Шулай ук мин заманында Америкада яшәгән милләттәшебез, Төньяк Калифорния университеты профессоры галимә Азад-Гайшә Рорлихның да бу хакта язып чыгуын хәтерлим. Ул, Америкадагы яшерен архив материалларына таянып, 1945 елга кадәр Япониядә 1 миллион чамасы мөселман яшәвен, аларның күпчелеге японнар булуын, американлылар аларны «сары чума» дип атауларын хәбәр иткән иде. Безгә килеп ирешкән кайбер хәбәрләр буенча, Америка японнарның күпләп ислам диненә килүеннән, Японияненң мөселман иленә әйләнүеннән уттан курыккан кебек курыккан һәм, шул сәбәпле, беренче атом бомбаларын да алар өстенә ташлаган. Заманында мин бу хакта да язып чыккан идем. Дөрес, хәзер Япониядә ислам диненең таралуы турында шактый хезмәтләр бар, әмма алар да кайбер нәрсәләрне әйтеп бетермиләр кебек.

Әйткәнебезчә, Әбрар Кәримуллин бу мәкаләсендә Япониядә татар тарихын шактый тулы ачып биргән, милләттәшләребезнең кояш чыгышы иленә ни өчен күченүләренең сәбәпләрен аңлаткан. Әйе, монда сәяси вазгыять тә, икътисади мәнфәгать тә, бу ике халыкның тарихи-мәдәни яктан бер-берләренә тартылуы да бар, әмма бу тема әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Татарлар Япония тормышында, япон күгендә язгы аҗаган кебек нурлар чәчеп балкыганнар да, үзләре турында яхшы ат, якты эз, зур тарих калдырып, тагы дөнья буйлап таралганнар... Инде дөньяның башка кыйтгаларында тагы ТАТАР булып шытып чыгу өчен, алар, мәңгелек орлыкка әйләнеп, җир шары буйлап сибелгәннәр... Китаплы күчмәннәр булып, дөнья тарихына кереп калганнар...

Әбрар Кәримуллин – әнә шул китаплы күчмәннәрнең байракчысы, юл күрсәтүчесе, милләт тарихын кыйтгалар буйлап барлаучысы һәм киләчәк өчен теркәп калдыручысы булды. Япония турында да ул бик белеп һәм яратып, сокланып язды, бу илнең, япон халкының татарларга күрсәткән яхшылыклары өчен гомер буе рәхмәтле булды. Әмма ул да бу темада барысын да әйтеп бетерә алмады, Тын океан суларыдай тирән һәм иксез-чиксез япон тарихын, япон-татар бәйләнешләрен өйрәнергә аның бер гомере генә җитмәде... Бу изге эшне ул безгә, киләчәк буыннарга калдырып китте. Япон-татарларның тарихи уртаклыгы, милли-мәдәни нигез-матрицаның берлеге, нәсел күзәнәкләрендә сакланган генетик кодның бер тамырдан булуы турында киләчәк галимнәре зур фәнни хезмәтләр язар әле! Әбрар ага кебек үк, мин дә моңа ышанам... ■

Терелəй күмелгəн эшкуар һəм имам-хатыйп Хəбибрахман Арсаев

Габделбəр Ризванов

Хəзер инде дөнья картасыннан юкка чыккан Яңа Мəңгəр авылында XIX гасырда Лотфулла Арсаев исемле хəзрəт яшəгəн. Ул Төркиядə 13 ел дин гыйлеме өйрəнə, шунда ук, əле сабыйлыгыннан да аерылмаган, 13 яшьлек Гөфрияне кəлəш итеп ала. Алар хəзерге Арча һəм Әтнə районы чигендəге Яңа Мəңгəр авылында матур гомер кичерə, биш ир, ике кыз бала тəрбиялəп үстерə. Сүзебез Лотфулла хəзрəтнең кече улы Хəбибрахман турында.

ТӨРКИЯ ҺӘМ ШВЕЙЦАРИЯДӘ БЕЛЕМ АЛУ. ХӘБИБРАХМАН – ИМАМ ҺӘМ ИГЕЛЕКЛЕ ЭШКУАР

Төпчек бала Хəбибрахманны барысы да ярата. Җиде яше тулганда əнисе улын үзенең туган якларына – Төркиягə җибəрə. Хəбибрахман дин сабагын, əтисе кебек үк, бик тəфсиллəп шунда өйрəнə. Әнисенең туганнары, балада белемгə хəвəслек барын сизеп булса кирəк, Хəбибрахманны ике ел Швейцариядə дə укытып кайтара. Ул анда хокук белгечлеге буенча белем ала. Хəбибрахман, 18 яше тулгач кына, чит иллəрдə зыялы, затлы шəхес буларак тəрбиялəнеп, туган авылы Яңа Мəңгəргə кайта. Нурулла мулла гүр иясе булгач, Яңа Мəңгəр авылы картлары 1909 елның 30 октябрендə шəригатьне яхшы белүче Хəбибрахман Арсаевны имам һəм мөгаллим итеп сайларга карар кыла.

Авыл өчен генə түгел, Казан өчен дə бик кирəк була укымышлы Хəбибрахман. Яңа Мəңгəр мулласы Казан мəдрəсəлəренең берсендə шəкертлəргə белем бирергə дə өлгерə. Тора-бара аны шəһəр тормышы сəүдəгəрлек һөнəренə дə тартып кертə. Хəбибрахман сабын белəн сəүдə итүне җайга сала. Зур булмаган цех та ачып җибəрə. Якташларына, аеруча мохтаҗларына сабын алып кайтып өлəшə торган була ул. «Алланың рəхмəте яусын, гомерегез гел рəхəттə үтсен», – дип дога кыла аңа ярлы-ябага.

ӨЧ ХАТЫН БЕЛӘН ТОРМЫШ. ХӘБИБРАХМАН – 25 БАЛА АТАСЫ

Хəбибрахман Яңа Мəңгəрдəн ерак түгел Мөндеш дигəн авылда мал-мөлкəтле гаилəдə туып-үскəн мулла кызы Хəдичəгə өйлəнə. Аларның бер-бер артлы Җəмил, Камил, Мөнир, Искəндəр, Идрис, Мөнəвəрə, Ильяс – барлыгы тугыз баласы дөньяга килə. Мөндеш авылындагы үтə дə чибəр Мəймүнəгə дə күзе төшə Хəбибрахманның.

Яңа Мәңгәр авылы урыны

Озак та үтми аны икенче хатынлыкка ала. Мәймүнә дөньяга ике бала тудыра. Түбән Аты авылыннан Маһрибикә дә буй җиткереп килә торган кыз була. Хәлле мөселманга дүрт хатын алырга мөмкин дип, Хәбибрахман Түбән Аты мулласы йортына яучы җибәрә. 17 яшьлек кызның исә өченче хатын булып төшәргә уй-хыялында да юк. Яучы килеп сүз башлауга ук ул йортларының икенче катына менеп, язмышының ничек булачагын фаразлый. Әгәренки яучы йорттан төенчек күтәреп чыгып китсә, кыздан башка да әти-әнисе ризалык биргән дигән сүз. Гөнаһ шомлыгына каршы, саубуллашканда кыз яучы кулында төенчек күрә. Маһрибикә, һичнәрсә белештермәстән: «Өченче хатын булганчы, үлемем хәерлерәк», – дип, икенче каттан урамга сикерә. Аягын, кабыргасын сындыра.

Хәбибрахман исә авыру кызга ярдәмен күрсәтә. Маһрибикә аягына басқач, кабаттан яучы җибәртә. Ниһаять, ризалашалар. Хәбибрахманның әнисе яшь киленне: «Балны чеметеп кенә капты, бармагын онга тидереп тә карамады, бик тә җебегән булыр ахры», – дип каршылый. Хәдичә абыстай көндәшенә мөлаем йөз күрсәтә. Яшь киленнән беренче булып Камил дөньяга аваз сала. Икенче балага Мөнир дип исем кушалар. Аннан Сәлмән, Фәүзи, Нәфис,

«Хәзер Совет власте, ике хатын белән яшәү тыела», – дигәч, Хәбибрахман үз өенең бакча башына өй салып, Мәймүнәне аера, Маһрибикә белән генә яшәп кала. Көннәрдән беркөнне аңа: «Калган гомереңнең тыныч үтүен теләсәң, колхоз оештырырга булыш», – дип шарт куялар.

Габделмәннан, Мәсгут, Әсгат, Әнвәр, Нурия, тагын Әсгат, Мәсгут... Шулай итеп, өч хатынлы Хәбибрахман 25 баланың әтисе була. Абыстайларның һәрберсенең үз кучеры, үз асравы бар. Хатыннары Яңа Мәңгәрдә дә, күрше-тирә авылларга да аш-суга бергәләп йөри. Кече хатыннар Хәдичә абыстайның сүзеннән чыкмый.

БЕР КӨНДӘ – ҖИДЕ МӘЕТ

Революциядән соң, коммунистлар Хәбибрахманга бай булуын, муллалык, сәүдәгәрлек итүен гел искәртеп тора. Кайгы-хәсрәт тә янәшәдә генә йөри. Холера зәхмәте Хәдичәнең, аннан туган өч баланың, Мәймүнә тапкан бер баланың, Мәһрибикә куенындагы ике баланың гомерен бер үк көнне өзә. Йорттан берьюлы җиде мәет чыга. Хәбибрахманның сәүдәгәрлек шөгыле белән Казанга киткән вакыты була бу. Кайтса, авылны солдатлар чолгап алган, керү-чыгу тыела. Хәбибрахманга авыл читендә әрлебирле йөрүдән башка чара калмый. Ниһаять, ул кайгы-хәсрәткә уралган йортына кайтып ава. Бик яхшылап, сабынны мулдан тотып, урын-җирне, йортны юалар.

«ЯХШЫЛЫК БЕЛӘН ОЛАК»

«Хәзер Совет власте, ике хатын белән яшәү тыела», – дигәч, Хәбибрахман үз өенең бакча башына өй салып, Мәймүнәне аера, Мәһрибикә белән генә яшәп кала. Көннәрдән беркөнне аңа: «Калган гомереңнең тыныч үтүен теләсәң, колхоз оештырырга булыш», – дип шарт куялар. Намаз вакытында авыл картларын колхозга керергә үгетли Хәбибрахман. «Элеккегә кайту юк. Большевиклар ныгып килә. Әйдә, берләшик колхозга», – дип нотык тота ул. Үзе дә бар мөлкәтен диярлек колхозга тапшыра, дөресрәге, тапшырырга мәҗбүр ителә. Хәбибрахман 70ләп умарта тота. Шуның яртысын колхозга бүлеп бирә.

«Башкасына исем китми, умарталарым бик кызганыч, шуңа гына күңелем сызлана», – ди торган була Хәбибрахман өйдәгеләренә. Әтиләре ризалыгы белән өлкән уллары Җәмил һәм Камил большевиклар сафына баса. Мулла малайларының коммунист булуы кайберәүләрнең ачуын гына кабарта. Җаен туры китереп, Җәмил белән Камилне бик каты кыйныйлар. Хәбибрахман мулла ике ут арасында кала, аның үзенә дә төрле яклап янау башлана: совет власте яклылар да, советка каршылар да аны эзәрлекли. Хәзрәтне аеруча якын күргән берәү: «Бүген сине кулга алачаклар. Мөмкин булса, качу ягын кара», – дип, сер ача. Бер көн генә элек: «Авылдан яхшылык белән олак», – дигән кисәтү кәгазе дә алган була мулла.

ЯҢА МӘҢГӘРДӘН ИКЕ МӘРТӘБӘ ҺИҖРӘТ

Эзсез югала Хәбибрахман. Шул кичне аны эзләп кат-кат киләләр. Берничә көннән исә, Хәбибрахманның йөкле хатыны Мәһрибикәне алып китәләр. Шулай да аны Әтнәдән ары алып чыгарга өлгермәгән булалар. Әтисе, йөри торгач, кызын үз йортына кайтару бәхетенә ирешә. Мәһрибикә: «Хәбибрахман мине эзләмичә калмас», – дип уйлап, кабат Яңа Мәңгәргә китә. Кем якты чырай күрсәтсә – шунда, күбрәк вакытын кучерларында кача-поса яшәп тора.

Хәбибрахман, югалуына унбер ай дигәндә, төн уртасында авылына кайтып төшә. Исәбе – гаиләсен алып Урта Азия якларына китү икән. Хатыны, балалары, берничә

Икенче урында кабер әзерлиләр дә, кичләтеп мәетне алырга киләләр. Бу якларда ком булганлыктан, ләхет алынмый: каберне берникадәр казып төшәләр дә, такта, агачлар куеп, мәетны кирпеч белән каплыйлар икән. Ходайның рәхмәте, кирпечләрне аралаулары була, мәет башын күтәрә.

туганы белән шул ук төндә ерак сәфәргә кузгалалар. Килеп, чүлләрдә каңгырап йөри торгач, бер урында төпләнергә уйлый Хәбибрахман. Бертуганы Абдулла белән фикерләшеп, юлны Төркиягә кадәр дәвам итәргә булалар. Пароход кузгалып берникадәр ара узуга, ыгы-зыгы, атыш, мәхшәр башлана. Куркудан диңгезгә ташланучылар да була. Пароход кире борыла. Хәбибрахманныкылар барысы да исән-имин ярга чыга. Абдулланыкылар да исән, әмма гаилә башлыгы үзе генә күренми. Дөнья бетереп Абдулланы эзлиләр. Юк, табылмый. Өч көн, өч төн диңгез ярында утыра аның гаиләсе. Пароходта мәхшәр вакытында диңгез төбенә киткәндер, дип фараз кылалар. Айлар, еллар үтсә дә Абдулла турында хәбәр булмый. Аның гаиләсен кайгырту да Хәбибрахман хәзрәт өстенә йөкләнә.

Хәбибрахман муллалыгын ташламый. Коммунист уллары да эш таба. Яңа Мәңгәрне сагына-сагына гомер кичерә гаилә. Маһрибикә аеруча сагышлана. Татарчадан башка тел белми, белергә теләми дә. Урамда үзбәкчә, кыргызча, төрекмәнчә ярыйсы гына арлашырга өйрәнгән балалары белән өйдә бары тик татарча гына сөйләшә. Килгәндә бер яше дә тулмаган Нурия барысын да уздырып җибәрә: әтисеннән көненә берәр сәгать дин сабагы ала, урысчага да теле ябышып тора. Илдә паспорт бирү башлангач, һәркем совет документын туган җирендә алырга тиеш, дигән хәбәр тарала. Хәбибрахман Яңа Мәңгәргә хат юллый, үзе исә: «Язган адресым буенча килеп тотмасلармы?» – дип шөбһәгә төшә. Яшәү урынын тагын үзгәртәләр. Куркып-өркеп, шулай да туган ягыннан хат алу өмете белән яши Хәбибрахман. Якташларыннан: «Кайт, Хәбибрахман абзый, сине җәберләүче булмас», – дигән хәбәр алгач, бөтен барлыгын җыеп, әҗәлем туган якта булыр, дип юлга кузгала. Хаттагы: «Сез кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү исемлегеннән чыгарылдыгыз», – дигән сүзләр дә өмет чаткысы уяткан була анда. Хәбибрахман Яңа Мәңгәргә юл тота, уллары исә, килгән җирләрендә яшәп кала.

Кайтса, дини һәм хокукый белемгә ия, эшкуарлыкка хирыс Хәбибрахманның берәүгә дә, совет властена бигрәк тә, кирәге юк икән. Колхозга тапшырылган малы исраф ителгән, берничә катлы йорты җимерелә башлаган. Ул калдырган байлыктан берәү дә баемаган, ә киресенчә, халык хәерчелек упкынына баткан... Умарталык та ташландык хәлдә, аны карый белүче дә юк. Менә шулчакта инде ул берничә авылдашын умартачылык эшенә өйрәтә. Үзе исә Олы Мәңгәрдәге пекарняда эшли. Берничә ир-ат кача-поса гына аннан дин сабагы да укый. Әмма дөньялар барыбер тыныч түгел, «халык дошманы» дигән яманат артыннан һаман сөйрәлеп килә. Алып китү белән дә янаулар булгалап тора һәм Хәбибрахман, ел ярымнан соң, тагын чит-ят җирләргә китәргә тәвәккәлли. Бу юлы инде Каракалпак якларына юл тота. Аның авылдан соңгы һәм мәңгегә чыгып китүе була бу. Күңел кыллары нечкәрә, үзәк өзгәләнә, шулай да китәргә кирәк. Хәбибрахман күңелен сагыш-моң баса.

ТЕРЕЛӘЙ КҮМЕЛҮ

Бу вакытларда Хәбибрахманның иң өлкән улы Җәмил Каракалпакның Чимбай шәһәрендә НКВД начальнигы итеп билгеләнә. Хәбибрахманга зур таяныч була ул. Әмма тора-бара коммунист Җәмилнең «халык дошманы» улы икәнлеген белеп алалар,

шуңа бәйләп булса кирәк, кайбер «килешмәгән яклары» да ачыклана – Җәмил кулга алына. Аның артыннан ук Хәбибрахманны да эзләп табалар. Башка туганнарына да хәвеф яный. Хәбибрахман, үзенә һәм улына булган җәбер-золымның хаксызлыгын исбатлау ниятеннән, адвокат яллый. Аклану өчен бөтен кирәкле материаллар әзерләнә.

Төрмә дигәннәре читән белән генә әйләндереп алынган. Хатыны, балалары Хәбибрахманны көн дә күрә диярлек. Ул исә: «Алла боерса, эш җайланыр, адвокатта дәлилләр җитәрлек, ирекә чыгарырлар», – дигән өметен өзми. Көннәрдән бер көнне ул юкка чыга. Өйдәгеләренә «үлде» дип хәбәр салалар. Улы Җәмил белән шактый дустанә мөнәсәбәттә булган бер милиционер аның кайда күмелгәнен дә әйтә. Маһрибикә төш күрә: аны бик явыз бер карчыкка фатирга керткәннәр дә Хәбибрахманга, коткарчы, шул явыз карчыктан, дип ялвара икән. Көн-төн яшь түгүләр дәвам итә. Прокурорга барып карагыз әле, дип киңәш бирәләр аңа. Кызы Нурия белән бергәләп китәләр. Нурия әнисенә тәрҗемәче буларак та кирәк була. Фамилияне ишетүгә үк, прокурор куркуга төшә һәм: «О-о, Арсаевы, Арсаевы...» – дип кабатлаудан ары уза алмый. Шуннан кызга карап әйтеп куя: «Әниеңә төшендер, балаларын ятим калдырасы килмәсә, мәетне кузгату турындагы уйларын башыннан чыгарып ташласын!» Шулай да, Хәбибрахманны, кешегә белдермичә, рөхсәтсез-нисез генә башка җиргә күмәргә кирәк, дигән фикергә киләләр. Бу эштә аларга берничә милиционер да булыша. Икенче урында кабер әзерлиләр дә, кичләтеп мәетне алырга киләләр. Бу якларда ком булганлыктан, ләхет алынмый: каберне берникадәр казып төшәләр дә, такта, агачлар куеп, мәетны кирпеч белән каплыйлар икән. Ходайның рәхмәте, кирпечләрне аралаулары була, мәет башын күтәрә, Маһрибикә кочаклап алуга, авыз-борыныннан кан китә. Халык дошманы исемлегендә йөргән Хәбибрахман тере килеш күмелгән булып чыга. Соңрак табиб та моның шулай булганлыгын раслый. Кабердән чыгарып, ундүрт көн үткәннән соң гына фани дөнья белән мәңгегә хушлаша Хәбибрахман. Кешечә җирләнүенә бер ай дигәндә, Каракалпакстан Югары судыннан аның аклануы турында хәбәр алына.

***

Заманының иң зыялы кешесе, хәләл көче белән гомер кичергән эшкуар һәм имам Хәбибрахманның фаҗигале тормышы бүгенгеләргә дә, киләчәк буынга да барып ирешсен иде.

Кызганыч, кайчандыр мал-мөлкәтле һәм бу байлыкны да авыл-колхозлар үсеше өчен кызганмый биргән Хәбибрахманнар яшәгән Яңа Мәңгәрдән 1990 елларда соңгы кеше күченеп китте. Тупыл агачлары, урамнарны, нигез урыннарын басып киткән «америка өрәңгесе», кура, кычыткан һәм, әлбәттә, Арсаевларның әти-әнисе, әби-бабалары һәм башка мәңгәриләр җирләнгән зират кына кайчандыр авыл булганын искә төшерә. Бу – дөньяның гаять моңсу һәм шомлы тынлыкка өркетелгән урыны. Гүя бирегә Лотфулла, Хәбибрахман Арсаевлар һәм башка игелекле затларның рухы кайтып: «Кайда биредә без иман нурына төргән халык? Кайда безнең хәләл көчебез белән тапкан мал-мөлкәт? Кайда авыл, колхоз? Алар ни өчен булдыксыз, эшлексез һәм наданнар кулында исраф ителеп, юкка чыкты? Урам һәм болыннарда йөгереп үскән сабыйларның варислары кайда?» – дип сызлана кебек... ■

Риза казый нәселе

(Ризаэддин Фәхреддиннең кызы Әсма Шәрәф белән аралашу тарихы)

Рәфкать Шаһиев

Әсма апа

Соңгы елларда күренекле галим, мәгърифәтче, журналист һәм әдип, тарихчы, фәлсәфәче, дин эшлеклесе һәм педагог Ризаэддин Фәхреддин турында шактый гына язмалар дөнья күрде, китаплар басылды, диссертацияләр якланды.

Мин галим белән ныклап торып кызыксына башлаганда, аның кече кызы Әсма һәм оныгы Арслан Шәрәфләр исән-сау иде әле. Миңа мәшһүр авылдашымның турыдан-туры варислары белән хат аша хәбәрләшергә һәм очрашып күрешергә насыйп булды.

Бу минем бик зур бәхетем. Риза казый турында бала чактан ук ишетеп үстем. Кечкенә чакта әбием авыл зиратына ияртеп бара иде. Иске өлешендә Чупай ташы белән төрбәләп алынган борынгы каберлекне күрсәтеп: «Монда бик укымышлы кешеләр күмелгән», – дип сөйләргә яратты.

Сигезенче сыйныфта укыганда, галимнең 125 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә, мәктәпкә галимнәр Әнвәр Хәйри белән Марсель Әхмәтҗанов килде. Укучылар, авыл

Арслан Шәрәф әнисе Әсма Шәрәф белән. Казан, 1957 ел

халкы белән очрашып – Ризаэддин Фәхреддин, аның эшчәнлеге, гаиләсе турында сөйләп, аңлатып китте алар.

Шул көннән башлап, үсмер күңелдә олугыбыз хакында күбрәк беләсе килү теләге яшәп килде. Вакыт уза торды, көтмәгәндә кулыма 1991 елгы «Сөембикә» журналының 5 нче саны килеп керде. Анда Диләрә Зөбәерова мәкаләсенә җавап хаты басылган, авторның исеме Әсма Шәрәф дип күрсәтелгән иде. Уч төбе зурлыгындагы әлеге язма бик катгый, кырыс рухта язылган. Язмага карап та авторның нindirәк кеше булуын, холкын чамалау авыр түгел иде. Күңелгә: «Бу кешене ничек тә бер күрәсе иде», – дигән тыелгысыз уй төште.

Әлмәт районы Яңа Кәшер мәктәбендә эшләгән чагым иде. Миңа, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары буларак, Казанга укытучыларның белем күтәрү курсларына барырга тәкъдим иттеләр. Форсатны кулдан ычкындырмыйча, мин, Әсма апа белән очрашуны да күздә тотып, күчтәнәчләр белән Казанга киттем.

Берничә көн узгач, Казанның элеккеге Куйбышев мәйданындагы белешмәләр бүлегенә барып, Әсма Ризаэддин кызы Шәрәфнең адресын сорадым. Ләкин моны төгәл ачыклау җиңел эш түгел иде. Бүлектәге марҗа хатыннары бөтен ваклыкларына кадәр төпченеп, аның туган елы, торган районы белән кызыксынды. Әлбәттә, ул кадәр мәгълүмат туплаган булсам, мин алар янына бармаган да булыр идем. Әтисенең туууына 130 тулудан исәпләп, Әсма апаның яшен: «Йөз тирәсе», – дидем. Ханымнар да, көлешеп: «Һай, безнең шәһәрдә андый кеше булырмы икән, фамилиясе дә сәер – ни Шәрәфиева түгел, ни Шәрәфетдинова...» – диештеләр. Шулай да, озак көтәргә туры килмәде. Әсма апаның адресын табып бирделәр: «Аңа сиксән биш яшь кенә әле», – дип елмаештылар.

Мин тиз генә Ленин бакчасы каршындагы пединститут тулай торагына йөгердем. Әнием әзерләп җибәргән шәльяулыкны, бер кап чәйне һәм үземә дигән ярты литр каймакны алып тукталышка юнәлдем.

Менә мин: «Кем каршылар, ничек итеп сүз башларга?..» – дигән уйлар белән үземә кирәкле йортның дүртенче катына күтәрелеп, кыңгырау төймәсенә бастым. Ишекне өлкән яшьләрдәге бер ир кеше ачты. Ләкин ул без ишетергә күнеккән: «Сез кем? Сезгә кем кирәк?» – дигән сорауларны бирмәде. «Әйдәгез, үтегез», – дип, өйгә дәште. Шуннан соң гына, эчкә үткәч:

– Сез кем буласыз? – дип сорады.

– Миңа Әсма апа кирәк иде. Мин Ризаэддин Фәхреддиннең авылдашы, Кичүчаттан булам, – дидем.

Мине каршылаган кеше – Риза казыйның оныгы, күренекле галим Галимҗан Шәрәфнең улы – Арслан Шәрәф иде. Монысын танышкач белдем. Ул миңа башмаклар китереп бирде дә:

– Әннә, сиңа килгәннәр. Кичүчаттан, – диде.

Шактый олыгаеп килгән ир кешенең «әннә» дип дәшүе миңа гаять сәер тоелды.

Шулвакыт залда кыска итеп киселгән чал чәчле, түшенә кызыл ташлы брошка кадаган, мин күз алдыма китергән авыл әбисенә аз гына да охшамаган, шатлыгы йөзенә бәреп чыккан олы яшьләрдәге бер ханым күренде. Бу – Әсма апа Шәрәф иде.

– О-о, Кичүчаттанмыни сез?! Минем әле бер дә Кичүчат кешесен күргәнем юк иде, – дип, көр тавышы белән бүлмәне яңгыратты. Курештек. Аның беркадәр каушаганлыгы сизелә иде.

Арслан абый, безгә комачауламас өчен, күрәсең, бүлмәсенә кереп китте. Әсма апа белән залга уздык.

Алып килгән күчтәнәчләремне Әсма апага бирдем, шәльяулыкны таратып башына яптым. Барысы өчен дә рәхмәт әйтеп, күчтәнәчләрне бер читкә алып куйды. Аннан

соң читләтеп кенә сораулар биреп, минем кем булуым, бирегә нинди максаттан килеп чыгуым белән кызыксынды. Әтиләре – күренекле авылдашым Ризаэддин Фәхреддин турында мәкалә язарга, киләчәктә музеен ачарга теләвем турында әйттем. Авыл баласы кайда да авыл баласы булып кала шул. Беркатлыгым белән бөтен күңелемдәгене ачып салдым.

Сүз барышында ул үзенә «Әсма ханым» дип дәшүләрен искәртте. Яшен тизлеге белән башымнан «ничекләр генә «ханым» дип әйтермен икән?» дигән уй узды. Үз гомеремдә андый сүзне әйтеп өйрәнмәгән, югыйсә. Шул ук вакытта, минем аңа «әби» дияргә дә телем бармый иде. Кыскасы, кыенсынып кына «апа» дип әйтергә рөхсәт сорадым. Ул каршы килмәде.

Без авыл турында, аның тормышы, кешеләре хакында чәй табыны янында озаклап сөйләшеп утырдык. Әкренләп сүз галимнең гаиләсенә, балаларына, нәсел-нәсәбенә күчте. Кулымда калын гына дәфтәр белән каләм. Тыйнак кына сораулар бирәм, үзем Әсма апаның авызыннан чыккан һәр сүзне язып барырга тырышам. Шунда ул, сөйләвеннән бүленеп:

– Дөреслегенә үзең ышанмаган нәрсәне язма да, сөйләмә дә. Моны исеңдә калдыр. Әткәйнең таләбе шундый иде. Үзе дә шундый булды, безне – алты баласын да шуңа өйрәтте, – диде. – Язмаңны матбугатта бастырганда «Әсма Шәрәф сөйләгәннәрдән» дип язарга онытма. Чөнки син бит моны үзең белмисең, мин сөйлим. Берәү дә сине плагиатлыкта гаепләрлек булмасын.

Инде вакыт шактый соң иде. Мин, саубуллашып, китәргә җыендым. Әсма апа мине ишек төбенә кадәр озата килде. Безнең әле сөйләшәсе сүзләр башланып кына киткән иде. Моны Әсма апа да бик яхшы аңлый иде, билгеле. Форсатны кулдан ычкындырмас өчен, мин дә, Казанга ни өчен килүемне дә онытып: «Иртәгә киләм, каршы булмасагыз», – дидем...

Тулай торакка кайтып керүгә мин Әсма апа сөйләгәннәрнең бер генә сүзен дә төшереп калдырмаска тырышып, акка күчердем.

Әсма апаның тәрбиялелеге, зыялылыгы мине таң калдырды. Аның гадилеге, эчкерсезлеге, сүзгә тапкырлыгы, өлкән яшьтә булуга карамастан, юморга бай булуы, таләпчәнлеге мине бу гаилә дөньясына бөтереп алып кереп китте. Шушы беренче очрашу вакытында булган эчкерсез сөйләшү Әсма апа белән әтисенең туган авылы Кичүчат арасына күпер салды. Янә очрашканда без инде күптәнге танышлар кебек күрештек.

Икенче көнне мин, институттагы укуымны ташлап, соңга калмыйча билгеләнгән сәгатьтә килеп җиттем. Кыңгырау төймәсенә басуга, озак та узмады, ишек чылбырын эләктергән тавыш ишетелде. Ишек сызык кадәр генә ачылды; аннан Әсма апаның елмаеп, янып торган зур күзләре күренде.

– Ә-ә, Рәфкать әфәнде, әйдәгез, узыгыз, – диде ул. Арслан абый эштә, өйдә Әсма апа үзе генә иде. Фатирга тәмле бәлеш исләре таралган. Мин, залга узып креслога утырдам да, газета-журналлар карарга керештем.

Әсма апаның аягы авыртканлыктан, өйдә хәрәкәтләнергә җиңел булсын өчен, Арслан абый аңа тәгәрмәчле җайланма ясап биргән икән. Ул өйдә шуның ярдәмендә йөри иде. Мине, көтелгән кунактай күреп, табынга дәште. (Җөмләдән, Әсма апа аш-суга бик оста иде. Бу уңганлык-булганлыкның әнисе Нурҗамал абыстайдан күчүен сөйли иде.)

Чәйдән соң Әсма апа мине гаять әһәмиятле фоторәсемнәр, төрле документлар белән таныштырды, үзенең истәлекләре белән уртаклашты. Өлкән яшьтә булуына карамастан, Әсма апа бөтен яңалык белән танышып бара, бик күп белә, хәтер диңгезе бик тирән иде. Бер юлы: «Кара, син бигрәк үз булып киттең, мин әле берәүгә дә бу кадәр ачылып китми идем», – дип куйды...

Нурҗамал абыстай кызлары Зәйнәп, Әсма һәм сеңлесе Нургаян белән

Безнең танышлык шулай башланды.

Мин, үземә карата җылы мөнәсәбәт сизгәч, берничә фоторәсемнең күчермәсен ясап булмасмы, дип үтендем.

– Кайбер фотосурәтләр берничә нөсхәдә булырга тиеш. Арслан белән сөйләшеп, синең өчен әзерләп куярбыз. Бәлки, әле өчәү бергә рәсемгә төшү мөмкинлеге дә булыр, – диде Әсма апа.

Монысы минем өчен гел көтелмәгән тәкъдим булды.

Алдан көнен билгеләп, өчәүләп, Татарстан-Киров урамнары чатына урнашкан фотосалонга киттек.

Без килеп җиткәндә, салонны бикләп китәргә җыеналар иде инде. Шулай да, безнең гозергә каршы килмәделәр.

Арслан абый акча түләгән арада Әсма апа белән без рәсемгә төшәргә әзерләндек. Фотограф кызлар Әсма апаны урындыкка җайлап утыртты. Мине артка бастырдылар, кулымны Әсма апаның җилкәсенә куярга куштылар. Шулчакта Әсма апа:

– Юк, юк! Син берүк үпкәләмә, алай кирәк түгел. Алай итеп ак офицерлар хатыннары белән төшкән, – диде.

Барыбыз да бердәм рәвештә көлеп җибәрдек...

Мин Казанга килгән саен Әсма апаларга кереп чыгарга гадәтләндем. Әсма апа да бу очрашуларны көтеп ала иде. Әйткәнемчә, аның хәтере бик яхшы иде. Әтисе сөйләвеннән генә белгән Кичүчат табигатен, аның һәрбер тавын, чишмәсен шундый итеп тасвирлап бирде ки – үзе шунда туып үскән, диярсең! Гомернең узып баруына уфтана иде Әсма апа. Никадәр яшәлгән, дөньялар күрелгән, әмма этисенең кендек каны тамган туфракка аяк басылмаган, бабаларының каберләре зыярәт кылынмаган...

Икенче юлы Казанга барганда, алар безгә кардәш тиешле, дип, авылның бик мөхтәрәм кешесе Әнвәр абый Шакирҗанов, күчтәнәчләр биреп, сәлам җибәрде. Мин күчтәнәчләрне тапшырдым, сәламнәрне җиткердем, Әнвәр абыйның аларга туган тиешле булуын да әйттем. Әсма апа рәхмәт әйтеп күчтәнәчләрне алып куйды да:

– Теге елларда безнең бер туганыбыз да юк иде, – диде, кырыс кына. Аннан тавышына йомшаклык өстәде:

– Икенче юлы җиде буын бабаларын язып җибәрсен.

Әйе, хаксызга рәнҗетелгән елларның тәэсире иде бу. Рәхмәт әйтте, ә сәлам юлламады. Мин, кайткач, боларның барысын да Әнвәр абыйга сөйләдем. Ул белгән кадәр бабаларын барлап-язып, хатны минем аша Әсма апага җибәрде. Күрешкәч тә, Әсма апа СССР картасы зурлыгындагы шәҗәрәне өстәл өстенә җәеп салды, икәүләп Әнвәр абый язып биргән бабайларны эзли башладык: Шакирҗан, Әхмәтҗан, Фәсәхетдин...

– Әнвәр туганга барыбыздан сәлам күндерерсең, – диде Әсма апа, шәҗәрәдән аерылып. Аның нәсел җебе ачыкланган, күңелгә тынычлык ингән иде.

Туксан икенче елның октябрь аенда мәчет ачу тантанасына чакыргач, Әсма апа бик куанып риза булды. Машина белән килеп алуны, кайтарып куюны җайлаган идем. Танышлары, туганнары каршы килсә дә (яшь кыз түгел лә): «Мондый форсат кабатланмаска мөмкин. Ата-баба туфрагын барып күрү алты баланың соңгысына, миңа насыйп булган икән, ничек тә барам! Алла ярдәменнән ташламас, изге туфрак савыктырыр әле. Аннан соң инде үлсәм дә үкенмәм», – диде ул.

Бу сәяхәткә Әсма апа белән бергә Арслан абый, Ризаэддин Фәхреддиннең энесе Салихның улы Җәүдәт абый, Нурҗамал абыстайның сеңелесенең кызы Асия апа Әсфәндиярова (танылган артистка Шаһсәнәм Әсфәндиярованың туганы), галимнәр Әнвәр Хәйри белән Марсель Әхмәтҗанов та кузгалдылар. Без авылга кайтып кергәндә караңгы төшкән иде инде. Кунакларны авылдашлар, минем әти-әнием, туганнарым каршылады.

Галимнәр шәһәр кунакханәсенә урнашты. Җәүдәт Фәхреддиневне кардәшләре Әнвәр абыйлар алды. Әсма апа, Арслан абый, Асия апа безгә кайтты. Татарда кунак – мунчасыз, бәлешсез булмый. Әлфия апам Казан ханымнарын мунча кертте. Кунакларга әнием пешергән ит бәлеше, авыл катыгы белән каймагы да бик ошады. Үзләрен бик гади тотканга, эчкерсез аралашканга күрә бернинди киеренкелек тумады. Көндезен дә, кичен дә бездән кеше өзелмәде.

Өч көн кунак булып, бу очрашудан яшәү көче алып, этисенең туган авылын күреп, якташларының җылы карашларын тоеп, Кичүчатлыларга бик рәхмәтле булып китте Әсма апа. Киткәндә: «Үлгәнче, һәркөнне искә алырлык очрашу булды бу», – диде.

Мин Казанга бара алмаган чакта ике араны җылы хатлар бәйләп торды.

Әсма апа бер генә хатны да җавапсыз калдырмый иде. «Инде вакытың тар икән, син, әлегә вакытым юк, булу белән язып салырмын, дип булса да хәбәр сал», – ди торган иде. Һәр сүзгә аерым бер мәгънә төсмере өсти-өсти, һәр сүзне уйлап, кирәклесен генә сөйли иде. Иң күрә алмаганы – ялган, буш сүз булды.

Ул этисенең кабат халыкка әйләнеп кайтуына, якташларының онытмавына чиксез куанып яшәде.

Инде хатирәләремнән бүленеп, укучыларга Әсма апаның, Арслан абыйның миңа атап язган хатларын тәкъдим итәм.

Әсма Шәрәф хатлары

Рәфкать!

Бу арада озын хат язам, әзрәк бушый төшкәч. Лениногорскиларга адресны бирергә ярый. Кызганыч, алар да – «Шәлчеле»ләр дә тантанада булырга тиешләр иде. Ничек Таһир әфәнде хәбәр итәргә уйламаган. Син җибәргән Әлмәт газетасына үземнең фикерләремне яза башлаган идем, бетереп булмый, тормыш бик мәшәкатьле, вакыт җитми, авырып алгаларга туры килә. Кичүчатны, аның халкын гел күңелемдә тотам. Сезнең анда торуыгыз да бик ямьле хәл. Юкса, син килеп тапмасаң, мин шул көе, белмичә «киткән» булыр идем. Рәхмәт сиңа! Арслан исемемне «ы» хәрефсез язсын, диде. Шулай, «Арслан» дип языла. Русча да, татарча да. Яшь карточкаларны үзеңә бирермен. Минем «ямьсез» фотоны күңеле булсын дип «чибәр» дигәннәрдер инде.

Барчагызга күп сәлам, яхшы теләкләр.
31/XII

Исәнме-саумы, Рәфкать туган!

Сәлам соңында ике зур рәхмәт: берсе хат өчен, икенчесе газетада басылган мәкаләң өчен. Мәкалә безгә бик ошады. Яхшы язылган, кирәк төрле язылган. Мактанган, күпергән, кирәкмәгән сүзләр дә юк. Чын, дөрес язма. Бик яхшы иткәнсең «мин сөйләгәннәрдән алынды», дип. Һичбер кешедә шик-шөбһә, берәр кешенекен күчереп язган дигән уй калмаслык. Әгәр дә шундый язулар белән шөгыльләнсәң, минемчә, киләчәктә яхшы журналист, язучы булырлык өмет бар. Мин шулай уйлыйм. Әлмәтләр бик яхшы газета чыгаралар икән. Инде синең хатка: әгәр дә Кичүчат зыяратындагы ташларны (вакытыгыз булса), сакланган хәтләләрен булса да, рәсемгә алып булса, бик яхшы булыр иде. Кичүчат фотоларына тулылык бирә торган күренеш. Мәчет төзелеп килгәне дә күңелле хәбәр. Миңа аның архитектурасы бигрәк ошаган иде. Стандарт мәчет түгел. Кичүчатка дан бирә торган. Мәчетнең ачылуы да бәйрәм шикелле үтсә иде. Шәлчеледән җавап килмәдеме? Анда мәдрәсә дә (бинасы) юктыр инде. Әле уйлап торам, хәзерге көнне 75-80 яшьтәге Кичүчат кешеләре 26 елда әткәй кайтканда бала-чага, яшүсмер булганнар. Әткәй сөйләгәндә: «Барган җирләргә авылдашлар белән балалар да күпләп ияреп (арттан гынадыр инде) йөрделәр», – ди иде. Шунда олы яшьтәге берәр кеше юкмы икән? Әгәр Фәсәхетдиннең тармагы булса, Әнвәргә Фәсәхетдин – бабасының бабасы буламы? Инде Мәмәт. Гөлнәзирә ханым белән күрешүең яхшы булган. Минем исәп: әгәр дә ул ханым минем хатка җавап итеп, Кичүчат музеена җибәрелгәннәрне кайтарырга вәгъдә бирсә, хәзергә үзләренең музей-почмакларында сакланып торсын. Сакланырга файда (әйбәт) булыр. Әниеңә күп сәлам.

Үзеңнең эшләр ничек? Миңа сәлам җибәргән авылдашларыңа миннән сәлам – мине бар дип белгәннәргә. Июнь аенда Казанда Бөтендөнья татар конгрессы [съезды] булачак. Читтән күп кунаклар киләчәк, диләр. Кичүчатның авыл хуҗалыгы эшләре ничек? Чәчү, мал-туар фермалары? Колхозда эшләр барамы, әллә җирләрен сатып бетерәләрме? Җиләк-җимеш, бакчачылык?

Син алып килгән Гүзәлнең ([исеме шулай] шикелле) нәтиҗәсе ничек булган? Вакытың булганда, яңа хәбәрләр булса, язгалап тор.

Сәлам белән, Әсма апа.

P.S. Синдә безгә кайтара торган фотолар бармы?

Дәвамы бар ■

БҮРЕ КЫЙССАСЫ

Рәсим Хәбибулла

Коръәндә Аллаһ Тәгалә: «Нинди урында булсагыз да, сезгә үлем ирешер, хәтта күкләргә ашкан бик таза төзелгән бина эчендә булсагыз да», – ди (4.78). Гомумән, Аллаһ безне бик күп аятьләр аша кисәтеп, билгеләнгән вакытта һәммәбезгә әҗәл килəчәген аңлатып килә. Бу кыйсса – Аллаһ Тәгаләнең әйткән сүзе һәрвакыт үтәләчәге турында. Аны олуг дин галимебез һәм татарның бөек шагыйре, Казан ханлыгы чорында яшәп халкына фидакарь хезмәт иткән Мөхәммәдьяр үзенең «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге») исемле поэмасында язып уза. Әлбәттә, поэма белән шигъри калыпта танышучылар да булгандыр, әмма, укучыларга аңлаешлы булсын өчен, мин аның эчтәлеген хикәяләп кенә чикләнәм.

Мөхәммәдьяр. Канәфи Нәфыйков рәсеме

Атаклы бер шаһ беркөнне үзенең сакчылары белән төнге шәһәрдә йөрергә чыга. Шулай иркенләп һава сулап йөргәндә ерак түгел бер йортта ут күрә. Шаһ, кызыксынып йорт эченә уза. Анда бик зур туй бара икән. Читтәрәк йорт хуҗасының үсмер кызын күрә, ул кыз бик чибәр, бик сылу була. Кыз янында ике кеше нәрсәдер язып утыра. Бу кешеләр шаһның күзенә бер күренәләр, бер юкка чыгалар. Шаһ куркуга кала, болар бик шикле адәмнәр, ахры, дип уйласа да, яннарына килеп сорарга җөрьәт итә: «Аллаһ хакы өчен, әйтегезче, сезне кемнәр дип аңларга?» Алар: «Без Аллаһның әмерен язучылар. Шушы өй хуҗасының кызы ундүрт яшькә җиткәч, аны бүре ашаячак», – диләр. Шаһ бик каты хәсрәткә төшә, шундый чибәр һәм гүзәл кызны бүрегә ашатмаска иде, дип борчыла...

Шагыйрь Мөхәммәдьяр бу кызның гүзәллеген болай тасвирлый:

Карарга кереп кем салса аның күркенә күзен,
Куәте җитмәй хәйран калыр, тыя алмас үзен.
Булыр ул ягымлы вә гүзәлләрдән гүзәл җан,
Аның өчен, һичшиксез, корбан булыр ничә җан.
Һәм йөзе аның кичә генә туган айга тиң,
Сүзе балдай татлы, юатучы мәгъшукага тиң.
Матурлыгы иртәнге таң кебек балкыйдыр,
Аның озын чәч толымнары гүя төн карасыдыр.
Көндезге йөзеннән аның ай вә кояш оялыр,
Ирененең матурлыгы Мисыр кызын каушатыр.

...Шаһ, кызның әти-әнисенә зур мал биреп, үсмерне үзенә кыз итеп алып кайта. Ул аны үз баласыдай күреп ярата, кадер-хөрмәттә генә яшәтә. Әмма бүре турындагы уй барыбер күңеленә тынгы бирми. Ул үзенең шаһлыгында булган барлык осталарны чакырта, алардан бик матур бер сарай салдырта. Нигезен тирән казытып, тимер һәм таш белән ныгыттыра. Диварларга тәрәзә уйдырмый, эченә бик күп шәмнәр куйдырта. Диварның эчке якларын энҗе-мәрҗән белән бизәтә. Сарайның эчендәге бүлмәләргә бик күп ризык, су, бал-шикәр китертә. Инде барысы да хәстәрләнеп беткәч, баланы китереп аңлата: «Кызым, сине ундүрт яшеңдә бүре ашарга тиеш, дип әйттеләр, син шушында бер ел тор, монда бүре керә алмас. Исән калсаң, мин сиңа күп байлык һәм тәхет бирермен, бәхетле булырсың» – ди.

Кыз, риза булып, шушы сарай эченә кереп урнаша. Сарайның тимер ишеген зур-зур йозаклар, ташлар белән ныгытып бикләп куялар. Бераз вакыт узгач, шаһ, ямансуламасын, дип, кыз янына бер гади генә хезмәтче кызын китертә. Ике яшь бала бергә уйныйлар, җырлыйлар, бәетләр әйтешәләр. Шулай көн арты көн узып, бер ел үтеп тә китә.

Көннәрдән беркөнне иптәш кызы шаһ кызыннан: «Сине нигә шаһ үз сараеннан аерып, монда бикләп куйды, син берәр ярамаган эш кылдыңмы әллә?» – дип сорый. Кыз серне чишә, белгәннәрен дустына сөйли. Шулвакыт хезмәтче кызы, көнчелегенә чыдый алмыйча, Аллаһка ялвара: «И Раббым, мине бүре итсәң иде!» Аллаһ кызның догасын кабул итә һәм аны бүрегә әверелдерә. Бүре шаһ кызын ашый, кыздан сөякләр генә кала.

Кызга ундүрт яшь тулып узды инде, кызны дөньяга чыгарырга вакыт, дип, шаһ сарайга юл тота. Бу тамашаны күрергә бихисап халык җыела. Ишекне ачып җибәрәләр, ә анда шаһ кызының сөякләре һәм бүре генә була.

Шунда гына шаһ үзенең ялгышуын аңлый һәм Аллаһтан ярлыкау сорап сәҗдәгә китә:

Яратылмыш барча дәүләт, барча халык – Синеке,
Кемгә бирсәң шәфкатең вә рәхмәтең – Синеке.
Син белмәс, дип, хаталы вә гөнаһлы эш эшләдем,
Тәүбә иттем инде менә, яманлыкны ташладым.
Син кичерә күр, зинһар, йә, Илаһым, әүвәлин,
Син ярлыкагыл, зинһар, йә, Илаһым, ахирин.

Туганнарым! Арагызда: «Язучы ни генә язмас», – дип шикләнүчеләр дә булыр. Әйдәгез, алайса, бер уңайдан пәйгамбәрләр тарихына да күз салыйк.

Мисыр фиргавене төш күрә. Төш юраучылар аңа бәни Исраил кавеменнән булган бер малай үсеп җитеп, аны тәхетеннән бәреп төшерәчәген әйтәләр. Бу фиргавен шуннан соң бәни Исраил кавеменнән булып туган һәрбер ир баланы үтереп барырга боера. Әмма бәни Исраил кавеменнән булып туган һәм фиргавеннең суда батып үлүенә сәбәпче булган Мусаны фиргавен үзе, баласыдай күреп, тәрбияләп үстерә... Аллаһның кодрәте!

Бүгенге тормышыбызга да караш ташлыйк әле. Шундый ук хәлләрне күрмибезме? Берәр якыныбыз сырхаудан арынмыйча яшьли үлеп китсә: «Табиблар гына карамады, бигрәк яшь иде бит әле», – диеп, Аллаһ Тәгаләдән узып сөйләшмибезме?! Әлбәттә, сырхау кешенең баш очында: «Гомере булса, савыгыр әле», – дип, дәваламыйча, кул кушырып утырырга ярамый, һичшиксез, чарасын күрергә кирәк. Әмма күргән чараның нәтиҗәсен барыбер фәкать Аллаһ Тәгалә генә биргәнен онытмыйк.

Башка каза төшсә: «Шунда бармаган булсам, шулай итмәгән булсам, бу казаны күрмәс тә идем», – дип, үкенеч белән сөйләмибезме? Сөйлибез ләбаса! Чөнки мәлгунь Иблис Аллаһның безгә әйткән сүзләрен истән чыгарта. Без, мәңгелеккә килгән кебек, бер-беребезне этә-төртә дөнья куабыз. Югыйсә: *«Кылган гөнаһлары өчен Аллаһ кешеләргә дөньяда ук газап кыла торган булса, җир өстендә бер генә кеше дә калмыйча, һәлак ителер иде. Ләкин Ул, һәлак итмичә, билгеләнгән вакытка чаклы кичектерә. [Алар], билгеләнгән вакыт җитмичә бер сәгать алдан газап ителмәсләр»,* – дип, безне кисәтеп тора (16.61).

Милләтебезнең асыл уллары, язучылар, ислам галимнәре, халкыбызны Аллаһ Тәгаләнең кушканнарын үтәп яшәргә чакырып, менә шундый гыйбрәтле кыйссалар, төрле үгет-нәсыйхәтләр, зур-зур хезмәтләр язып калдырган. Безгә аларны укып, Аллаһ Тәгаләнең туры юлына кайтып, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хакыйкый өммәтеннән булып яшәр өчен тырышлык куярга гына кала. ■

Тынгысызлык. Канәфи Нәфыйков рәсеме

ТАТАР БАЙЛАРЫ

ӘХМӘТ БАЙ
(1837-1906)

Ризаэддин бине Фәхреддин

Русия мөселманнары файдасы өчен ярым миллион сум микъдарында вәкыф калдырмыш мәшһүр сәүдәгәр Әхмәт бай хакында язылмыш бер әсәрдер. Әхмәт бай үзенең күп гомерене кичермеш вә «Хөсәения» дия мәшһүр мәдрәсәсене тәэсис итмеш (төзегән) Оренбург шәһәрендә улындыгым сәгатьләрдән файдаланмак нияте илә, буның хакында бу рисаләне төзедем. Бу көн улмаса киләчәк бер көндә, шаять, укучылар улыр.

ӘХМӘТ БАЙ ГАИЛӘСЕ

Әхмәт байның ерак бабалары Сәгыйть касабәсе *(бистәсе)* тәэсис ителдегендә, Казан губернасы Мамадыш өязе Кибәк Хуҗа карьясыннан *(авылыннан)* һиҗрәт итеп (күчеп) килмешләрдер. Бунларның мәгълүм уланнары Гобәйдулла исемендә бер зат улып, Әхмәт байның нисбәте ошбу Гобәйдулланың угылы Хөсәен үзәренәдер.[1]

Хөсәен бине Гобәйдулла үз гасырында яхшы дәүләтле вә могтәбәр бер адәм улып, бу көндә Каргалы суы буенда улан бишенче агач мәсҗет буның тарафыннан бина ителмештер. Мәзкүр мәсҗет исә, иң элек 1760 тарихында Бикчәнтәй бине Мөхәммәткол тарафыннан бина улынып, соңра ут казасы илә тәләф улмыш *(беткән)* иде.

Хөсәеннең угылы Гали, бай балалары низамы үзәренә атасыннан калмыш малны тәмам бетереп, фәкыйрь хәлдә Иләк *(Соль-Илецк)* шәһәрендә вафат итмеш. Габделбакый, Әхмәт, Габделгани, Мәхмүт, Габдерахман исемендә ир балалары вә бер кач гадәд *(берничә)* кыз балалары яшь вә ятим хәлләрендә калмышлардыр.

ӘХМӘТ БАЙ

Әхмәт бай 1253 [һиҗри] /1837 [милади] тарихында Каргалы шәһәрендә дөньяга килеп, башка тугмалары илә бәрабәр аталарыннан фәкыйрь хәлдә ятим уларак калдыклары сәбәбеннән, дөньяның күп мәшәкатьләрене күрмеш, хәтта ки кара эшләр эшләп йөрмеш вә көненә 12 тиенгә ялланып тирес, кирпеч сукмыштыр. Ошбу хәл илә дә дөньядан өмидсез улмай, бәлки һәмишә иҗтиһадыны вә гайрәтене, сабыр вә сәбатыны *(чыдамлылыгын)* арттырып тормыштыр.

Соңрадан бервакытлар ничек улса да, биш сум акча хасил кылып, Оренбург шәһәренә килеп, кырыктартма сәүдәсенә[2] керешмештер. Ошбу кәсебе аз-аз улса да алга китеп, көннәрнең берендә ат-арба алырга муафыйк улмыш.

Әхмәт бай үзенең ат-арбасыны йигеп, татлы тамыр вә күкташларыны салып, казакъ арасына чыгып китмеш вә казакъларның: «Акча сатам, нә вирәсез?» – дия йөрдекләре, бервакытта сәүдә кылып алмашып йөрер улмыштыр. Үзенең гайрәте вә казакъ халкының садәлеге, вә шул йирләргә дә бу вакытларда немсә (немец) вә яһүдиләрнең аяк басмадыклары сәбәбеннән, яхшы дәүләт хасил әйләмештер.

Буннан соң туганнары илә Оренбург шәһәренә күчеп килмешләр вә берлектә сәүдә кы-

---

[1] «Гани бай» китабын Габделхәмит Хөсәенов төзегән. Анда «Хөсәеннең атасы Габдулла», диелә. Ризаэддин хәзрәт исә үз китабының «Соңгы сүз» өлешендә Әхмәт бай варислары илә якыннан аралашмавын белдерә. (Лирон Хәмидуллин искәрм.).

[2] Кырыктартма сәүдәсе – вак-төяк сату, капчык күтәреп сатып йөрү.

лып, олуг байлардан улмышлардыр. Утыз биш еллар берлектә тиҗарәт *(сәүдә)* иттекләре соң, 1896 тарихында тугмалары улан Габделгани хаҗи вә Мәхмүт, өч борадәр *(ир туган)*, дүрт миллион сум милек вә дәүләт тәкъсим итмешләрдер *(бүлгәннәр)*. (Габделбакый илә Габдерахман вафат итмешләрдер).

Әхмәт бай 1296/1879 тарихында Хиҗазга сәфәр итеп, хаҗ кылды вә Мәдинәгә варып, Рәсүлулла мәсҗетене зиярәт итте. Русиянең бөек шәһәрләрендә сәүдә итеп йөрдекеннән өстен, ошбу касд *(ният)* илә Германия вә Ингилтәрә *(Англия)* мәмләкәтләренә дә сәяхәт әйләде. Борадәрләре илә бүлешдекләре соң Казан шәһәренә һиҗрәт итте *(күчте)* вә шунда 1324/1906 ел 10 декабрьдә (8 зөлкагъдә) дөньядан үтте. Вафат улдыгы көндә тәкърибән *(якынча)*бер миллион алты йөз мең сум тәрикәсе *(малы)* калып, васыятьләрне чыгарган бәгъдендә тугмасы Мәхмүт Хөсәенов илә хатыны Гайшә Габделгалләм кызы араларында тәкъсим ителде *(бүленде)*. Аллаһы Тәгалә мәзъһәр гафу вә гофран итсен!


Проверено 1949 г.

رضاء الدين بن فخر الدين .

احمدبای

ولادتی ۱۸۳۷ ده. وفاتی ۱۹۰۶ ده.

ایکنچی طبعی .

روسیه مسلمانلری فائده‌سی ایچون یاروم میلیون صوم مقدارنده وقف قالدرمش مشهور سوداگر احمدبای حقنده یازلمش بر اثردر .

آدیگی خیر ایله آگدرمغه ایله همت
عالمه کلدیککه بر طاشی ترك ایتمه دلیل
طاشی ده نقشی ده محو ایدر اما ایام
ابدی دائر اولور السنه ده ذکر جمیل .
« نابی » .

« وقت » مطبعه‌سی اورنبورغده .
ТИПОГРАФІЯ ГАЗ. „ВАКТЪ". ОРЕНБУРГЪ.
1911.

«Әхмәт бай» китабы. Авторы – Р.Фәхреддин

САБЫЙЛЫК ВАКЫТЫ ВӘ ТӘРБИЯСЕ

Әхмәт бай сабый вакытында бик шук вә шаян улып, элек тәрбиясене анасы Хәмидә карчыктан алмыштыр. Соңра үз мәхәлләләренең мөәзиненә йөреп, дүрт-биш кыш гомер уздырмыш. Вә бер кач гадәд *(берничә)* «Һәфтияк шәриф» туздырмыш исә дә, укырга вә язарга үгрәнә алмамыштыр. Баедыгы соң вексель вә чек кеби кәгазьләргә вә үз исеменнән язылмыш мәктүпләргә имза язмак лазем килдекеннән, кара савытка батып чыккан соң кәгазь өстеннән үтеп киткән кара таракан аякларының эзенә охшашлы бер рәвештә имза кылырга үгрәнмеш иде. Фәкать русча имзасы мөселманча улан имзасына күрә хәйли *(күпкә)* артыктыр.

Дүрт кыш мәктәпкә йөреп тә үз имзасыны куя белмәдекене бу заман яшьләре, ихтимал ки, мөбаләгага *(артыру)* хәмел кылырлар *(дип уйлар)*. Фәкать бунда мөбаләгә юктыр. Хәтта мәктәп вә мәдрәсәләрне ислах хакында сүз чыкмыш мәҗлесләрдә: «Бән биш сум акча илә дүрт миллион мая хасил иттем, имде бәнем хакымда: «Габи *(аңгыра)* вә зиһенсез, ялкау вә иҗдиһадсыз», – дия һич әйтүче улырмы? Шөйлә *(шулай)* исә дә, дүрт кыш укып үз исемемне язарга вә укырга үгрәнә алмадым, бунын сәбәбе бәнем ялкаулыгым вә иҗтиһадсызлыгым дәгел, бәлки башка бер шәй улса кирәк, бу исә, тәртипсез вә низамсыз укымактан башка дәгелдер», – дия һәрвакыт сөйләр иде.

КӘСЕП ВӘ ТИҖАРӘТЕ

Әхмәт бай: «Тырыш адәмгә Аллаһы Тәгалә ярдәм вирәдер. Кеше булдырган эшне

Әхмәт бай Хөсәенов

булдырырга бәнем дә кулымнан килергә тиешле», – игътикады илә кәсепкә кермеш вә кич илә көнне, михнәт илә рәхәтне фәрекъ итмәксезен *(аермыйча)*, ошбу мәсләгендә дәвам итмеш. Нә кадәр бәла вә каза күрер улса да, аслан каушамый вә мөтәрәддид улмай *(икеләнми)*, бәлки әүвәлгедән зиядә *(артык)* гайрәтене арттырыр улмыштыр.

Казакъ халкының садәлеге һәм дә Волга елгасыннан локомотив һәнүз *(һаман)* үтмәдегенең[3] Әхмәт байның дәүләт тапмакына бер сәбәп удыгы инкарь улынмаз. Буныңла бәрабәр: «Тырыш адәмгә Аллаһы Тәгалә ярдәм вирәдер, кеше булдырган эшне булдырырга бәнем дә кулымнан килергә тиешле», – игътикадының да олуг әсәре улмыштыр. Шул вакыт мөселманнарының йөрәкләре йитмәзлек рәвеш илә сәүдәләр кылмакы вә фабрикалар эшләтмәке дә мәзкүр гакыйдәсенең сәмәрәсе *(файдасы)* улса кирәк.

Үзеннән мал алмакта улан немсә вә яһүдиләрне күрдегендә: «Бунлар бездән алмыш нәрсәләрене Аурупа базарларында күп файдалар бәрабәренә сатмакта улсалар кирәк. Шөйлә базарлар илә тугрыдан-тугры үземез мөнәсәбәт пәйдә итсәк вә васитасыз *(арадашсыз)* мөгамәлә кылыр улсак, дәхи дә артык рибех *(файда)* алсак кирәк, кешеләр кулыннан килгән эш безнең кулымыздан ни өчен килмәсен», – дия. Аурупа базарларына йөреп, сәүдә конторлары ачып карады.

Ошбу хакта бәхәс итмеш бер мәкаләсендә мөхтәрәм Йосыф әфәнде[4] дияр: «Яһүди вә немсәләрдән бер груһ *(төркем)* Оренбург шәһәренә вә аның әтрафына килеп, эчәк җыярга керештеләр вә буны да чит мәмләкәтләргә йибәреп торыр иделәр. Әхмәт бай исә, эчәкләрнең ни өчен җыелдыгыны вә нә йирләргә йибәрелдегене аслан белмәдеге хәлдә, яһүд вә немсәләрдән күрмәкче, анлар чыгармыш базар хисабы илә эчәк җыярга кереште. Үзенең сәүдәгә маһирлыгы сәбәбеннән, эчәкне очсыз алдыгыннан, яһүд вә немсәләргә сатып, хәйли *(байтак)* рибех *(файда)* күрер иде. Соңра эчәкләрнең ни өчен җыелдыгыны вә нә йирләргә китдегене үгрәнде. Ошбу вакыт немсә вә яһүдләрнең васиталыкларыннан *(арадашлыгыннан)* котылып, эчәкне немсә вә яһүдләрне йөртмәктә улан олуг комиссион исеменә йибәрер улды. Соңра буның васиталыгыннан да котылмак фикеренә керде вә тугрыдан-тугры сәүдә ачмак касды *(нияте)* илә 1893 елда Берлин шәһәренә олуг партия эчәк китереп, тиҗарәтханә *(сәүдә йорты)* ачты. Мал күп, акча күп, йитәрлек кадәр гакыл вә фикер вар. Әмма Әхмәт бай шул йирнең телене белмәз, тиҗарәт вә мәгыйшәт ысуллары илә ашна улмаз иде. Ошбу хәлләр Әхмәт байны Берлинда яһүди ярдәменә мохтаҗ кылды вә яһүди васиталыгыннан котылмак артыннан йөрдегендә, Русия тәбәгасы *(гражданы)* улан бер яһүдине үз хезмәтенә алды. Малны очсыз алмак юлларыны белдегеннән, Әхмәт бай ошбу тиҗарәтханәсеннән зарар итмәде. Ошбу мөддәттә *(вакытта)* Әхмәт бай ике мәртәбә Берлин шәһәренә килмештер. Ләкин биш ел соңрасында, 1898дә тиҗарәтханәне бөтен-бөтене япты вә эшләрене туктатты.

[3] Ягьни, ул дәвердә тимер юл хәрәкәтенең Самарадан узмаган булуы Хөсәенов байлар сәүдәсе уңышына китерә.

[4] Йосыф әфәнде – Акчура (Акчурин) Йосыф Хәсән улы (1876-1935), җәмәгать вә сәясәт эшлеклесе, публицист.

Сәүдә эшләренең иң мөшкел вә иң яшереннәрене гамәлияте илә белмәктә улан Әхмәт байның ошбу тиҗарәтханәне ябуына вә эшене туктатуына хакыйкый сәбәп – җәһаләт *(наданлык)* иде. Зирә *(чөнки)* чит мәмләкәт халкының әхвале рухияләре илә ашналыгы улмаз вә үзе илә мөгамәләдә улыначак немсәләрнең телләрене белмәз иде.

Гайрәт вә җәсарәтенә мәгълүб *(җиңелгән)* улдыгыннан, Әхмәт бай Ауропада улан иң олуг бер сәүдә мәркәзенә килеп төште исә дә, нә файда ки: күз-колагы, кул вә аягы үзенең хезмәтендә улан яһүдидән гыйбарәт иде. Яһүди нә йиргә алып варса – шунда варыр, яһүди нә сөйләсә – шуны тыңлар иде. Әгәр дә Әхмәт бай тугрыдан-тугры немсә эчәкчеләре илә сөйләшергә вә бу тугрыда анлар илә васитасыз аңлашырга муафыйк улса иде, ихтимал ки, тиҗарәтханәсене ябачак йирдә[5] дәхи дә артык тәрәккый кылдырыр иде».

Йосыф әфәнде мәкаләсеннән хөласа *(нәтиҗә)* будыр: бер мәмләкәт илә сәүдә кылмак өчен тел белмәк, акча хаклары вә банк мөгамәләләре һәм дә тиҗарәт хакында улан низамнар илә ашна улмак лазем идекендә шөбһә юк. Ошбу тәҗрибәләренең нәтиҗәсе уларак, иске гадәтләре кабиленнән мәгълүматсыз тордыклары вакытта, Русия мөселманнарының сәүдә бабыннан яһүдиләр, немсәләр илә рәкабәт *(конкуренция)* итә алмаячакларыны, бәлки бөтен-бөтенә дәүләтләреннән аерылачакларыны гүзәл белмештер.

Бөтенрусия мөселманнары русча укырга дин исеменнән каршы тордыклары бер вакытта, Әхмәт бай үзенең мәдрәсәсендә русча дәресләр өчен сыйныф ачып, рус лисаны укыттырдыгының сәбәбе – югарыда сөйләдегемез тәҗрибәләре улмыштыр.

ИКЪТИСАДКА РИГАЯТЕ *(МӨНӘСӘБӘТЕ)*

Яшьлегендә күп зәхмәтләр күреп, хәтта ки читләрнең агыр хезмәтләренә ялланып эшләдеге сәбәбеннән улса кирәк, Әхмәт бай мал кадерене белер, урынсыз йиргә бер тиен улсын, сарыф итмәз өчен тырышыр иде. Мал тәләф *(әрәм-шәрәм)* итүчеләрнең телләрендә истигъмаль ителмәктә улан *(әйтелгән)*: «Мал бәне тапмый, бәлки бән малны табам», «Кеше малы дәгел, үзем тапкан мал!» сүзене Әхмәт бай гомерендә бер кәррә *(мәртәбә)* улсын, истигъмаль итмәмеш улса кирәк.

Сәфәргә чыктыгында азыгыны йортыннан әзерләп чыгар, пароход залларында халыклар сыйланып йөрдекләрендә, бу да кәндесенең *(үзенең)* күмәч вә итне ашап канәгать итәр иде. Зур бер эш иҗбар *(мәҗбүр)* итмәдекендә, беренче дәрәҗәләрдә дәгел, бәлки икенче дәрәҗәләрдә йөрер вә арбачылар илә дә озак сатулаштыгы соң гына утырыр. Хатларыны күп вакытта йөрүче илә йибәрер, йөрүче улмадыгында гына почтага вирер иде. Бу хәлләрне янында йөрүчеләрнең күпләреннән ишеттек.

Үзенең тугмасы Мәхмүт байга йибәрер өчен дия бер мәктүпкә маркасыны ябыштырып почтага вирергә тордыкларында, Оренбург шәһәренә тугры китүче улмыш. Әхмәт бай мәзкүр мәктүпне ошбу кемсә кулына виреп: «Сезнең сәфәреңез ашыгыч улдыгы сәбәпле, ошбу марканы куптарып алырга мөмкин улмады, Мәхмүт бай конторында куптарып алсыннар да, бәнем дәфтәремә язсыннар, онытa күрмә!» – дия тәэкидләп *(кабатлап)* вирмештер[6].

«Хатыннар ихтыярына куйсаң, көннең салкынлык-йылылыгына күрә дәгел, бәлки пичләргә үз кәефләренә карап ягалар, шуның өчен һәркөн суыклык дәрәҗәсене белдегем илә: «Бу көн фәлән кисәк ягарга тиешле дия санатып яктырам», – дидеген ишеттем. Чанага утырырга чыктыгымыз вакыт ялчыларыннан беренең исеме илә чакырып: «Бунда бер көрәк күренми, югалмасын, эзләп табып куй!» – дия тәнбиһ итте *(кисәтте)*.

---

[5] Мәхмүтгәрәй әфәнде хәбәренә күрә, бу тиҗарәтханәне ябучы Әхмәт бай дәгел, бәлки үзара бүлештекләрендә Габделгани хаҗи хиссасына [өлешенә] калмыш вә Габделгани хаҗи тарафыннан ябылмыштыр. (Р.Ф.).

[6] Буны Каргалы имамы мулла Хәйрулла әл-Госмани әфәндедән ишеттем.(Р.Ф.).

Әхмәт бай һәрвакыт: «Мал илә тәмугътан котылып оҗмахка кереп буладыр, малны кадерсез кылырга вә урынсыз тотарга ярамаз», «Акчаның һәр тиене Аллаһы Тәгаләнеке, бәнем кулымда анчак әманәт уларак торыр, Аллаһы Тәгалә риза улмазлык йирләргә бер тиен вирмәм», – дияр иде. Яшьләргә вә бай балаларына улан нәсыйхәте дә һәрвакыт: «Акча арыслан агызындадыр, егет улсаңыз, шуннан алыңыз!» – диер улмыштыр. Ошбу сәбәптән, Әхмәт бай сәүдә бабында ригаятьсез улып, хәтта ярым тиенгә кадәр дикъкать итәр улмыш, нәрсәнең яхшысыны карап, арзан алмак иҗтиһадында улдыгыннан, бының илә сәүдә кылмак агыр улмыштыр.

Макариядә[7] урамда бер кешегә очрап: «Безнең ашханәгә кергәнеңез күрелми, юкса башкаларга йөрисезме?» – димеш. Мәгълүм адәм дә: «И, Әхмәт абзый! Без бик арзанлы ашлар илә генә торамыз, ашханәләр бездән бер-ике тиен генә файда күрәләр булыр», – дидегендә: «Байлыкның бәрәкәтлесе шул бер-ике тиеннән җыелыр, шул бер-ике тиен безнең ашханәгә кереп торсын!» – димештер. Казан шәһәренә вардыгыннан соң гомуми бер зыяфәт иттегендә *(сыйлаганда)*, Казан байлары арасында улан габделбатыйннар *(корсак коллары)* ошбу зыяфәткә *(сый-хөрмәткә)* канәгать итмәдекләреннән, Әхмәт байның ашларыны мәсхәрә кылып, рус газеталарына яздырдылар.

Кассабына *(мал суючыга)* алып вардыгында, бер адәмне чакырып: «Бән кушкан каешны эшләдеңме?» – дия сорады. Үтәге *(эшне башкаручы)* адәм дә йөгереп бер каеш китереп вирде. Әхмәт бай шуны безгә күстәреп: «Күптән бирле йөртә торган чыбыркым вар иде, кучерларга бирмидер идем, ничектер форсат табып угырлап киттеләр. Шуның урынына бу каештан чыбыркы үрдерәм. Шаять, базардан алганга күрә, арзан төшәр», – диде.

Мал кадерене белдеге сәбәбеннән, хаҗ көнендә, хаҗилар тарафыннан бугазланмыш корбаннарның тиреләрене җыеп та, кыйммәт хаклары илә сатмак вә берәр төрле мосаләхы гаммәгә[8] сарыф әйләмәк чараларыны эзләп вә фикерләп йөрмеш вә буны да бик күп адәмнәрнең хәтерләренә салмыштыр. Соң вакытларда Төркия хөкүмәтенең дә ошбу тәләф *(әрәм)* ителмәктә улан тиреләргә күзе төшеп, акчага әйләндерергә башладыгыны сөйләделәр.

ДИЯНӘТЕ ВӘ ӘХЛАКЫ

Әхмәт бай, намаз үтәрлек кадәр сүрәләр вә догаларны хифыз итеп *(яттан белеп)*, шуннарны дөрест укыр, дин хөкемнәре тугрысында мәхәббәтле вә салабәтле *(ныклы)* улып, сәфәр вә хәзерендә намазларыны вакытында әда кылыр *(үтәр)* вә казага куймаз, белмәгән нәрсәләрене үгрәнмәктән оялмаз, кылган изгелекләрене башкаларны кызыктырып, шуны эшләтмәк касды *(теләге)* илә генә улмаса, белдермәз вә сөйләмәз иде. Диянәтле, һөнәр вә эшлекле, халык өчен файдалы адәмнәрне сөяр вә кирәк кадәр анларга ярдәм әйләр иде. Динендә мөсаһәләле *(игътибарсыз)*, намаз укымаучы адәмнәрне вә, гомумән, ялкаулар, акча кадерене белми торган яшь байлар, тамгыкяр *(ач күзле)* вә үз вазыйфаларыны йиренә китермәгән муллалар бының каршында очсыз бәһа илә йөрерләр иде.

Гомум ислам байларында улан горурдан Әхмәт бай сәламәт иде. Өстендә – бәрән эчле ак тун, башында биш-алты сумлык бүрек улдыгы хәлдә, иптәшемез илә безне түрдә утыртып, үзе кучер янында безгә каршы утырдыгы хәлдә, Оренбург урамында дәфгаләр илә *(күп тапкыр)* йөрде. Бу хәле исә, тәкәллеф вә рия илә *(икейөзлелек)* дәгел, бәлки табигый бер гадәтеннән иде. Һәркем илә сөйләшер вә сорашыр, кешегә аслан ким күз илә карамаз иде.

Мәҗлесләрдә сүз көрәштерергә, хосусан, мәктәп вә гыйлем илә мәшгуль дәгел, мул-

---

[7] Макария – Түбән Новгород өлкәсенең Макарьево бистәсе, Түбән Новгородтан 88 км ераклыкта Россиянең иң эре ярминкәсе.

[8] Мосаләхы гаммәгә – гади халык арасында низагны бетерү өчен, килешү.

лалар илә муллаларның вазыйфалары нәләрдән гыйбарәт идегәне сөйләшергә яратыр. Ләкин һичкем илә ачыгланышмаз, тавышыны бозмаз иде. Сүзләрене гакыл илә сөйләр, мәдрәсәләрдә ятып мантыйк исеменнән әүһам *(бозык буш уйлар)* вә хыялят *(буш уйлар)* укымадыгы сәбәпле, кувәи мантыйкыясе *(уйлау көче)* сәламәт калдыгыннан, сүзләре мантыйкый улыр иде.

Каргалыда мәктәп вә шәкертләр хәленнән, муллаларның уку вә укыту тугрыларында лазем *(тиешле)* дәрәҗәдә иҗтиһадлары *(тырышлыклары)* юклыгыннан зарланып утырдыгында, яшь муллалардан бере үз-үзене забыт итә *(кулга ала)* алмый, хиффәтләнеп *(акыл җиңеллелеге белән)*: «Аякларыңыздан тотып селкүче булса, өчәвеңездән бер әлиф төшмәз, муллаларны интикад *(тәнкыйтъ)* итеп вә анларга гаеп иснад кылып *(аударып)* утырасың», – диде. Әхмәт бай буңа каршы көлде вә: «Бик дөрест әйтәсең, хәзрәт, өчәвемездән бер әлиф төшмәдеге сәбәпле, наданлык вә җәһаләтнең нә кадәр агыр бер михнәт идегене гүзәл аңладым, шуның өчен мөселман карендәшләремезнең балалары бу михнәттән хәляс улсыннар *(котылсыннар)*, безем кеби бер әлифсез дә калмасыннар иде, диям. Юкса, әгәр дә галим булсам иде, бән һәм бу тугрыда хәзрәтләр рәвешендә бихәбәр *(хәбәрсез)* торыр, бәлки хәзрәтләр кеби, гавам *(гади халык)* баласы укымасын вә җаһил калсын фикерендә улыныр идем. Гавам балаларында әлиф булмаса, әлиф бугланнарының кадер вә гыйзззәтләре күбрәк улачактыр!» – дия, мәҗлесене көлкегә әйләндерде вә мәҗлес халыклары *(муллалар һәм берлектә)* мәҗбүри көлешә башладылар.

Мәдрәсәсенең капкасыннан кердегемез илә яшь кенә бер бала очрады, буны янына китереп, нә йирле вә кангый *(кайсы)* сыйныфта идеген сораштыгы соң җитди уларак балага: «Угылым! Бәнем бер Кәбир исемле кучерым, Шәриф исемле писәрем *(язучым)* вар. Кәбир – карт, әмма Шәриф яшь егет. Кәбир һәркөн куш ат җигеп, сәгать унбердә контор ишеге янына варып, Шәрифне көтеп торадыр. Шәриф чыгып, шул чанага утырадыр да, банкка китәдер. Бундай карт кеше ни өчен бу яшь егетне һәркөн шөйлә йөртә? Ни өчен Кәбир Шәриф урынында вә Шәриф Кәбир урынында йөрмидер?» – диде. Бала бераз торды да: «Кәбир укымаган, әмма Шәриф укыган», – диде. Әхмәт бай: «Алай икән!» – дия, баланы үз юлына йибәрде.

Әхмәт бай сүзене тиз аңлаучы, хак илә батыйльне *(ялганны)* бер-береннән аеручы улдыгыннан, милләтнең тәрәккыйсе хакында сөйләнмеш сүзләргә колак салыр вә анларның рәваҗлары *(таралуы)* өчен тырышыр вә һичкемнең шелтәсеннән курыкмай, хак йиргә ярдәм кылыр иде.

Казан шәһәрендә вә Казан әтрафында элек заманда кылынып та, соңыннан югалмыш вәкыфларны ихья итмәк *(тергезү)* хакында күп иҗтиһадлар кылып йөрде исә дә, монафигъ *(файдалы)* мөштәрәкә *(уртак эш)* хакында кайгыртучыларның азлыгыннан вә бундай мәсьәләләрдә артыннан йөрергә иптәшләр табылмадыгыннан, бу тугрыда улан хәрәкәтләре нәтиҗәсез калды.

Үзенең күрмеш зәхмәтләрене, нә кеби иҗтиһадлар илә мал таптыгыны һәр йирдә вә һәркемгә сөйләр, гарьләнмәз иде. Казакъ арасында йөрдеге вакыт, өстендә чикмән улдыгы хәлдә, чыбыркысыны биленә кыстырып, арбасы яныннан янәшә уларак йөрдегене, юл буенча үлән йолкып атына ашата-ашата вардыгыны вә тәмам арып беттеге соң, арбасында улан тартмалар, әрҗәләр өстенә менеп йокладыгыны сөйләр вә бу йокыларның ләззәтләрене сагыныр иде.

Ахыры бар

*Текстны басмага **Җәүдәт Миңнуллин** һәм*
***Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Гаяз Исхакый Ләһстанда

Ләйсән Галиева

«Безгә искиткеч дустанә мөнәсәбәт күрсәткән, милли мәсьәләләребезгә шулкадәр игътибар биргән, үзебезгә дин, милләт һәм кан ягыннан тугандаш булган дәүләттән золым-җәбер күргән вакытта, безгә кочагын киң итеп ачкан Польша...», «дус ил»... Әлеге илдә ун-уникe еллап гомерен кичергән Гаяз Исхакыйны Ләһстан илен ташлап китү вакыйгасы әнә шундый сүзләр язып калдырырга этәргән.

Әдипнең биографиясенә кагылышлы фактларны барлаганда, Польшага бәйле шактый гына мәгълүмат туплап була. Г.Исхакый 1927-1939 елларда Варшавада яшәп ала. Аның инициативасы белән 1928 елның 28 июнендә биредә «Идел-Урал» комитеты оештырыла. Польшага ул 1907 елда Архангель губернасының Пинега шәһәрендә бергә сөргендә булган дусты маршал Юзеф Пилсудскийның шәхси чакыруы буенча килә һәм Варшава шәһәрендә төпләнә. Пилсудский аңа үз матбагасын оештыруда ярдәм итә. Г.Исхакыйның «Идел-Урал» тарихи-публицистик китабы 1938 елда Варшавада поляк телендә дөнья күрә. Биредә шулай ук «Милли юл» журналы әзерләнә (басылу урыны – Берлин). Г.Исхакый Варшава «Прометей» клубы эшчәнлегендә катнаша. Милләт мәҗлесе төзелүнең 20 еллыгына багышлап үткәрелгән конгресс 1938 елның 4-6 февралендә Польша башкаласында уза. Г.Исхакыйның аны уздыру эшендә башлап йөрүчеләр арасында булуын беләбез. Аның конгресс хакында 1938 елның февралендә Варшава радиосы аша ясаган чыгышы мәгълүм.

1939 елның сентябрь аенда Гитлер Германиясе Польшага һөҗүм башлагач, Г.Исхакый, эмигрантлар оешмасы «Прометей» җитәкчеләре белән бергә, Варшавадан чыгып китәргә мәҗбүр була. Биредә аның бөтен әйберләре, кием-салымнары кала. Аларны ул илдәшләре, башкалада укыган яшьләргә тапшырып китә, Варшавадагы архивын бер саклык банкына илтә («Ике ут арасында» драмасы һәм «Олуг бәйрәм» исемле хикәясе дә шунда сакланган була). Болар Һ.Мәхмүтов, Л.Гайнанова, М.Хәсәнов, М.Сәхапов, Ф.Мусин, З.Мөхәммәтшин һ.б. галимнәрнең мәкаләләре аша билгеле.

Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗатын киң планда тикшергән әдәбиятчы галимнәрнең берсе – Х.Миңнегулов. Әлеге темага аның «Исхакый мөһаҗирлектә» (1999), «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» (2004) исемле ике монографиясе дөнья күрә. Алда саналганнардан тыш, китаплар башка кызыклы фактлар белән дә таныштыра. Мәсәлән, Г.Исхакый бераз вакыт Польшаның Шәрык институтында эшләп ала. 1937 елның башларында, бигрәк тә әдипнең туган ае февральдә аның иҗади эшчәнлеге башлануга 40 ел тулу мәмләкәттән читтә яшәгән татарлар арасында киң



Ислам журналларының мөхәррирләре Барасби Байтуган («Төньяк Кавказ»), Вассан Гәрәй Җабагый («Ислам күзәтүе»), Л.Н.М.Крычинский («Татар елъязмасы»), Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә («Истикъляль»), Гаяз Исхакый («Яңа милли юл»). «Rocznik tatarski» («Татар елъязмасы»). 1932 ел

күләмдә билгеләп үтелә. Юбилей тантаналарының иң зурысы 5 март көнне Варшавадагы Шәрык институтының зур залында уздырыла. 1930 елда Польша башкаласында Идел-Урал, Төркестан, Азәрбайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия, Карелия вәкилләрен үз эченә алган «Прометей» исемле милли азатлык хәрәкәте оешмасы төзелә. Аның үзәгендә дә Гаяз Исхакый тора. «Яңа милли юл» журналының 1931 елгы җиденче-сигезенче саннарының тышлыгында «Ләһстанда татар атлы гаскәрие», «Наполеонның татар гвардиясе», «Татар сугышчысы» кебек сурәтләр бар. Алар «Ләһстан мөселманларының милли музәханәләрендән алынган». Варшавада язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Исхакыйның «Ислам мәмләкәтләрендә» дигән юл хатирәләренең бер өлеше язылган.

Г.Исхакый Варшавада яшәү чорында биредә милләтебезнең күренекле әдипләренә багышлап төрле кичә һәм чаралар үткәрүдә катнашкан, оештырып йөргән. Мисал өчен, Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә, «Тәрҗеман»ның 50 еллык бәйрәме һ.б. Г.Исхакыйның шулай ук Варшаваның «Прометә» клубында, Шәрык институтында лекцияләр укуы, чыгышлар ясавы да мәгълүм. Октябрь инкыйлабыннан соң мөһаҗәрәткә киткән милләттәшләребез 1552 елгы кара көнне «Хәтер көне», «Матәм көне» рәвешендә билгеләп үткән. Мондый чаралар 1920-1930 елларда Польшада да уза.

Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге тарихчы, журналист һәм җәмгыять гыйлеме галимнәре Б.Солтанбеков, И.Таһиров, Р.Гайнетдинов, Б.Гали, С.Исхаков, А.Мөбарәкҗанова, Г.Галәметдинов һ.б. хезмәтләрендә дә урын ала. Галим Р.Гайнетдинов үзенең «Деятельность татаро-башкирских эмигрантских организаций и центров в 1900-начале 1930-х годов» дип исемләнгән диссертациясенең бер өлешен Г.Исхакыйның «Идел-Урал» оешмасының СССРга каршы алып барган антисоциалистик эшчәнлегенә багышлый. Әлеге хезмәттән шунысы билгеле: «Идел-Урал» «Бәйсезлек комитеты» Польша Генштабының II бүлеге тарафыннан финанслана һәм

моның өчен әлеге хәрәкәт әгъзалары СССР һ.б. илләр хакында мәгълүмат җыеп бирергә тиеш була. Б.Гали исә әлеге күренешнең баштарак кына булуын ассызыклый.

«Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары» темасы беренче тапкыр 1994 елда Ә.Кәримуллин язмаларында күтәрелә. Галим татар җәмәгатьчелеген әдипнең 1932 елда «Rocznik tatarski» («Татар елъязмасы», Вильно, хәзерге Вильнюс) дип исемләнгән поляк басмасында дөнья күргән «Польша татарларының милли бурычлары» мәкаләсе белән таныштыра. Әлеге язмадан аңлашылганча, Г.Исхакый Польшада яшәүче татарларның тарихы, мәдәнияте белән кызыксынган, аны аларның язмышы борчыган. Мәкаләне рус теленә галим Р.Йосыпов тәрҗемә итә. Соңрак ул аны «Польские страницы жизни Гаяза Исхаки» дип исемләнгән язмасында да бастырып чыгара.

Л.Гайнанова 1999 елда басылып чыккан Г.Исхакый әсәрләренең икенче томында телгә алынган «Rocznik tatarski» журналы хакында өстәмәләр кертә: «Бөек Ватан сугышына кадәр Польшада поляк телендә поляк-литва татарларының тарихы, тормышы, мәдәнияте турында «Rocznik tatarski» («Татар елъязмасы») дигән исемдә өч җыентык чыгып өлгерә (1932 – Вильнода, 1935 – Замощчта, 1938 – Варшавада). 1932 елгы җыентыкта Г.Исхакый турында белешмә һәм аның «Польша татарларының милли мәсьәләләре» исемле мәкаләсе басылып чыга. Әмма искәрмәләр авторы тарафыннан телгә алынган белешмә турында Ә.Кәримуллинда мәгълүмат юк. Китапчы галим шулай ук әлеге басманың соңрак нәшер ителгән саннарын да эзләп карый, әмма Казан, Мәскәү һәм Санкт-Петербург китапханәләрендә Ә.Кәримуллин кулында булган мәҗмуга да табылмый. «Татар елъязмасы»ның әлеге һәм башка саннары белән безгә Польшаның электрон китапханәләре аша танышырга насыйп булды.

Чыннан да, «Татар елъязмасы»ның өч саны өч шәһәрдә дөнья күрә, дүртенчесе 1939 елда башланган сугыш аркасында басылмый кала. 1932 елда нәшер ителгән җыентыкта Г.Исхакыйның «Польша татарларының милли бурычлары» дип исемләнгән мәкаләсе урнаштырылган. Моннан тыш, әдипнең эшчәнлеге хакында башка мәгълүматларга да тап булабыз: Арслан Бәй (Леон Найман Мирза Крычинский дип уйларга нигез бар) тарафыннан язылган «Генерал Мацей Сулькевич» язмасында Г.Исхакыйның «Wschod» («Көнчыгыш») журналында дөнья күргән «Сугыш вакытында татар хәрби оешмалары» мәкаләсенә сылтама бирелә (бу мәкаләнең эчтәлеге белән үз хезмәтендә галим Б.Гали таныштыра); «Яңа милли юл»да поляк татар гаскәриләре рәсемнәре урнаштырылуы (алда күрсәтелде); мөхәррире Г.Исхакый булган «Яңа милли юл» журналының чыгып килүе һ.б. турында хәбәр ителә. Елъязманың редакторы – Леон (Арслан) Найман Мирза Крычинский (1887-1939) – Вильнюста Татар халык музееи һәм Татар халык архивын оештырган зат.

«Татар елъязмасы»ның икенче томында да Г.Исхакый, аның эшчәнлегенә кагылышлы фактлар теркәлгән. Мәсәлән, мәҗмугада ислам журналларының мөхәррирләре төшкән фотосурәт бар, биредә Барасби Байтуган («Төньяк Кавказ»), Вассан Гәрәй Җабагый («Ислам күзәтүе»), Л.Н.М.Крычинский («Татар елъязмасы»), Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә («Истикъляль»), Г.Исхакый («Яңа милли юл») бергә утырганнар.

Елъязманың өченче томы Литва татарлары тарихына багышланган. 1993 елдан алып 2006 елга кадәр «Rocznik tatarski»ның дәвамы буларак «Rocznik tatarow polskich» журналы чыгарыла. 1994 елгы санында Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» әсәре поляк телендә дөнья күрә (әсәрнең копиясен поляк галиме Гжегож Червинский безгә тапшырды, аңа рәхмәтебезне белдерәбез). Тәрҗемәче Адам Мурман тарафыннан татар язучысы хакында кыска гына мәгълүмат китерелә. Аерым алганда, Г.Исхакыйның Польшада яшәү чорында Варшава мөселман җәмгыятендә дин буенча мөгаллимлек итүе, «Rocznik tatarski» редакциясе белән хезмәттәшлеге һәм поляк татарларының еш кунагы бу-

луы турында хәбәр ителә. Әдипнең поляк телендә «Wschod-Orient», «Zycie Tatarskie», «Przegląd Islamski» журналларында басылган мәкаләләре аерым игътибарга лаек, дип искәртә поляк тәрҗемәчесе. Соңгысының берничә саны белән танышу мөмкин булды, әмма әдипнең мәкаләләре әлегә табылмады. Басманың күзәтү өлешләрендә Г.Исхакый юбилее, аның Польшадагы эшчәнлеге хакында кыска-кыска мәгълүматлар китерелә.

«Rocznik tatarski»дан тыш, поляк җирендә, польша татарлары һәм шулай ук казан татарлары тормышына күзәтү ясап, башка басмалар да чыгып килә. Шулар арасында иң билгеле булганы – «Zycie tatarskie» («Татар тормышы»). Журнал 1934-1939 елларда нәшер ителә, редакторы – Стефан Туган-Барановский. Бу басманың барлык саннары белән дә әлегә танышу мөмкин булмады. Шулай да 1937 елгы 5 санының беренче битләрендә басылып чыккан Али Мурза-Мурзич мәкаләсе игътибарга лаек, чөнки биредә Г.Исхакыйны 40 еллык әдәби эшчәнлеге белән котлау сүзләре урнаштырылган. Мәкаләдә әдипнең биографиясе китерелә, иҗатына күзәтү ясала. Моннан тыш, безнең кулда булган журнал саннарының күзәтү, хроника өлешләрендә Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеге хакында да мәгълүматлар теркәлгән.

Г.Исхакыйның иҗади эшчәнлегенә 40 ел тулу уңаеннан Мәхмәд Вәисинең «Wschod» журналында – поляк, «Şimali Kafkasya» («Төньяк Кавказ») журналында рус телләрендә мәкаләләре басыла. Соңгысында Җәгъфәр Сәедәхмәд Кырымлының «Әмәл» журналында да басылган «Казан әдәбияты һәм Гаяз Исхакый» язмасы да урын алган.

«Şimali Kafkasya» мәҗмугасы 1929-1934 елларда «Горцы Кавказа» исеме белән чыгарыла. Эчтәлегендә – рус, төрек, француз һәм инглиз телендәге язмалар. Журнал Польша, Франция һәм Чехословакия илләрендә нәшер ителә. «Горцы Кавказа» журналының 1931 елгы 26 санында О.Идилли тарафыннан язылган «Об Идль-Урале» мәкаләсе урнаштырылган. Эчтәлектә – М.Худяков хезмәтенә, «Красная Татария» саннарына мөрәҗәгать итү. Текстның тел-стиле бу язма да Г.Исхакый каләме белән иҗат ителгән дип әйтергә мөмкинчелек тудыра. Журнал авторлары арасында Г.Исхакый барлыгын галимә А.Н.Рубанова да раслый. Кызганыч, әлеге басманың да барлык саннары безнең кулда әлегә юк.

Билгеле булганча, Г.Исхакый Варшаваның Көнчыгыш институты белән дә хезмәттәшлек итә. Институтның Көнчыгышны өйрәнүче яшьләр түгәрәге исеменнән, Көнчыгыш мәсьәләләренә багышлап, өч айга бер чыгып килүче журнал бастырыла. «Wschod» (соңрак «Wschod-Orient») дип исемләнгән әлеге басманың 1930-1939 еллар аралыгында барлыгы 31 саны дөнья күрә.

Әлеге журналда Г.Исхакыйның өч мәкаләсе басыла: «Идел-Урал», «Сугыш вакытында татар хәрби оешмалары», «1931 елгы мөселман конгрессы». Алар поляк һәм инглиз телләрендә язылган. Икенчесе алдарак телгә алынган иде. «Идел-Урал» мәкаләсенең эчтәлеге язучы һәм публицистның «Историко-политический очерк республики Идель-Урала», «Русиянең киләчәге (Идел-Урал җөмһүрияте)» язмаларының эчтәлеге белән тәңгәл килә диярлек.

«1931 елгы мөселман конгрессы» дип исемләнгән мәкаләне татар теленә тәрҗемәдә тәкъдим итәбез. Аңлашылганча, бу мәкалә – күренекле әдипнең поляк җире белән бәйле материалларын беренчел эшкәртү омтылышы. Эзләнү дәвам итә. Әлеге юнәлештәге эшкә битараф калмаган журнал укучыларның киңәш-тәкъдимнәренә өметләнеп калабыз. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

1931 ЕЛГЫ МӨСЕЛМАН КОНГРЕССЫ

Гаяз Исхакый

AYAS ISHAKI

KONGRES MUZUŁMAŃSKI 1931 R.

Wygnanie dnia 23 marca 1924 r. ostatniego kalifa Abduł Medżyd Efendi z Stambułu, uznane było przez cały świat muzułmański za nadzwyczajne wydarzenie.

Chociaż kalifowie w czasie wojny światowej nie potrafili odegrać moralnej roli jakiej po nich spodziewało się tureckie wojskowe dowództwo, to jednak po wojnie, w czasie podziału Turcji przez zwycięskie kraje i w czasie ruchu dążącego do wyswobodzenia Turcji idea niezależności „makamu" (siedziby kalifa, t. j. Stambułu), wokoło której zgrupowało się całe społeczeństwo muzułmańskie, odegrała dość znaczną rolę. Nic więc dziwnego, że zaczęto szukać dróg wyjścia z tego położenia.

Pierwszą próbę w kierunku rozstrzygnięcia tego zagadnienia poczynił kairski muzułmański uniwersytet El-Azhar, który w kwietniu 1926 r. zwołał w Kairze kongres muzułmańskich teologów. Na postawione pytanie, czy wypędzony z Turcji Abduł Medżyd Efendi pozostaje nadal kalifem, kongres odpowiedział, że kalif powinien obronić cały świat muzułmański i mieć siłę moralną i fizyczną, ażeby móc wypełniać własną wolę; Abduł Medżyd Efendi nie potrafił obronić nietylko świata muzułmańskiego, lecz i swego wysokiego stanowiska, a nawet samego siebie i dlatego też nie może on być dłużej kalifem. Sprawa wyboru nowego kalifa została jednak niezałatwiona. Jakby dla ostatecznego rozstrzygnięcia tego zagadnienia w tymże roku w miesiącu czerw-

KONGRES MUZUŁMAŃSKI PODCZAS OBRAD

Siedzą od lewej strony — 2-gi, Emin El Husseini — wielki mufti Palestyny, 3-ci, Halid Pasza — prezes arab. egzekutywy Palestyny, 4-ty, El Zabara — poseł imama Jemenu, 5-ty, Musztehid Sejjef Al Ata — głowa Szyitów...

57

Г.Исхакыйның «Wschod» (Варшава) журналының 1932 елгы 3-4 саннарында поляк телендә, резюмесы инглиз телендә басылган мәкаләсе

1924 елның 23 мартында Истамбулдан соңгы хәлифә Габделмәҗид[1] әфәндене куып чыгару бөтен мөселман дөньясы тарафыннан гадәти булмаган вакыйга кебек кабул ителә.

Бөтендөнья сугышы вакытында хәлифәләр төрек хәрби командирлары тарафыннан көтелгән әхлакый рольне уйный алмасалар да, сугыштан соң, җиңүче илләр арасында Төркия бүленгән һәм Төркиянең азатлыгы өчен хәрәкәтләр барган вакытта, бөтен мөселман җәмәгатьчелеген туплаган «мәкам» (хәлифә урыны, ягъни Истамбул) бәйсезлеге идеясе мөһим роль уйный башлый. Шуңа күрә дә әлеге хәлдән чыгу юлларын эзләүнең башланып китүе шаккатмалы түгел.

Әлеге мәсьәләне чишү омтылышы беренче мәртәбә Каһирәдә урнашкан Әл-Әзһәр мөселман университеты тарафыннан башкарыла: биредә 1926 елда ислам дине әһелләре съезды үткәрелә. Төркиядән куып чыгарылган Габделмәҗид әфәнде хәлифә булып каламы, дигән сорауга җавап биргәндә, конгресс хәлифә бөтен мөселман дөньясын якларга, һәм әхлакый, һәм физик яктан көчкә, үз ихтыярын үтәү мөмкинчелегенә ия булырга тиеш; Габделмәҗид әфәнде мөселман дөньясын гына түгел, ә бәлки үзенең югары позициясен һәм хәтта үз-үзен дә яклый алмады һәм шуңа күрә башка хәлифә була алмый, дип җавап бирә. Әмма яңа хәлифә сайлау мәсьәләсе чишелеш тап-

[1] соңгы хәлиф Габделмәҗид әфәнде – Габделмәҗид II (1868-1944), 1924 елның 3 мартында, Мостафа Кәмалның (Ататөркнең) указы белән хәлифәлек бетерелгәч, Төркиядән куып чыгарыла.

мый. Әлеге мәсьәләгә нокта кую өчен эшләнгәндәй, шул ук елның июнь аенда, Ибн әл-Согудның[2] Мәккәдә хажда булган вакытына туры китереп, икенче мөселман конгрессы чакыртыла.

Конгрессны ачып җибәргән Хиҗаз короле Ибн әл-Согуд бөтен мөселман илләреннән җыелган күп санлы делегатлардан барлык мөселман проблемаларын бергәләп карауны үтенә.

Англия сәясәтен алга сөрүче һәм Бөтендөнья сугышы вакытында хәлифәгә хыянәт иткән Хиҗаз короле Хөсәенне изге урыннардан кысрыклап чыгарган кеше буларак, Ибн әл-Согуд мөселман дөньясында аеруча зур популярлык казана һәм хәлифә дәрәҗәсенә иң лаеклы кандидат булып тоела. Әмма аның консерватив һәм фанатик ваһһабилар сектасыннан булуы либераль мөселман җәмәгатьчелеген куркуга сала, һәм шунлыктан Конгресс мисыр һәм һинд мөселманнары делегатлары составында көчле каршылык күрсәтә, яңа хәлифә сайлау мәсьәләсе кулайрак вакытка күчерелә.

Узган ел Иерусалимда 6 декабрьдән алып 17сенә кадәр дәвам иткән өченче съезд үткәрелә. Үткән конгрессларның хаталарын кабатларга теләмичә, әлеге конгресс беренче планга мәдәни мәсьәләләрне хәл итүне алгы планга куеп, хәлифә сайлау проблемасын аңлы рәвештә юкка чыгара.

Шулай да, өченче съезд алдында да, алдагылары белән чагыштырсак, җитди сораулар куела. Ул да булса – сионизм һәм яһүдилек проблемалары.

Иерусалимны конгресс үтү урыны итеп билгеләү барлык яһүдиләр дөньясында ыгы-зыгы чыгара. Алар конгресска каршылык күрсәтә башлыйлар һәм, мөселман илләре арасында конгресска ышанычны какшату ниятеннән, Европага сәяси панисламизм янавы белән куркытырга тырышалар. Бу факт, Йәмәннән кала, бер генә мөселман иле дә үз рәсми делегатын җибәрмәве, ә барлык ислам динендәге илләрнең үз делегатларын иҗтимагый активистлар рәтенә, барлык секталарның исә үзләренең югары дәрәҗәле лидерларын җибәрүе белән аңлатыла. Конгресста шулай ук инкыйлаби оешмаларның вәкилләре дә катнаша. Югарыда әйтелгәннәрдән шуны күрәбез: өченче съезд, һичшиксез, демократик рухта уза һәм сәяси яктан, узган икесе белән чагыштырганда, беркадәр либераль һәм дөньяви төстә үтә.

Этник яктан караганда, конгресста гарәп һәм төрекләр, фарсылар, һиндләр, малайялылар, славяннар һәм кытайлар катнаша; географик яктан Хиҗаз, Йәмән, Мисыр, Палестина, Сурия, Гыйрак, Иран, Әфганстан, Һиндстан, Тунис, Алжир, Финляндия, Югославия һәм Төньяк Африка илләре үз вәкилләрен җибәрә.

Конгресста барлыгы 150 кеше катнаша, аралашу телләре булып гарәп һәм төрек теле тора. Биредә барлык партия һәм социаль төркемнәр дә була: панисламистлар, милләтчеләр һәм региончылар, ләкин милләтчеләр, һичшиксез, күпчелекне тәшкил итәләр.

Конгресс Иерусалимда 1931 елның 6 декабрендә ачыла һәм барлык мәсьәләләрне хәл иткәннән соң, шул ук айның 17сендә үз эшен тәмамлый.

[2] Ибн әл-Согуд – Ибн әл-Согуд Габделгазиз (1880-1953) – ваһһабилар мәзһәбенең дини башлыгы, 1927 елда Хиҗаз короле булып игълан ителә.

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Съезд программасында түбәндәге дүрт пункт карала: 1) Палестинадагы изге мөселман урыннарын саклау. 2) Хиҗаз тимер юлын кайтару мәсьәләсе. 3) Иерусалимда гомуммөселман мәдәнияте бирлеген саклау өчен махсус комитет булдыру. 4) Боларны башкарып чыгару өчен Иерусалимда мөселман университеты төзү.

Конгресс иң беренче чиратта 6 комиссия сайлый һәм үз эшен башлап җибәрә. Документлар аерым комитетлардан килү сәбәпле, һәрбер карала торган мәсьәлә буенча киңәшләшү уздырыла һәм шуларга ярашлы резолюцияләр әзерләнә.

Беренче очрашуда Идел-Урал һәм Кавказ вәкилләренең СССРдагы мөселманнар хәлен киң яктырткан лекциясе кызыксыну белән тыңлана.

Әлеге лекцияләрдән соң, җыелганнар арасында большевикларга каршы карашлар сиземләнә, соңрак алар мөселман прессасына да үтеп керә. СССРдан булган делегатларның комитетларда, ябык җыелышларда һәм уртак утырышлардагы һәрдаим эшчәнлеге, большевикларга каршы алып барган көрәшне сәяси мотивлардан тыш һәм җирле кызыксынулардан өстен куя белү сәләте әлеге көрәшне бөтен мөселман дөньясы өчен рәсми рәвештә яңгырамаган, әмма иң мөһим сорауларның берсенә әверелдерә.

Палестинадагы изге мөселман урыннарын саклау комиссиясенең докладыннан соң, яһүдиләрне Палестинага күчереп утыртуга һәм мөселманнарны җирләреннән куып чыгаруга каршы резолюция кабул ителә.

Хиҗаз тимер юлы темасы буенча лекция укылганнан соң, конгресс башкарма хакимият идарәсенә керер өчен тимер юлны кабул итә һәм әлеге резолюцияне тормышка ашыру өчен махсус комитет билгеләнә.

Съездның университет төзү турындагы карары бертавыштан кабул ителә. Бары тик мөселман мәдәни берләшмәсен оештыру проекты гына бәхәс кузгата: биредә феодаль һәм демократик карашлар кисешә.

Ниһаять, большевикларның мөселманнарга карата алып барган кыерсытуларына каршы протест кабул ителгәннән соң, гомуммөселман мәдәниятенә нигезләнгән килешү проекты расплана. Конгресс, һәрбер милләтнең мөселман вәкиленә урын бирергә тырышып, 25 кешедән торган Югары Совет сайлый һәм 1933 елда үтәсе IV мөселман конгрессының уздыру вакытын билгели.

Югары Совет съездда кабул ителгән резолюцияләрне башкарып чыгару ниятеннән җиде кешедән торган башкарма комитет сайлый[3].

Поляк теленнән ***Ләйсән Галиева*** *тәрҗемәсе* ■

[3] Югары Совет эшендә әлеге мәкаләнең авторы Гаяз Исхакый һәм узган гасырның уртасыннан алып Кавказ тау халыкларының атаклы командующее оныгы Сәед Шамил катнаша. Шуннан соң Сәед Шамил Совет тарафыннан башкарма комитет әгъзасы итеп сайлана (редактор искәрмәсе).

ГАЛИМ
Рөстәм Үтәмешев

Үтәмешевләр гаиләсе: гаилә башлыгы Исмәгыйль Гали улы Үтәмешев, хатыны Зөбәйдә Мөхәммәтҗан кызы, Түрфәндә һәм Рөстәм (Үзбәк)

Байтак еллар якташыбыз Рөстәм (Үзбәк) Исмәгыйль улы Үтәмешевнең исеме билгеле сәбәпләр буенча сер булып кала бирде. Шуңа да аның исеме тар даирәдә – галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре арасында гына хөрмәт белән искә алына иде. Әле шушы арада гына «Татарстан яңа гасыр» телеканалында космонавтика көненә багышланган тапшыруларның берсендә татарлардан Галәм киңлекләрен өйрәнүдә өлеш керткәннәрне санаганда, аны телгә алучы булмады. Роальд Зиннуров, Рәшит Суняев кебек абруйлы галимнәр, дистәдән артык очучылар, космонавтлар төркемендә күнегүләр ясаган затларның исем-фамилияләре аталса да, аны онытгылар.

Кем соң ул Рөстәм Үтәмешев? Совет фәне һәм космонавтикасы тарихында нинди эз калдырган? Сүз Галәмне өйрәнүдә әйдәп баручы академиклар С.Королев, А.Благонравов, В.Парин, А.Богомоловлар белән иңгә-иң куеп эшләгән галим, космик медицина өлкәсендә фәнни эзләнүләр алып барган инженер-конструктор, оештыручы һәм җитәкче сәләтенә ия булган милләттәшебез

Рөстәм Үтәмешев турында. Ул – гаять гыйбрәтле һәм данлы тормыш юлы үткән шәхес.

Рөстәм ага Чыгышы белән Кукмара ягының Мәчкәрә авылыннан. Нәсел шәҗәрәсе Казан ханы Үтәмешгәрәйгә барып тоташа. Бу хакта галим үзенең бабалары, тормыш юлы турында язганда искә алып китә. Казан һәм Кырым ханнарының нәселләрен дәвам итүчеләр буларак, Исмәгыйль ага һәм аның җәмәгате Зөбәйдә ханым газиз балаларына да хикмәтле исемнәр кушканнар. Кызлары тугач, аны татарда сирәк очрый торган «Түрфәндә», ә улларын «Үзбәк» дип атаганнар.

Рөстәм Үтәмешев хатыны һәм улы Илдар белән. 1958 ел

Элеккеге чорлардан бирле, Үтәмешевләр Мәчкәрәдә мәдрәсә (1758 елда ачылган), тирә-юнь авылларда мәктәпләр ачканнар, мәчетләр төзеткәннәр һәм аларның чыгымнарын үз өсләренә алганнар. Тәрбияви юнәлештә укытуы белән танылган атаклы Мәчкәрә мәдрәсәсендә милләтебезнең күренекле шәхесләре Габденнасыйр Курсави, Хөсәен Әмирхан, Ш.Мәрҗанинең бабалары белем алган. Галим һәм язучы Адлер Тимергалинның мәгълүматларына караганда, ике катлы кирпеч мәчетне – ошбу карьянең беренче мәчетен 1791 елда үз хисабына беренче гильдия сәүдәгәр Габдулла бин Габделсәлам бин Үтәмеш төзеткән. Аның улы Муса Үтәмешев, икенче мәхәллә оешкач, агач мәчет салдырган. М.Үтәмешевнең тырышлыгы нәтиҗәсендә, мәҗүси удмуртлар күпләп мөселманлыкка күченгән. Мусаның эшен улы Исхак Үтәмешев дәвам итеп, бер катлы кирпеч мәчет бинасы төзетә һәм Аллаһ йортына 7 мең сум акчасын васыять итеп тә калдыра. Сәүдә һәм сәнәгать белән шөгыльләнгән Үтәмешевләр оештырган ширкәтләр Казан белән генә чикләнмәгән, алар Уфа, Оренбург, Себер якларында да эш йөрткән.

Булачак галимнең атасы Исмәгыйль Мөхәммәтгали улы Үтәмешев тә – кабатланмас шәхес. Ул Сембер гимназиясен алтын медаль белән тәмамлый, шундагы коммерция училищесында укый һәм Санкт-Петербургтагы политехника институтын тәмамлап, югары әзерлекле мөһәндис-инженер һөнәрен ала, берничә чит тел, шул исәптән, латин һәм борынгы грек телләрен дә үзләштерә. Исмәгыйль әфәнде җәмәгать тормышында да актив катнаша. Казан Шәһәр Думасына сайлана, каланың Шәрәфле гражданы исеменә лаек була. И.Үтәмешев инкыйлабка кадәр татар матбугаты битләрендә еш телгә алына. Үзенең туган авылы Мәчкәрәдә электр станциясе, су тегермәне төзетә, авыр крестьян хезмәтен җиңеләйтү өчен, күп кенә техник яңалыклар кертә, авылдашларына даими рәвештә ярдәм итеп тора. Шуңа да халык арасында аның һәм гаиләсенең абруе зур була. Җәмәгате – Зөбәйдә ханым мәшһүр дүрт бертуган нашир һәм миллионер сәүдәгәрнең

берсе – Мөхәммәтҗан Кәримовның кызы. Зөбәйдә дә гаять укымышлы, зыялы зат: ул үз вакытында Казан гимназиясен тәмамлаган. Утызынчы еллардагы күмәкләштерү дулкыннары Мәчкәрәгә дә кагыла. Үтәмешевләр ике катлы таш йортларыннан куылып, мәрхәмәтле кешеләрдә сыену урыны таба. Гаилә башлыгы кулга алына һәм Мордва урманнарындагы лагерьга сөрелә. Илле яше тулыр-тулмас, ул вафат була. Ике бала – алты яшьлек кызы һәм өч яшьлек улын кочаклап, «халык дошманы» Зөбәйдә ханым берялгызы утырып кала. Хәер, аны да тынычлыкта калдырмыйлар. Кеше-кара абайламасын, дип, 1929 елның кышындагы зәмһәрир суык бер төнне, тол хатынны балалары белән ат җигелгән чанага төяп станциягә озаталар. Меңәрләгән сөрелгәннәр белән, бергә аларны да, товар вагонына төяп, көнчыгышка таба алып китәләр. Кеше белән шыплап тутырылган вагонда ни ашарга, ни эчәргә булмый, хәтта сулыш алырга, иркенләп утырып барырга да мөмкинлек тудырылмый. Кайберәүләр шунда җан бирә, берәүләр үз-үзенә кул сала. Зөбәйдә ханым шул шартларда бердәнбер котылу юлы таба. Бервакыт кичен состав үр менгәндә тизлекне киметкәч, ул, форточкадагы чәнечкеле тимерчыбыкны сүтеп, бер-бер артлы ике нарасыен кар көртенә томыра һәм үзе дә алар артыннан иреккә ташлана. Алар, эз югалту өчен, Үзбәкстанга мең газап белән барып чыга һәм шунда миһербанлы кешеләр ярдәме белән төпләнеп кала. Һәм биредә яши башлагач, «Рөстәм»гә «Үзбәк» дигән хан исемен үзгәртергә туры килә. Ул биш яшеннән, апасына ияреп, мәктәпкә йөри башлый. Ни кызганыч, 16 яшендә Түрфәндә тиф белән авырып дөнья куя. Мәктәпне тәмамлагач, Рөстәм 1944 елда В.Чкалов исемендәге авиация заводында слесарь булып эшкә урнаша. Ташкентта эвакуациядә булган Ленинград авиация җиһазлары җитештерү институтына укырга кереп, инженер-электромеханик булырга хыяллана.

Сугыш беткәч, институт янә Нева буйларына кайтып урнаша. Булачак галим дә, Зөбәйдә ханымны алып, Ленинградка күченә. Ана кеше шушы уку йортында кием элүче булып эшкә керә. Икенче курста укыганда, Рөстәмне институтның профоргы итеп сайлыйлар. Бу вакытта шау-шулы «Ленинград эше» кузгатыла. Күп кенә галимнәр, шәһәр җитәкчеләре репрессиягә дучар ителә. Чират вуз ректоры Ф.Катаевка да җитә. Институтка «халыклар атасы»ның ышанычлы иярчене Г.К.Маленков җитәкчелегендәге комиссия килеп төшә. Вуз хезмәткәрләре һәм җәмәгать оешмалары җитәкчеләре белән бергә, профорг Рөстәм Үтәмешевтән дә сорау ала рәхимсез түрә. «Ректорыбыз бер дигән намуслы кеше һәм чын мәгънәсендә турылыклы коммунист», – дип ярып салгач, Р.Үтәмешевне профкомнан куу, ректорны исә эшеннән азат итү турында карар чыгарыла. Аллаһның рәхмәте белән, ошбу сынаудан да котыла Рөстәм. Югыйсә, меңәрләгән гөнаһсызның башына җиткән «иярчен» каршысында «халык дошманы» малае басып торганын белсә, азагы хәвефле булуы шиксез. Ректор Ф.Катаев исән кала һәм күпмедер вакыттан вазыйфасында яңадан торгызыла. Ул, шушы егетлеге өчен, Рөстәмгә гомере буе рәхмәт укый. Дәрте ташып торган яшь белгечне Хәрби һава көчләренең фәнни-тикшеренү дәүләт институтына – Мәскәү янындагы Чкаловскига җибәрәләр. Нәкъ менә биредә беренче космонавтларны әзерләү үзәге оештырыла. Хезмәт юлын лейтенант дәрәҗәсендә башлаган егет аны полковник булып тәмамлый. Баш конструктор Сергей Королев кулы астында эшли, Юрий Гагаринны һәм аның дусларын Галәм киңлекләренә озатуда турыдан-туры катнаша. Беренче космонавтны очышка әзерләгәне өчен, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. 1967 елдан унҗиде ел дәвамында Бөтенсоюз медицина техникасы җитештерү фәнни-тикшеренү институты директоры булып эшли, СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш метрологы, Биология һәм медицина өлкәләрендә исәпләүләр буенча Халыкара комитет рәисе вазыйфаларын башкара. Рөстәм Исмәгыйль улы – 300дән артык фәнни хезмәт, 120 уйлап табу авторы.

Рөстәм Үтәмешев оныгы Камилә белән. 1997 ел

Әлбәттә, шушы дәрәҗәле дә һәм бер үк вакытта үтә җаваплы да урыннарда хезмәт итү шома гына барган, дип әйтү хакыйкатькә хилафлык кылу булыр иде. Тирә-юнеңдә вак җанлы, мәкерле, кара эчле затлар булганда, татар зыялысына сынауларны җиңә алуда, үзеңнең хаклыгыңны исбат итә алуда ныклык, сабырлык кебек күркәм сыйфатлар кирәк булган.

Галимнең хезмәт биографиясеннән бер-ике шундый шомлы вакыйга турында искә алып китик. Беренче космонавтны очышка әзерләү барышында бер катлаулы җиһазны сынарга туры килә. Генераль конструктор кушуы буенча, Ю.Гагарин «Ротор» дигән бу җайланмага кереп урнаша һәм Р.Үтәмешев тумблерга баса. Капсула берничә минут дәвамында коточкыч тизлек белән әйләнә. «Ротор»ны туктаткач, Юрий капсуладан көч-хәл белән генә чыга һәм бик нык ризасызлыгын белдерә. Рөстәм Исмәгыйль улы, аны тынычландырып, болай ди: «Игътибар белән мине тыңла, бу вакыйга турында беркемгә дә сөйләмә, арабызда сер булып калсын, чөнки очышка сине җибәрмәсләр». Икенче көнне галим Сергей Павловичка тикшеренү нәтиҗәләре буенча хисап тота һәм реаль очыш вакытында шуның кадәр чамадан тыш авырлыклар кичерергә туры килмәячәк, дип фараз кыла һәм «Ротор»да күнегүләр ясау туктатыла. 1967 елның язында «Салют-1» дигән яңа космик корабльне очышка әзерләү бара. Анда Рөстәм Үтәмешевнең якын дусты – Советлар Союзы Герое, очучы-космонавт, инженер-полковник Владимир Комаров очарга тиеш була. Очыш Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгына багышлана, шуңа да КПСС Үзәк Комитеты, югары даирәләр, гәрчә очыш тиешенчә әзер булмаса да, эшләрнең тәгәлләнүе турында рапорт бирүне таләп итә. Урындагы эш башкаручы инженер, җаваплы хезмәткәрләр, әлеге басымга түзә алмагач, әзерлек беркетмәләрен имзаларга мәҗбүр була, әмма Рөстәм Исмәгыйль улы үзенең җаваплылыгындагы эшләрнең тәгәлләнмәгән булуын сәбәп итеп, беркетмәгә кул куюдан баш тарта. Җитәкчеләрнең моңа җен ачуы чыга. Бу вакытта Сергей Королев исән булмый инде. 23 апрельдә – туган көнендә «Салют»ка старт бирелә. Кайгылы хәбәр кич – туган көн уңаеннан җыелган мәҗлес кызган чакта килеп ирешә...

Р.Үтәмешевне тагын да югары урыннарга билгеләү турындагы мәсьәлә аның тормыш юлында берничә тапкыр калкып чыга, ләкин билгесез сәбәпләр аркасында кичектере-

Кукмара районының Мәчкәрә авылында Үтәмешевләр йорты

леп кала. 1975 елда Р.Үтәмешевне СССР Медицина сәнәгате министры итеп билгеләү, өч елдан СССР Дәүләт Стандарты комитеты рәисе урынбасары һәм 1983 елда илнең сәламәтлек саклау министры урынбасары итеп билгеләү турындагы карарлар аздан гына гамәлгә ашмый кала. Иң соңгы мизгелдә нindидер «кара көчләр» хәрәкәткә килеп, галимгә аяк чала. 1983 елның сентябрендә аны КПССның Мәскәү шәһәр комитетының Партия контроле комитетына чакыртып алалар һәм аноним сигнал бунча әңгәмә оештыралар. Әңгәмә бик «җанлы» узган, күрәсең. Галим, икенче көнне Таллинга халыкара конференциягә доклад ясарга барышлый, поездда авыр инфаркт кичерә, әмма эстон табиблары һәм хәләл җефете Рәдифә ханымның тырышлыгы белән аякка басып, эшен дәвам итә.

Рөстәм Үтәмешев, милли җанлы, зыялы нәселнең дәвамчысы буларак, татардан читтә ят кавемнәр арасында хезмәт итеп үзенә кәләшне Казанда тапкан. Аның җәмәгате Рәдифә Закир кызы Шаһивәлиева – укымышлы, затлы нәселдән. Алар 1953 елда гаилә корып, Звездный городокта (Йолдызлы шәһәрчектә) яши башлыйлар. Рәдифә ханым, югары белемле табиб-невропатолог буларак, сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәт итә һәм гомерен тулысынча гаиләсенә – газиз иренә һәм улы Илдарга багышлый.

2011 елның апрель азакларында Кукмарада, галим Рөстәм Исмәгыйль улы Үтәмешевнең тууына 85 тулуга багышлап, район хакимияте һәм мәгариф бүлеге мәктәп балаларының иҗади конкурсын һәм фәнни-гамәли конференция уздырды. Республика газеталарының берсендә хәбәрче буларак, миңа да бу чарада катнашырга, галимнең улы – техник фәннәр докторы Илдар Рөстәм улы Үтәмешев белән танышырга насыйп булды. Илдар әфәнде әтисе башлаган эшне дәвам итүче – галим-академик Мәскәү физика-техника институтын тәмамлаган. Ул медицина техникасы иҗат итү һәм төзүдә катнаша, бу өлкәдә эшләүче Гамәли эзләнүләр институтына җитәкчелек итә, Россия һәм Европа табигый фәннәр академияләренең гамәли әгъзасы, җәмәгать эшчәнлеге дә алып бара. Ул башкаладагы татар морзалары җыенын җитәкли. Галим төрек, инглиз, монгол телләрендә иркенләп аралаша. Аның Кытай, АКШ, Панамада булуы һәм бу илләрдәге фәннең үсеше турында сөйләве әле дә хәтердә. Ә иң мөһиме: Илдар Үтәмешев – газиз әтисе хакында, нәселләре турындагы берничә китап авторы. Ул «Рөстәм турында истәлекләр» дигән китабын очрашу хөрмәтенә миңа да бүләк иткән иде.

Рөстәм Мәһдиев ■

ЧУАШЛАР

Зариф Бәшири

КИЕМНӘРЕ ВӘ КУЛ ЭШЛӘРЕ

Чуашлар киемнәр өчен читкә бер дә юк диярлек дәрәҗәдә аз акча тоталар. Күлмәк вә ыштан кеби киемнәрен дә җитен-киндер сүсләреннән җеп эрләп үзләре тукыйлар. Чуашларның арыш кырларындагы һәр дисәтинә җирләре киндер илә чолганган буладыр. Җитен вә киндер эшләренә һәр игеннән артык әһәмият биреп эшлиләр. Яхшы тәрбияләп үстергәннең соңында, үз вакытында кичектерми йолкып орлыгын коялар да, сапларын талкып, сүс ясыйлар.

Хатыннары җеп эрләргә, киндер сугарга гаять дәрәҗәдә оста булып, эшләгән киндерләрен нәфис рәвештә ак, нәзек вә түземле итеп чыгаралар. Үзләре эрләгән җепләреннән, кызыл, сары вә кара төсләргә буяп, төрле-төрле нәкышләр төшереп, дастымал, сөлге, җәймә, чигешле күлмәк, тастар кеби нәрсәләр тукыйлар.

Чуаш хатыннарында сугу-туку, эрләү кеби һөнәрләрне яшьтән үк өйрәнү гадәт булып калган. Бу һөнәрләрне соң дәрәҗәдә әһәмият илә өйрәнәләр. Синтәбер, үктәбер числоларында урам тулган чуаш хатыны вә кызлары сүс талку, җитен вә киндер тукмаклау кеби эшләр илә мәшгуль булалар. Кышка керсәләр, кечкенә генә лампа тирәсенә

Чуаш хатын-кызлары милли киемдә.
Фото Чуашстан Республикасының Яльчик районы рәсми сайтыннан алынды

Ахыры. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

җыелып утыралар да, җеп эрләү илә шөгыльләнәләр. Хәтта кызлары вә яшь киленнәре чит авылларга кунакка утырмага барганда да орчык, каба кеби җеп эрли торган коралларын калдырмый алып барып, анда да өйдәге кеби эшлиләр. Чөнки аларда кунакка бару вә килү кебиләр, артык ясалма кылану илә сыйлашу, чиктән тыш риялыклар илә хөрмәтләшү булмаенча, бер-берен күрү, хәл вә әхвәл сорашу, көн итү хакында фикер алышу булганга, эшне туктаткан бернәрсәдән саналмыйдыр. Менә шуның өчен дә алар күлмәк-ыштан, мендәр вә ястык тышлыклары, дастымал вә җәймә кеби нәрсәләр өчен фабрикаларның түземсез материалларына барлы-юклы ашлыкларын саткан акчаларын әрәм итмичә, үз кул һөнәрләре илә канәгатьләнәләр.

Бәйрәм вә кунак киемнәре чиста вә нәфис рәвештә эшләнгән булып, ирләренеке кызыллы кара вә күк алачалардан, ак киндерләрдән, хатын вә кызларыныкы кызгылт кара вә күк алачалардан буладыр. Ләкин шимал *(төньяк)* чуаш хатыннарының бер өлеше ак киндердән күлмәк кимиләр.

Гадәттә эш вакытында кия торган күлмәк вә ыштаннарында чисталык вә нәфислеккә бик игътибар ителенми. Ак вә кара төстәге калын киндер җепләр илә тукып ясалган тупас киндерләр вә алачалардан ясалган күлмәк тузып каткан вә әшәкеллеккә әйләнгән буладыр.

Аларда дөм-кара киндердән күлмәк вә ыштан бөтенләй юк диярлектер. Фәкать бәгъзе чуашларда җәйлек өчен булган тужурка вә пиджак рәвешендә ясалган простой киемнәре генә зәңгәр сыман кара киндердән була. Хатын вә кызлары рус барышнялары кия торган «куфтачка» рәвешендә бернәрсә ясап кияләр.

Аяк киемнәре ирләрендә вә кыз-хатыннарында бер төстә булып, озын баулы (киндерәле), зур вә тупас чабата илә үзләре баскан калын туладан, киң вә кыска балтырлы оек (чуашча – «чулка») буладыр. Бәгъзе ирләре вә хатын-кызлары аякка махсус тукылган калын ак киндер чорныйлар. Моңа Казан артлары – «аяк эштәри», мишәрләр – «пүртәнгә», чуашлар «пиртулла» диләр. Кыш көннәрендә күбрәк җон җебеннән тукыганын чорныйлар. Бунысына исә «җонтулла» диләр. Бу аяк киемнәре ирләренә ошаса да, кыска күлмәкле хатыннарына, аякларын багана кеби калын күрсәткәнгә, бик килешсез булып торадыр.

Кышкы киемнәре җон җебеннән тукылган кара чикмән илә сары (дублы) тун булып, төсләре вә тегүле рәвешләре хатын-кызлары илә ирләрендә һич аермасыз бердәй буладыр. Кирәк ирләрендә вә кирәк хатыннарында һичбер вакыт ак чикмән киелмәс.

Киемнәренең форма җәһәтенә килсәк, ирләренең күлмәк вә ыштаннары русларныкыннан бик аз аермалы булып, күлмәкләре – тар вә кыска, ыштаннары тар вә озын буладыр.

Чикмәннәренең кайтарма якасызы, авыл русларының милли казакилары кеби, арттан вак-вак бөрмәләгән билле буладыр. Туннары шундай билле булып, чабуларына вә күкрәк өсләренә саргылт кызыл вә яшел төсләрдә җәтмә дигән бернәрсәне боргалап тоткан булалар.

Җәйлек казакилары ирләрендә һәм хатыннарында кара материалдан. Вак-вак бөрмә билле якасы, авыл татарларының кайтармасыз каймалы кыек җилән якалары кеби булып, сары, кызыл вә яшел җепләр илә боргалап-боргалап куйган буладыр. Ләкин бу күбесенчә байларында гына була.

Башларына җәен – фуражка, үзләре баскан эшләпә, кыш – рус бүрегенә охшашлы озын бүрек илә татарларның малахай бүрекләрен кияләр.

Хатын вә кызларының җәйге нечкә һәм зиннәт өчен булган киемнәре, хәзерге милләтләрнең һичберсенә дә охшамый, бөтенләй үзләренә аерым бер рәвештә буладыр. Бәгъзе берләре электәге татар хатыннарының киемнәренә охшый дияргә ярарлыктыр.

Күлмәкләре, капчык кеби тәнгә ябышып торган тар вә тездән бераз гына озын булып, түбәнгә, итәк өстенә ике-өч вершок киңлегендә күк күлмәккә – кызыл вә кызыл күлмәккә – яшел яки зәңгәр төстә бер-ике катлау тар итәк тоткан була. Бу итәк Казан тарафындагы авыл хатыннарында да бар. Моңа татарларда һәм чуашларда «куштан итәк» диләр. (Бу урында куштан сүзе фантазия дигән сүз урынына әйтелсә кирәк.) Изү тирәсенә, татар хатыннарыныкы, кеби кызыл вә сары һәм яшел вә зәңгәр төсләрдә булган тар ситсыларны мич капкачы рәвешендә ярты түгәрәк итеп әйләндереп тоткан була. Моңа «сабма изү» диләр. Баераклары моның өстенә вак көмеш тәңкәләр дә кадап зиннәтләнәләр.

Сачләрен, үреп, чулпы вә тәңкәләр тагалар. Күкрәкләренә иске тәңкәләр тезеп ясалган хәситә* кияләр, ләкин хәситәләрендә, татар хатыннарыныкы төсле ачык, челтәр кеби шара-бара нәрсәләр булмыйча, фәкать тәңкә генә була.

Башларына исә кызлары гадәттә вә эш вакытларда катлап яулык вә кечкенә генә шәл баласы баглыйлар. (Бу татар вә мишәр кызларында да шулай ук.) Әмма бәйрәмнәрдә такыя кияләр. Такыя исә ярты карбыз кабыгы рәвешендә бернәрсә булып, өстенә кырыеннан түбәсенә кадәрле рәт-рәт иске тәңкәләр кадап ясалган була. Ике чигә өстеннән тамак астына кадәр тәңкәдән оештырып ясалган бүрек колакчасы кеби нәрсә төшерелгән буладыр. Кайберәүләр моны простой пыяла, энҗе вә төймәләрдән дә ясыйлар.

Хатыннары исә башларына тастар баглыйлар. Тастарлары шушы рәвешле була: киң, кызыл тирәле ак яки ак тирәле кызыл дастымал кеби нәрсәне тамак астыннан алып, ике очын баш түбәсенә китереп баглыйлар, соңра сөлге кеби озын бернәрсә илә маңгайларын вә баш түбәләрен чорныйлар да баш артыннан чалып алып, ике очын тез астына кадәр салындырып төшерәләр. Бу салынып төшкән очлары, сөлге башлары кеби, төрле-төрле төсләр илә чигелгән буладыр.

Җәнүби *(көньяк)* чуаш хатыннарының бер өлеше ике сөлге кеби нәрсәне ишеп тастар өстеннән башларына чалма кебек итеп чорныйлар.

Кызлары вә хатыннары муеннарына төймә-тезмәләре, яка чылбырлары, колак алкасы тагалар. Бармакларына йөзек кияләр.

Гомумән, чуаш хатыннары вә кызларының иң кадерле вә сөемле җиһазлары – иске көмеш тәңкәләрдәндер. Шуның өчен аларда әллә кайчангы иске тәңкәләрне күп очратырга мөмкин.

ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ, ЙОРТ ВӘ БАЛА ТӘРБИЯЛӘРЕ

Чуашларның хатын-кызларында ирләреннән аермалык галәмәтләре бик аздыр. Әхлак, тәрбия вә тормышлары тәмам ирләренеке белән бер булып, ирләре ниндәен эшкә икътидарлы булсалар вә эшләсәләр, хатын вә кызлары да шуңа тиң булалар вә эшли алалар. Эшли алалар гына түгел, бәлки үзләренең вазыйфалары хөкемендә дип беләләр.

Сука сукалау, урак уру, печән чабу, иген сугу, урман ташу, утын кисү кеби эшләрне ирләре белән бергә торып эшлиләр. Кызлары 15-16 яшькә җитмәс борын печән чабарга өйрәнәләр. Хәтта мондый эшләргә өйрәнмәгән кызларына: «Эшлексез, уңмаган кыз!» – дип, нәфрәт күзләре белән карыйлар. Иң мактаулы кызлары да печән чабарга, зур кибәннәр өяргә маһирәләрдер. Ат ашатырга бару, атланып чабышларга йөрү кеби хатыннарга бөтенләй кагылышы булмаган, һичбер милләттә күрелмәгән эшләрдә дә

*Хәситә яхуд хәсилә – бу мишәр сүзе «касыйдә»дән алынган булырга тиеш. Электә «касыйдә»не, бөти урынына, муеннарына тагып йөргәннәр. Тау як татарлары моңа «ачкыч бавы» диләр. – З.Б.
«Шура»: хәситә вә хәсилә сүзләре «хасыять»тән алынган булса кирәк.

ирләреннән калышмыйлар. Тик бары чабата туку, арфан вә дилебкә ишү кеби ирләрнең кичке өй эшләренә генә тыгылмыйлар.

Чуашларның хатын-кызлары, сабый вакытларындагы ана тәрбиясеннән башлап, махсус тормыш мәшәкатьләренә иялэшеп вә шул тәрбия белән тәрбияләнеп үсәләр. Менә шулар өстенә, йорт вә бала тәрбияләре дә алар өстенә йөкләнгән буладыр. Шуның өчен дә аларның өй эчләре әшәке вә пәс була. Балалары да тәрбиясез вә тупас холыклы булып үсәләр.

Бердән, ошбу сәбәпләргә вә икенчедән, җаһиллекләреннән, аларның хатын-кызлары үзләренә махсус булган нәзакәт вә хиссият, нечкәлек вә җазибият, шәфкатьлелек вә йомшак табигатьлелек кеби сыйфатлардан гари булалар. Шушындый таифәнең хатыннарында йорт вә бала тәрбиясенә караган гүзәлчә нинди тырышлык булсын да, аларның балалары күркәм әхлак вә әдәп кебиләрне кайдан ала белсеннәр? Табигый, күркәм әхлак вә әдәптән ерак, шуның белән бәрабәр куркак вә җөрьәтсез булып җитешәләр. Бала тәрбияләүләрендә миллилек рухын кертү, икътисадка иялэштерү кеби гүзәл сыйфатлары да юк түгелдер.

Шуны да әйтеп китәргә мөмкиндер ки, чуашларның хатыннары, шушы кадәр тупас булган авыр хезмәтләргә җигелеп өстерәсәләр дә, тиз картаймыйлар. Ирләр табигатенә охшаш табигатьле, тупас тормышлы булган сөякләре белән бәрабәр яшьлектә булган матурлыкларын тиз генә югалтмыйлар. Чөнки аларның кызлары кара тутыклы, кара кашлы, үткен күзле булып, төскә соң дәрәҗәдә матур булалар. Ләкин ни чара ки: ирләр табигатенә якын табигатьләре, тупас вә килешсез киемнәре бу матурлыкларын хасиятьсез калдырадыр. Кызлары артык киенеп көязләнергә дә бик һәвәсле булмыйлар.

Чуашларның хатын-кызлары гаять дәрәҗәдә хөррәләрдер. Теләсә кайда барсын вә теләсә нинди эшне кыйлсын, үз ихтыяры белән эшли вә ирләреннән һичбер ачы сүз ишетмидер. Йорт эшендә ирләре ни эшләсә, болар да шуны эшләргә ихтыярлы булып, ирләре ни кисә, шуны кия, ирләре ни ашаса, шуны ашыйдырлар. Шуның өчен дә аларның ир белән хатын арасында кычкырыш-талаш кеби тавышсызлыклар бөтенләй үк булмыйдыр. Чуаш хатыннары никадәр хөррә вә һәрнәрсә үз кулларында булса да чиктән тыш тәкәллефләргә манчылып артык исрафларга кул сузмыйлар, киресенчә, түшәкләренә күрә генә аякларын сузалар ки, гаять саран да, исрафчан да булмыйча, ныклык белән генә көн үткәрергә тырышалар. Чөнки алар тормышның мәшәкатен ирләре белән бергә күтәрәләр.

Кабат булса да әйтәмен: чуаш хатыннары, никадәрле авыр вазыйфаларга җигелсәләр дә, мәҗбүри түгел, ихтыярыйдырлар. Бәлки алар ирләре белән бер сафта хезмәт итүләренә мәгърурәләрдер.

Издиваҗ *(өйләнү)* мәсьәләсенә килсәк, чуашларның үзләренә махсус бер шәригатьләре юк. Әмма шулай да булса, акыртып-бакыртып кыз бирмәк, ризалыгыннан башка сатмак кеби әшәкелекләрдән пакьтерләр. Бәлки кызлары вә егетләре, үз ихтыярларында булып, бер-берсен күреп сөйләшеп вә ризалашып өйләнешәләр. Хәтта аларда низам каршысына дәлил торткан никах шартлары кеби нәрсәләр урынына «үзе сөеп бару вә теләп алу» нык бер ышаныч вә низам булып тотыладыр. Чөнки аларда никах дигән нәрсә, шаһидлар куеп, дәфтәрләргә язып беркетүләр белән булмыйча, бәлки егет белән кызның «ризалык белән алдым-бирдем»нәреннән генә гыйбарәттер. Бер тәкъдир ир, бер айдан соң, рисваи итеп куып җибәрсә, хатын һичкая барып: «Бу минем иремдер», – дип дәгъва итә алырлык төпле бер дәлил тота алмыйдыр. Шулай да булса, аларда бер алган хатынны аеру, икенче хатын алу кеби инсаниятсезлекләр генә түгел, араларында татусызлыклар да булмыйдыр. Бәлки дә бер-берсенә таянып, бәхетле тормыш белән гомер итәләр. Чөнки алар үзләре күрешеп, бер-берсен сынашып

вә сөешеп өйләнештеләр, эткәләренең күн бияләй киеп барышныклык итүләре белән түгел. Менә бу гүзәл вә бәхетле тормышлар, әлбәттә, хатыннарының хокукта тигез вә иркле булуларыннан килгән бер өстенлектер.

Шул кадәресе гаять гаҗәптер ки, аларда гыйффәт дигән нәрсәнең һич әһәмияте юктыр. Бер кыз кирәк бакирә *(гыйффәтле)* булсын, кирәк булмасын, игътибарга алынмый. Шуның өчен дә аларның кызлары гыйффәтләрен бик иртә җуялар вә шуны гади бер эш хөкемендә белеп, ояттан да санамыйлар. Хәтта шулкадәреге бардыр ки, бер кыз яшьтән егеткә катнашып йөрмәсә, уеннарда вә җыеннарда биергә үзенә бер иптәш таба алмаса, аның ата вә анасы, бөек бер дәрәҗәдән төшкән кеби: «Кызыбыз егетләргә катнаша алмый!» – дип, аһлап, хәсрәт чигеп вә башкалар арасында да зур бер гаепле кеше кеби боек рәвештә йөриләр.

Бу чиктән тыш хөрриятне «шәригать эстәүчеләр»ебез бәлки дә «хатыннарның хокукта тигезлекләреннән вә артык ирeклелекләреннән» дип тә әйтәләр. Ләкин бу наданлык сәбәпле булган вәхши бер гадәт кенә булса кирәк. Безнең татар кызлары, никадәр тарлыкта вә читлектә булсалар да, йөзләренә читалар бәйләп йөрсәләр дә, наданлыклары вә бигрәк тә чиктән тыш әсарәттә *(әсирлектә)* булулары сәясендә, бөтен шәһәрләрне фәхешханәләр белән тутырмактадырлар. Хәлбуки, чуашларның хатын-кызлары фәхешханәләрдә бер дә күрелмәсләр.

Чуаш хатыннарында пакь, күркәм гадәтләр дә очраштыргалый. Мисал: гайбәттән саклык, хыянәттән ераклык, ялган сөйләүдән пакьлек кебиләр. Кайбер милләтнең хатыннары арасында гайбәт кеби кабахәт сыйфатлар гади бер эш урынында булмыш вә ләззәт белән кулланылмактадыр. Аеруча безнең татар хатыннары өч-дүрте бергә җыелып булсын, мәҗлесләрдә булсын, гайбәт ашап, юк-бар хикәяләр сөйләү белән вакыт уздыралар. Бу исә эшсезлектән килгән бер авыру булса кирәк. Дөрес, чуаш хатыннары да сөйләшәләр, ләкин гайбәт түгел, бәлки кирәкне сөйләшәләр. Чөнки алар эшсез түгелләрдер. Гыйлем вә мәгарифтән хассыз вә тәрбиядән ерак булган бу таифә хатыннарында шундый күркәм гадәтләрнең булуы һәркемнең күкрәгендә әһәмиятле бер фикер кузгатса кирәк, дип уйлыйм.

Чуашларның ирләре гыйлем җәһәтеннән ничек булса, хатыннары да шулайдыр. Бу көндә ирләреннән нинди тәрбияләнүчеләр булса, хатыннарының да шундый тәрбияләнүчеләре ирләр белән бер хисапка туладыр. Шулай булгач, чуашларның мәдәният багчасына аяк басулары өмидле аяк басудыр.

КӨЙЛӘРЕ, МУЗЫКА ВӘ ХИССИЯТЛӘРЕ

Инсанның күкрәгендә хиссияте никадәр куәтле булса, аның эшләгән эше дә шул дәрәҗәдә дәртле өмид белән эшләнәдер. Адәмнең хиссият вә дәртен кузгатучы да ике төрле нәрсәдер ки: бере дә – музыка вә икенчесе дә – җырудыр. Дошман каршысына тезелеп куркуыннан дерелдәп торган гаскәр, музыка вә җыр тавышлары белән күтәрелгән хиссиятләренә көчләре арткан, җиңү өмидләре ныгыган хәлдә, дошманнары өстенә ыргыла. Ниһаять, болар сугыш мәйданында өстенлек алалар. Дарга асылынган бер мәхкүм, янында уйналган музыканың тәэсире белән, газиз җаннан аерылганын сизми дә каладыр.

Кыскасы, музыка белән җыру һәр эшнең башы вә һәр каһарманлыкның тамыры димәк мөмкиндер. Шуның өчендер ки, моны аңламаган вә моңа һәвәс алмаган һәр милләт, сугыш мәйданында булсын, башка ярышларда булсын, җиңелүгә, түбән тәгәрәүгә юл тотадыр. Ләкин шуны да әйтеп китәргә мөмкиндер ки: дөньяда һичбер милләт юктыр, ул милләтнең үзенә махсус музыка вә җырулары булмасын. Фәкать бу

үле милләтләрдә тәэсираты зәгыйфь, йогынтысы тупас, зәвык вә ләззәте аз, бөтенләй хиссиятсез булып, җырлануы да күбесенчә фәхеш вә исереклек мәйданында буладыр.

Безнең «Тәфтиләү», «Ашказар» вә «Сәлим бабай» кеби иске көйләрне, хәзерге Казан такмакларын алсак, нә дә музыкадан вә нә дә авыздан ишетелгән тавышлары күкрәккә нинди хис бирә дә, йөрәктә нинди дәрт вә өмид багларлык бер урын кора? Шулай ук җырулар да әүвәле агачтан, таштан, соңыннан җанкай-җанаш, пумала баштан бәхәс итеп, бер-беренә мәгънәсез коры бер тратата көенә оештырган татар сүзләреннән генә гыйбарәт булганлыктан, тыңлап торучыларны ләззәтләндерү, нечкәртү читтә торсын, бәлки күңелне болгандыра, эчне генә поштырадыр. Менә болар шуның өчен дә фәхешханәләрдә вә исереклек йортларында исерекләр агызыннан гына җырлана вә роль казанадыр. Чөнки болар җансыз милләтебезнең үле көйләре вә җырларыдыр.

Дөрес, бу җөмләләребезнең сәбәпчесе булган чуаш милләте дә, тыштан караганда, үле бер милләттер. Ләкин моңа кадәр язган нәрсәләремне ашыкмый гына укыгыз да, аларның икътисади тормышларын, миллилекләрен, намуслылыкларын, тырышлыкларын, бу көндәге хәрәкәт вә уянуларын, гыйлем-мәгарифкә омтылышларын күреп, чуашлар чыннан да әле үле яки җитешмәгән, дип әйтә алмассың!

Чуашларда музыкага мәхәббәт, милли көйгә омтылыш шулкадәре шәптер ки, алар үзләренең шул тупас көйләре, татсыз җырларын айтар-айтуклары белән боргалый-боргалый җырлаганда, бөтенләй үзләрен онытырлык дәрәҗәдә хиссияткә чумалар.

Һичбер чуаш юктыр ки, эшләгән вакытта һава ярып җырламасын. Җәен печән чапканда, көзен урман кискәндә бөтен сахра вә урманны яңгыраткан җыр вә тавыш моңлы чуаш егете белән батыр күңелле чуаш кызының авызыннан чыккан буладыр. Чөнки алар: «Көй куәтне арттыра, көчне күбәйтә, эштән читли торган бернәрсә белән шөгыльләндерми», – дигән кагыйдәне алга алганнардыр һәм дә эшләрне дә тырышлык вә түземлек белән башкаралар. Үзләренең тәҗрибәләре белән шуны дөрес дип белгәнгә вә игътикад кылганга күрә дә эш вакытында берәрсе ара вә ялкаулана башласа: «Әй, ялкау, арый башладыңмы инде. Җәле, бер җыру җырлап җибәр дә күңелең күтәрелеп, арганлыгың бетеп китәр!» – диләр.

Музыкадан иң яратып уйный торган нәрсәләре – думбра белән скрипкадыр. Яшьләре арасында боларны уйный белмәгән бик аздыр. Хәтта боларны күбесенчә үзләре ясыйлар да. Туйларда, бәйрәмнәрдә, эшсез вакытларда думбра уйнап бию – аларда күркәм эштер. Җыелып утырган яшьләре арасында музыка уйнаганда картлары хисләнеп тыңлап утыралар. Музыканың тәэсиреннән араларында яхшы ук хәрәкәт тә башланып: «Ай, бар иде соң яшь чаклар!» – дип, дәртләнә-дәртләнә иске хикәяләр дә сөйләшеп алалар. Гомер буенча эчләренә җыелган аһ вә тәэсирләрен шул урынга түгеп калдыралар.

Хатын-кызларында музыка кулланмак гадәте бөтенләй үк юк. Фәкать алар бииләр генә. Биюләре исә, ирләр белән егетләрендә бер ысулда булып, һичбер төрле кагыйдәгә салынмаган татарча аяк чалмаштырып сикеренүдән генә гыйбарәттер. Бары шунысы гына татарчадан аерыладыр ки: кызлар белән егетләр һәрвакыт бергә тотынып биилләр. Биегән вакытта такмак әйтеп тору гадәт булса да, музыка уйнаганда парлап җырламак гадәте юктыр.

Бердән, артык хисләндекләреннән вә икенчедән, йомшак яшьле булганлыкларыннан, музыка уйнаганда еламаган чуаш бик аз буладыр. Елаганда күбрәк сөйгәннәрен сагынып, аны мактый-мактый сызланалар, чөнки аларда гашыйк вә мәхәббәт исемле нәрсә яхшы ук бардыр. Шулай булса да, сөйгәнен алмый калган егет, сөйгәненә бармый калган кыз аларда бик сирәк очрыйдыр. Аның өчен аларда кавышудан чикли торган шәй юктыр, ягъни байлык, ярлылык, фамилия кеби нәрсәләр гашыйк белән мәгъшука арасына аркылы төшә алмыйлар.

МОСАФИРПӘРВӘРЛЕК, ЯХШЫЛЫК ВӘ ӨЛФӘТЛЕЛЕКЛӘРЕ

Чуашларда мосафирпәрвәрлек сөемлек шәйләрнең иң күркәменнән вә олугсыннан саналадыр. Алар шуның өчен дә Аллаһы Тәгаләдән иген вә яңгыр сораганда: «Мине мосафирлар вә яхшы затлардан булган кунаклар алдында оятлы итмә», – дип дога кылалар.

Читтән бер гаҗиз кеше аларга килеп төшсә, кирәк нинди диннән вә милләттән булса да, аны «Алла кунагы», дип гаять хөрмәтлиләр вә үзләренең иң сөемле ашларыннан булган кара икмәк белән тоз, ачы кәбестә, тозлы балык вә өй сыраларын тәкъдим итеп ашаталар, эчерәләр. Кыскасы, кулдан килгән кадәр хөрмәттән тартынмыйлар. Бигрәк тә башка милләттән булган мосафирларның канәгать булуы – болар өчен бөек бер нигъмәттер.

«Мосафирларга – хөрмәт, гаҗизләргә – ярдәм, картларга кечеклек – бабайлардан мөкатдәс мирас булып калган», – диләр һәм шуны һичбер вакытта югалтмаска вә үтәргә тырышалар. Аларга бер мосафир кереп, канәгать булуын белдереп чыкса, бөтен эчләре шатлык белән тулып, Аллага тәшшәкерләрен озаталар. Табигый, чит җирләрдә алҗып йөргән бер мосафир яки ачка аптыраган бер зәгыйфь аларның риясыз вә тәкәллефсез хөрмәтләренә, сөемле ашларына, ачык йөзләренә мәмнүн булачаклардыр. Бигрәк тә башка милләттән булган мосафирлары канәгать калса, болар өчен бөек бер нигъмәттер.

Чуашларда моның белән бергә «Яхшылык юлда ятмас» мәкале тагын да шәбрәк роль казанган. Алар шуннан файдаланмакчы булып, башка милләтләргә катнашырга вә аеруча татарлар белән арада татулык вә өлфәт хасил итәргә теләсәләр дә, безнең һәрбер кабахәтлекне диннән санап, үзләреннән уздырмаска тырышкан татарлар вә мишәрләр бичараларның ашларына каршы таш белән җавап кайтаралар. Чуашлар кулдан килгән кадәре яхшылыкларын ничаклы аямыйча: «Кан-карендәшләребез, якын вә иске күршеләребез», – дип, йомшак вә мөлдерәгән күз белән карап, һәр өмидләрен аларга салырга базынганда, татар агайлары ике өлеш артык золымнарын аямыйлар.

Бу көндә наданлык вә тәрбиясезлекнең иң соңгы ноктасына кадәрчә килгән бер кавемнең күкрәкләрендә булган кардәшлек вә күршелек хисен саклый алулары вә шуны яңадан терелтеп өлфәт вә мәхәббәт юлындагы актык гайрәтләрен сачрәтүләре, үзләренең яңадан тәрәккый вә мәдәният рельсәсе белән йөгерүләре хакында, кирәк матбугатта вә кирәк хыялда сафланган бер өмиднең хак вә тугры идекен исбат иттеке кеби, үзләренең ахирәви мәнфәгатьләрен генә күзәтеп, саф диндарлыкларын аяк астына таптаган бәгъзе татар кардәшләребезнең бу кеби инсаниятсезлекләре ирекле-ирексез кан агулатырга мәҗбүр итә түгелме?!

Шура. – 1909. – №17. – Б.531-534; №19. – Б.591-593; №21. – Б.654-656; №22. – Б.685-686.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Бурятларның җәйге өйләре

БУРЯТЛАРДА ҖИР МӘСЬӘЛӘСЕ

Бурятларның тормыш-көнкүрешенә караган кайбер нәрсәләр турында сораштырганнан соң, мин җир мәсьәләсенә күчтем. Бу хакта Хамба Лама ошбу мәгълүматны бирде:

– Бу мәсьәлә бездә әлегәчә төгәл генә хәл ителә алмады. Җир күп, ләкин безнең бурятлар бик иркен яшәргә күнеккәннәр. Шунысы да бар: Себер җирләрен Русиянең эчке төбәкләре белән чагыштыру бик зур хата. Бөтен губерналарда да җир бертөрле итеп бүлеп бирелергә тиеш түгел. Русиядә, мәсәлән, Кырым якларында, кешенең 3-5 дисәтинә җире булса, ул гаиләсенең тормышын алып бара ала. Әмма Казан, Уфа губерналарында һәр кешегә 15 дисәтинә җир булмаса, авыл кешесе тормышын тарта алмый. Себердә һәм биредә исә 30 дисәтинәң булмаса, тормыш көтү бик авыр. Бүгенге көндә безнең бурятларның һәрберсенә 15 дисәтинә җир бүлеп бирү – «Сез ачлыктан үлегез!» – дигән сүз белән бер. Шуңа да карамастан, Русия хөкүмәте

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

җирне нәкъ менә 15 дисәтинә итеп бүлеп бирергә уйлый. Кыскасы, безнең шәхси милегебез булган җирләрнең 15 дисәтинәдән артыгын хөкүмәт көчләп кулыбыздан тартып алачак һәм күчеп утыручыларга бирәчәк. Русиянең эчке төбәкләреннән бирегә кеше күчереп утыртачаклар. Ләкин бу безнең җирләр, кулыбызда бу җирләрнең ата-бабаларыбыздан калган милегебез икәнен раслаучы кәгазьләребез, чын мәгънәсендә документларыбыз бар. Тик хөкүмәт моны кабул итми. Кем нәрсә дия ала? Чарасызлык. Гомумән, бөтен Себердә бу канун тиздән үз көченә керәчәк.

БУРЯТЛАРДА ГАИЛӘ ТОРМЫШЫ

Бурятлар борынгы заманнардан бирле күчмә тормыш белән яшәгәннәр. Бу соңгы елларда исә, яз-җәй айларында күчеп йөриләр дә, кыш көннәрен үзләре «улус/олос» дип атый торган ике-өч йорттан гыйбарәт авыллар хәлендә утрак тормыш белән үткәрәләр икән. Кышлык йортлар агачтан салынган, эчендә бүлмәләр юк. Өйләрнең эчендә дә, тышында да бернинди бизәк күрмәссең. Гаиләдә ничә кеше булса, барысы да шул бүлмәсез йорт эчендә бергә яшиләр. Искиткеч пычраклык, юынуның, мунчаның ни икәнен дә белмиләр, арулык ни – хәбәрләре юк. Ләкин үзләре бик кунакчыл халык. Күп кенә яклары безнең далада яши торган казакъ халкына охшаган. Аеруча язгы-җәйге күчмә тормышлары казакъларныкы белән бер үк. Җәйге йортлары – тирмәләре дә казакъ тирмәләре кебек. Биредә бурятларның җәйге өйләренең рәсемен сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәм.

Бурятлар күп кенә эшләрдә Аксакаллар җыены карарына буйсыналар. Борынгырак чорларда гаеплеләр, җинаятьчеләр дә аксакаллар алдына китерелә торган булган, эшләре кичерү яки җәза бирү юлы белән хәл ителгән. Зур, җитди дәгъвалар каралганда, аксакаллар берничә кеше җыела, ә инде вактөяк низаглар тикшерелгәндә, ике-өч аксакал җыены да катгый карар кабул итә ала икән. Аксакаллар җыенының рәсемен дә бирәм.

Хәзерге вакытта бу Аксакаллар җыены хөкүмәт тарафыннан билгеләнеп куела, ләкин элегрәк алар сайланып куела торган булганнар.

Бурятларның Аксакаллар җыены

Бурятларның өйләрендә җиһаз дип атарлык берни дә юк, бары тик ике-өч «бурхан», ягъни пот куелган. Бурханнарның яннарында каһвә чынаягы кебек кечкенә савытларда су тора. Гыйбадәтханәләрендәге потлар янына да нәкъ шулай ук су куялар. Су – бурхан хакы өчен бирелә торган миннәтсез сәдака булып санала икән. Төп ышануларының берсе – сәдака кабул булсын өчен аның миннәтсез булуы шарт икән, ә су һәр җирдә мул, миннәт* булу ихтималы юк.

Бурятларда хайван бик күп, бу бөтен Монголиядә шулай. Хайван җитештерүдә алардан да остасы юк, бу яктан да безнең казакълар белән бәйләнешләре бар. Бер аермалары бар шулай да – казакълар ат сөтеннән кымыз ясыйлар, бурятлар исә, турыдан-туры аракы ясыйлар, ләкин төрлесеннән ясый алалар: сыер сөтеннән дә, куй-сарык сөтеннән дә. Сөттән ясалган аракы бик куәтле була, ди. Хамба Ламаның фикеренә күрә, бурятларда нәселләрнең бозылуының сәбәбе дә нәкъ менә аракы күп эчү белән бәйле. Сөт аракысын эчүнең элекке заманнарда билгеле бер вакыты, елның бер вакытында гына бу мөмкин булган.

Хамба Лама сөйләгәннәренә болай дип өстәде:

– Ләкин бүгенге көндә кышын-җәен туктаусыз эчәләр, гел исереп йөриләр. Менә шул сәбәпле, нәселләр начарайды. Бик зур тизлек белән кими, югала барабыз.

– Шулай булуы бик мөмкин, – дидем. – Сүзләрегезне куәтләп, русларның тормышында күргәннәремне сөйләп китәргә телим. Мин, Петербургта яшәгәндә, Литейный (проспект) урамында, Мариинск хастаханәсенең каршысындагы бер йортта тордым. Шул вакытта бер нәрсә игътибарымны җәлеп иткән иде: хастаханәгә рус хатыннары чәршәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрне бик күпләп киләләр, башка көннәрдә бик күренмиләр иде. Хастаханә мөдире белән таныш идем, беркөнне: «Нигә шул-шул көннәрдә авыруларыгыз бик күп, ә башка көннәрдә бик аз була?» – дип сорадым. Мөдир миңа: «Шулай булуы бик табигый, безнең руслар атнада өч көн – шимбә, якшәмбе һәм дүшәмбе көннәрне күбесе эчәләр, сишәмбе көнне дә әле тиешенчә айнып җитә алмыйлар. Менә шул син санаган көннәр генә кала да», – дип җавап бирде. Монда да аракы эчүнең нәселләр яшәешенә йогынтысы булуы аңлашыладыр дип уйлыйм.

– Мин бу халык арасында туып-үстем, тәҗрибәм дә зур. Минем фикерем буенча да, бу чынлап та шулай.

Хөрмәтле укучыларыма тагын шуны да белдерәсем килә: Хамба Лама – заманча мәктәпләрдә укып белем алган кеше түгел, бары тик монгол телендә, борынгы монгол әдәбиятын һәм фәлсәфә әсәрләрен укып нәрсә белә алган булса, бөтен мәгълүматы шул.

Рус телен дә ул соңрак үзлегеннән өйрәнгән. Ләкин гаять киң мәгълүматка ия, үзен-үзе белгеч итеп әзерләгән бу кеше шәрык дипломаты дип аталырга лаеклы. Гомумән, бик борынгы заманнардан бирле, укый-яза белмәгән философлар нәкъ менә шәрыкта җитешкән дә инде.

Бу кеше белән өч көн буе аралашу нәтиҗәсендә бик күп мәгълүмат тупладым.

Аерылыр вакыт җиткәч, Хамба Лама бөтен ламалары алдында, гаять матур, төзек тел кулланып, бик тирән мәгънәле чыгыш ясады. Саубуллаштык. Кочаклашып саубуллашканда: «Моннан соң Мөхәммәд өммәтеннән булганнарга калбемдә ярату һәм җылы хисләр яшәтәчәкмен», – диде.

Дәвамы бар

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

*Эшләнгән яхшылыкка рәхмәтле булып, яхшылык белән җавап кайтарырга кирәклекне аңлаудан туган хис (тәрҗ. иск.).

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Әдәбиятыбыз күгендә якты йолдыз булды

(Хәтер-хатирә)

Альберт Хәсәнов



Барлас Камалов

Тышкы кыяфәте, килеш-килбәте белән дә бик чибәр, шуның өстенә, искиткеч җор телле егет иде дустыбыз Барлас Камал. Хәер, аның белән дус булмаган кешене эзләп табып кара? Ярты Казан, ярты республика! Бөтенләй чит булган ватандашлар язмышына да беренче чиратта яхшылык кылып, бәлаләрдән йолып катнаша иде ул. Берәүне төрмәдән коткарып кала, икенче берәүне Өлкә комитеты шифаханәсенә дәваланырга сала, фатир алып бирә, улын институтка урнаштыра; фатирлыга өй җиһазлары, суыткыч алырга булыша... Хәтта бер белмәгән кешеләргә кылган игелекләрен дә эшләрен санап бетергесез. Бер дә арттырып сөйләвем түгел. Шундый, һәркем белән сөйләшә белгән, һәркайда сүзе үтә торган егет иде Барлас Хәмит улы Камалов. 1930 елның бик салкын 17 гыйнвар иртәсендә, Чистай шәһәрендә, укытучы гаиләсендә туа ул.

Мин аралаша башлаганда Барлас Хәмит улы киң эрудицияле, тирән фикерле, көндәлек тормышта зур урыннар биләгән танылган түрә, Республика комсомолының органы «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире, ВЛКСМ Өлкә комитеты бюросы әгъзасы, соңрак Татарстан радиосының баш редакторы булды.

Ә бит тормыш юлын җир сөреп, ат җигеп, басудан көлтәләр ташып башлаган егет бит ул. Хезмәт юлының беренче битен 1946-1948 нче елларда Буа колхоз-совхоз театрында актер булып башлап җибәрә Барлас. Бу сәләт аңарда тумыштан ук булганмы, әллә аңа театрда рольләр башкарганда йокканмы? Ул бик талантлы, дипломатка тиң, һич очына чыгалмастай буталчык мәсьәләләрне дә бик җиңел хәл итә иде.

Барлас белән дус булмаган адәмне эзләп кара, дигәннән, аңарда булган кешегә

ышану, аны барлык кимчелекләре белән кабул итү кебек олы хистән мин дә мәхрүмнәүмиз түгел идем. Моның белән шуны әйтмәкче булам. Без, Шамил абый Бикчи (Бикчурин) белән Казанга килеп номерларга урнашу белән Барлас Камал шундук бүлмәбезгә, «Ирекле иҗат йортына берәр атна торырга килә. Ул гына да түгел, сабакташым Роберт Әхмәтҗан, Габделхәй Сабит, югары категорияле, көмеш тембрлы диктор сабакташым Эльс Гаделев, Мәскәү радиосы һәм телевидениесенең Татарстан буенча үз хәбәрчесе, чыгышы белән Шөгер егете Ильяс Латыйпов килеп җитә. Ул чорларда чынлап торып безнең бүлмә язучы дусларыбызның «Ирекле иҗат йорты»на әверелә. Дусларымны бик сагынып, каләмдәшләремне олы хөрмәт белән искә алып язам бу юлларны. Бу егетләрнең туганнары, якыннары аларны, югалтып торганда, бик җиңел генә без белгән «офислар»дан килеп табалар иде.

Барлас Камалов – әдәбиятыбыз тарихында бик тирән, уникаль эз калдырган язучы. Аның кырык елларга сузылган иҗат юлында, төрле газета-журналларда һәм аерым китаплар, җыентыклар булып, йөздән артык хикәясе, утыздан артык повесте, «Өметең өзелмәсен» (1986), «Җир күчәре» (1990), «Үткән гомер – искән җил» (2001) исемле өч романы, күп санлы очерклары, публицистик язмалары, мәкаләләре һәм рецензияләре дөнья күрде. Әдипнең «Үр менгәндә» (1961), «Сыналыр чак» (1965), «Яшь имәннәр» (1966), «Яшьлек эзләре» (1968), «Күңел кыңгыраулары» (1969), «Урамнар киңәя» (1971), «Канатлы кырмыскалар» (1979) дигән, тормыш казаныннан ташып кайнаган җирләреннән чүмеч белән чумырып алган повестьларын үз итеп, чын күңелдән яратып укымый мөмкин түгел. Ә 1972 нче елда чыккан «Ялыкмаслар» романы белән аеруча зур дан казанды ул.

Барлас телне бик оста белеп, аның каймагын гына җыеп язды. Илле елдан артык актив тормыш юлында иптәшләренә, дусларына, хәтта бер белмәгән адәми затларга да яхшылык эшләгән олуг ихтирамга лаеклы затка рәхмәт йөзеннән, теге адәмнәр дә кулларына традицион «бер ярты» тотып килгәннәрдер. Ул чакларда ихтирам иткән, рәхмәтеңне җиткерергә теләгән кешегә тапшырырга нәрсә бар иде соң? Базарларда чәчәкләр дә сатмыйлар иде бит.

Ә Барлас андый зат түгел, «бер ярты» тотып килгәнне дә кире бормады, тәмен белеп салгалый да иде. Аннары бит үзебез дә бозыклар: «Коры рәхмәт, коры кашык кебек, авыз ерта», – диярга яратабыз. Алары түгел, мине Барлас дустыбызның, үзе сөйләгәннәренең раслыгына иман китереп, шулкадәр ышанып сөйләве таң калдыра. Башта уң кулының икенче бармагын, сәнгатьчә осталык белән, актерларча бизәп, борын алдына куя. Акыллы башын, нурлы йөзен дә һәйкәлгә, постаментка урнаштырырлык кыяфәткә кертә. Аңа гына хас, искиткеч йөз бу! Язучыбыз үз башыннан узган берәр хәлне сөйләргә әзерләнә. Без дә Шамил абый Бикчи белән, тынсыз калып, аны тыңларга әзер торабыз. Югыйсә, башка чакны безнең Бикчиебезне дә чаң да чаң килеп сүзгә кушылудан хәтта ГАИ инспекторы да тыя алмый...

«Кичә шулай, таң алдыннан, иртәнге дүртләр-бишләр тирәсе булдымы икән, – дип башлап китә Барлас остабыз. – ут капкандай телефон дөберди. Алай-болай дөбердәп, йокыдан уятмасын, дип, ике кат мендәр астына тыккан җирдән бит! Телефон трубкасын алырлык, «әйе, тыңлыйм», дип әйтерлек хәлдәме соң мин? Шушы минутта ук дүрткә ярылып китәрлек булып башым чатный. Кичә «Казан утлары» журналында, түбә такталарын узып түшәмнән тамчы тама башлаганчы, дуслар белән «Сарсаз кызы Сәрия» романын юдык. Бар мәшәкатьләрне ташлап торып, иң беренче реаль эш итеп башны төзәтергә кирәк миңа. Телефон кайгысымы миндә, диегез. Бар рухи көчемне йодрыкка туплап, телефон аппаратын мендәр астыннан алсам, шалтыратучы КПССның

Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев үзе икән. Таң беленмәс шалтыратмаса соң?! Белми торгандыр минем пахмельдән үләргә ятканны. Чынлап, шулкадәр иртәдән шалтыратмаса соң? Ул-бу, хәвеф-хәтәр булмагандыр, берәр җиргә ут капмагандыр, өченче бөтендөнья сугышы башланмагандыр ич!

– Әү, Фикрәт Әхмәтҗанович! Ни булды? – дим. Кәефсез, көч-хәл белән генә сөйләшүемне трубка аша ул да сизгәндер. Сизмәс сиңа!

– Үзеңдә нихәлләр? – ди. – Монда обком тәрәзәсеннән барысы да бик ачык күренә, бик актив эшлисез! Повесть артыннан повесть, роман артыннан роман чыгарасыз. Менә «Ялынмаслар» дигән романыгызны гаиләбез белән яратып укыдык. Шәп чыккан! Моңарчы, безнең күп язучыларыбыз кагылмый үткән, йә батырчылыклары җитмәгән пласт-катламнарны күтәргәнсез. Вы первопроходец, котлыйм! Молодец!

– Барлас Хәмитович, беләсезме нәрсә? Безгә замандашларыбыз турында сугышчан характерлы очерклар кирәк. Шалтыратуым, борчуым да шуның өчен иде. Берәр районга барып, тормышчан очерк язып кайтырга исәбегез юкмы соң?

– Нигә булмасын! – дип бүлдердем обком секретарен. – Кирәк чакта әдәбиятыбызның ул жанрын да җиңел буйсындырабыз.

Обком секретаре белән сөйләшәбез бит. Фикрәт Әхмәтҗанович үзе белән кыю, җөмләнең ахырына нокта куеп сөйләшкәнне ярата.

– Ул вакытта менә нәрсә, – ди Өлкә комитеты башлыгы. Әллә чынлап, әллә шаяртып: – Товарищ мой, верный! – дип тә әйтеп куйды. Аннары:

– Менә нәрсә! – дип тагын кабатлады. – Быел Буа районы игенчеләреннән мул уңыш көтәбез. Урак өсте башлану белән шунда барып төшеп, берәр ялкынлы очерк язмассызмы икән? Минем яңа гына алган кара «Волга»м Сезне өегездән килеп алыр. Елга портына да төшереп куяр. Анда аерым причалда Сезне махсус «Метеор» көтәр. Җиңелчә су корабын махсус җиһазландырырга күрсәтмә бирелгән. Ашау-эчү, әрмән коньягы мәсьәләләре хәл ителгән. Буада Сезне райкомның беренче секретаре каршы алыр, озатып йөрер. Сез бит үзегез дә Буа егете! Без дә райком секретаре белән бербәрсен аңлашып, нәтиҗәле эшләрләр, дип уйладык.

Мондый чакта нәрсә дисең? Синең белән Татарстан җөмһүриятендәге беренче дәрәҗәдәге зат, ихтирамга лаек кеше сөйләшә. Башым бишкә ярылырлык дәрәҗәдә авыртса да:

– Була ул, Фикрәт Әхмәтҗанович! – дидем. – Очерк була, Сез сорагач, җидегә ярылам. Очерк булачак!

Бер дигән очеркның буласына Барлас үзе генә түгел, шул минутта ук без дә ышандык.

– Икенче вакытны шулай диванда ятам. Баш төзәтелмәгән, мишәр әйтмешли, цатнап-цатнап авырта. Әллә миндә кан басымы шаярамы, дип тә шикләнеп куйдым. Юк, булмаска тиеш. Ә-ә! Кичә нәшриятта басылган «Дөмбер Денидал»ны (1999) юдык. Егетләр барысы да үтереп мактадылар. Белмим, ихлас күңелдән мактаганнардырмы? «Барлас, старшина, бу синең чираттагы иҗади уңышың!» – дип бәяләүләре әле дә хәтердә. Шулай мактап кабул иткәндә, әсәрне дуслар белән нигә юмаска?! Спрашиваете?

– Кирәк бит шундый бер мизгелдә янәдән телефон чылтырарга. Барып трубканы алмый булмады. Йомшак кына тембрлы телефонистка ханым эндәшә:

– Алло! – ди. – Халыкара телефон станциясеннән бу. Мине яхшы ишетәсезме? Каушап калмагыз, Барлас Хәмитович! Сезгә Һиндстаннан, аның башкаласы Делидан аларның премьерлары Индира ханым Ганди шалтыратырга җыена.

– Мин каршы түгел, – дип әйтергә генә сүз таптым. Каушамаган кая ул! Баш чатнаулары шунда ук юкка чыкты. Үземне момент кулга алдым. «Анда, Һиндстанда нәрсә булды икән тагын? – дим. – Берәр төрле террор-мазармы? Әллә Һинд океаны ярларыннан чыгып, берәр штатны су басканмы?» Индира ханымны яхшы беләм, бер дә юктан гына борчымас. Ул арада трубкада, күңелгә ятышлы, колоратур тембрлы тавыш ишетелде:

– Алло, дим? «Ялыкмаслар» романы, чын бестселлер авторы, татар халкының танылган язучысы Барлас әфәнде Камаловның квартирасымы бу? Менә зур шатлык, әллә автор мине үзе тыңлыймы? Дәһли каласыннан Һиндстанның премьер-министры Индира Ганди борчый Сезне. Ишетәсезме?

– Ишетәм, ишетәм, Индира ханым! Ишетмәгән кая! Минем нәкь өйдә чагымны туры китердегез. Бездә хәзер коеп яңгыр ява. Зонтик алырга дип урамнан кире борылып кергән идем. Үзегез ни хәлләрдә ятасыз? Бер дә тартынмый сөйләгез, Сезнең миңа нинди гозерегез, йомышыгыз төште? Коеп яуган яңгыр астында мин аларны яланаяк йөгереп үтәргә әзер.

– Беләсезме, хөрмәтле Барлас әфәнде? Ишетеп беләм һәм ул чыннан да шулай бугай, сезнең татар халкы бездә үскән һинд чәен бик ярата икән.

– Ярата гынамы соң, хөрмәтле Индира ханым, – дип бүлдердем премьер-министрны, – Һиндстан чәе дигәндә, прәме тәкать тота алмыйлар. Авыл җирләрендә карт-коры әбиләр чәегезнең четвертушка кабын ике дистә эре йомыркага сатып алалар. Ә шәһәр җирендә, башкалабыз Казанда бөтенләй дефицит. Көндезен шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Мин үз гаиләмә дә Һиндстан чәен ара-тирә генә КПССның Өлкә комитеты буфетыннан эләктергәлим. Анда да по блату! Әбиләребез исә һәр кап чәегезнең бик кадерен белеп, һәр чәйнеккә тузан бөртеге хәтле, тик тәм чыгару өчен генә салалар. Бездә шул чәйгә каен яфрагы, кара карлыган, кура җиләге, чия яфраклары, мәтрүшкә үләне салып эчү хутта. Ул чәегезне нигә дип шулхәтле санап кына җибәрәсездер? Бездә бер-береңнең хәлен белеп, берочтан җәелеп кич утырып кайтырга кунакка барганда күчтәнәчкә бер кап һинд чәе тыгып бару – иң зур этикет, иң зур дәрәҗә!

– Идел-Кама бассейнында яшәгән бик тырыш-уңган, үз сүзендә торучы татар халкы белән безнең алыш-биреш – үзара сәүдә мөнәсәбәтләребез күп гасырлар элек башланган, – дип дәвам итте Индира ханым. – Рус сәяхәтчесе һәм сәүдәгәре Афанасий Никитинның «Өч диңгез артына сәяхәт» («Хождение за три моря») дигән әсәрен укыганыгыз бардыр. Никитин әфәнде безнең якларны аркылыга-буйга кичкән. Иң кызыгы шул: рус сәяхәтчесеннән ике йөз еллар алда, Һиндстанга Россиянең Ырынбур

штаты сәүдәгәре Хаялин килеп чыккан. Дәһли, Бомбей калаларында төпләнеп, чәй һәм төрле аштәмләткечләр белән сәүдә итә торган берничә кибет ачкан. Рәсәйгә чәй белән йөкләр төягән кәрваннар озаткан. Безнең ике ил арасындагы сәүдә дә, партнерлык мөнәсәбәтләре дә әнә шул чорлардан башлана бит.

– Менә ни өчен дә мин Сезгә мөрәҗәгать иттем, Барлас әфәнде, – дип дәвам итте Һиндстан премьеры. – Быел безнең берничә штатта чәй уңышын бик мулдан җыярга ышандыралар. Үземнең каналлар аша ныклап белештем: Сез, Барлас Хәмитович, бик көчле журналист, публицист икәнсез. Чәй җыю сезоны башлану белән безгә килеп чыгып, уттан кызу репортаж ясап китмәссезме икән? Мин Сезне ихлас күңелдән чакырам. Сезне алырга Дәһлидән махсус самолет киләчәк. Казан аэропорты реактив моторлы самолетларны әлегә кабул итми икән. Ул чакта Мәскәүнең Шереметьево аэропортынамы инде?! Анда ничек килә алырсыз бит. Мин бу турыда губернаторыгыз Ф.А.Табеевка шалтыратырмын. Аны бик яхшы беләм, Мәскәүдә күп тапкырлар очрашкан бар. Барлас әфәнде, Сезне буш итмәм. Чәй җыю сезоны башлану белән, чәй яфракларының иң тәмле, иң хуш ислеләрен генә, бер самолетны дыңгычлап тутырып, Татарстанга озатыр идек. Аннары, Барлас Хәмитович, «Ялыкмаслар» романыгызны да, тиз көндә һинд һәм бенгал телләренә тәрҗемә кылдырып, бастырып чыгарырга ышандырам.

Башка чакларны мондый тәкъдимнәр булганда, мин, маңгаемны уып: «Уйланырга кирәк», – дип җавап бирә идем. Ә Индира ханым тәкъдименә:

– Чәй сезоны башлану белән җибәрегез очкычыгызны! Сездәй чибәр ханымның тәкъдименнән баш тарту безнең тагар егетләрен гомумән бизәми. Момент килеп җитәчәкмен. Барам Дәһлигә. Берүк яхшы номер алып куегыз. Кондиционерлы бүлмә булсын. Мин артык коры һавалы климатны авыр кичерәм.

– Шулай олылап чакырып торганда нигә бармаска?!

Татарстаныбызны нигә хуш исле «Һиндстан чәе»нә күммәскә? «Ялыкмаслар» романын каян кулына төшерде икән? Мәскәүгә килгәчтер инде. Аны да һинд, бенгал телләрендә чыгарам дип тора. Әллә мин, Барлас Камал анда барып бер дигән репортажлар бирә алмаммы, җүләр! Барласның кулыннан килмәгән эше юк аның!

Бу нәрсәләрне Барлас дустыбыз безнең ике кешелек номерда, үзе кебек хыялый коллегалары арасында, Казан байларыча киерелеп, диванда кырын яткан килеш сөйли. Киеренке пафос белән. Без сыныбыз катып тыңлыйбыз аны. Шамил абый хәтта бераз көнләшеп, телен дә шартлата:

– Без дә язучы булып йөрибез инде, энем, – дип миңа ым кага. – Менә бит арабызда кемнәр бар! Аларга ничек мач туры килеп тора. Аларны әллә кайларда беләләр, укыйлар. Кунакка чакыралар.... Иң югары дәрәҗәдә!

Барлас сөйләгәннәрнең күбесе аның искитмәле фантазиясе икәнен икебез дә белә югыйсә. Ә шулай да Барлас Дәһлигә чәй җыярга барачак, репортажлар да язачак!

– Ә менә без чакырсалар да отказ бирер идек. Булмый бездән, дияр идек, – дип дәвам итә Бикчи. – Меланхоликларча кулын селтәп куя. Ә мин аның сүзен:

– Шуңа күрә безне Дәһлигә чакырган кеше дә юк, – дип куәтлим.

Бер караганда, меланхолиягә бирелергә сәбәп тә юк, Шамилнең сые һәрвакыт кулында:

– Булмаса, шуның өчен тотыйк берәрне, – дип, Барласка тулы фужер суза.

Үзеннән беркайчан туйдырмый торган, искитмәле фантазияле, һәрчак киң күңелле, талантлы язучы иде Барлас Камалов. Күңелендә һәрчак изгелек кылу, яхшылык эшләү булды. Игелек кылу белән беррәттән, әсәрләрне дә хисапсыз күп язды. Аларны онытмаска, вакыт-вакыт янәдән бастырып чыгарырга кирәктер. Барлас Камаловның бай иҗади мирасы бүген дә кирәкле, аңа еш кына мөрәҗәгать итәбез. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Әбрар Кәримуллин хатлары

Тәлгат* дус!

Сезнең 1 августта язган хатыгызны алдым, анда Сез «Саба районының 60 еллыгын билгеләп үтәргә җыенабыз», шул уңай белән үзегез котлау сүзегезне яисә шул вакыйга белән бәйле берәр язма җибәрүне сорагансыз.

Сүз Сабаны административ үзәк итеп билгеләү турында барамы? Мин бу турыда беренче мәртәбә ишетәм. Элек ул як ничек аталган, кемгә караган? Волостьмы, кантонмы булган? Минем Чәбья-Чүрчи авылы элек Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостена караган, 20 нче еллар башында Сатыш волостенда булган кебек. Күрәсез, мин бу 60 еллык уңае белән аңа бәйле берни белмим. Димәк, яза да алмыйм.

Котлау, дигәч, нәрсә әйтергә дә белмим диярлек. Бу 60 ел Саба районы кешеләренә нәрсә алып килде? Гомумән, сталинизм заманы, аннан брежневщина елларына караган бу 60 ел эчендә мактанырлык нәрсә булды икән? Нинди котлау сүзләре язарга соң?

Бердәнбер шулай дип язарга мөмкиндер:

Якташларымны Саба районы оештырылуга 60 ел тулу уңае белән чын күңелдән котлыйм. Киләчәктә районның икътисади, милли мәдәният ягыннан Татарстан Республикасының (ә ул, һичшиксез, тулы хокуклы мөстәкыйль дәүләт булыр) мактаулы төбәге булуын телим.

Сталинчылар, үз ялагайларыбыз җимергән мәчетләр торгызылыр, халыкка әдәп,

---

*Тәлгат – Тәлгат Нәҗмиев.

әхлак нурлары сибелер, корытылган чишмә, инеш-елгаларыбызның сулары мулланыр, сукаланган яшел болыннарыбызда, шайтан таягы урынына, мул үлән-чәчәкләр гөрләп үсә башлар, җимерелгән күперләребез яңадан эшләнер, кыр-басуларны машиналар таптап, юллар салып йөрүгә чик куелыр, урман-кырларыбызны талау урынына, аларны акыллы файдалана башларбыз. Мәктәпләребез дә элеккечә Тукай телендә сөйләшер, балаларыбыз Альберт та, Роберт та түгел, яңадан Рөстәм вә Рәшитләр, ә Фаялаша, Маялаша, Раялаша башлаган кызларыбыз ата-аналары биргән изге исемнәренең кадерен белә башларлар иде, диясе килә киләчәктә.

Кайчан Өчнарат (Три сосны), Ике Басу Арташ (Два поля Арташ), Байлар Сабасы «Богатые Сабы»лар булып яшәүдән туктап, үзләренең чын исемнәре белән йөртелә башлар, кадерле сабалыларга бу турыда да уйларга ярыйдыр юбилей көннәрендә.

Бу 60 ел эчендә «матур тормыш»та яшәгән Саба районының күпме әзмәвер кебек батыр егетләре, туган йортларын ташлап, ерак Шпицберген атавы, Донбасс, Кузбасс шахталарына кузгалмады да, күпчелеге Карелия, Себер якларына урман кисүгә юл алды, китте, югалды, кире кайтмады. 60 еллыкны үткәргәндә менә боларны да онытмыйк. Саба якларының мең еллардан артык гыйбрәтле тарихында аның Болгар дәүләте чорында ук даны зур төбәк икәнен дә онытмыйк. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар...» китабында гына да Саба якларында даны Ерак Көнчыгыш илләренә яхшы билгеле булган галимнәр искә алынган. Безнең төбәктә даны киң таралган күпме мәдрәсәләр эшләп торган, ә Сатыш мәдрәсәсенә нинди генә шәрык мөселман илләреннән укырга шәкертләр килмәгән?!.

Безнең төбәк кешеләре эшкә дә, һөнәргә дә, гыйлемгә дә оста булганнар... Оренбург якларына барып бистәләр салганнар, Урта Азия, Кытай, Һиндстан, гарәпләр белән сәүдә тотканнар, чит илләргә йөргәннәр, Истанбул, Каһирә уку йортларында белем алучылар да шактый булган. (Минем үземнең бабам Гата Ихсанов Истанбул университетында гыйлем алган, Мөхетдин Корбангалиев белән Ике Басу Арташ, Чәбья-Чүрчи, Язлы Арташ авылларында земство хисабына татар дөньяви мәктәпләре оештыруда актив катнашкан.) Саба ягыннан чыккан кешеләр арасында Россиянең чит илләрдәге илчесе булып йөргән затлар да билгеле...

Болар әле өстә яткан фактлар гына. Саба районына 60 ел тулуны билгеләп үткәндә аның тарихын өйрәнүне дә киләчәктә эш планнарына кертү кирәктер. Аерым авыл тарихын чагылдырган авыл музейлары да бар, ә безнең хәтта аерым бинада район музеебыз да юк бит. Монысын да онытмыйк шушы юбилей көннәрендә.

Туган авыл, туган як – һәркем өчен иң изге, иң кадерле, иң газиз хис. Меңьеллык тарихы булган Саба төбәгенең киләчәге, аның милли теле, милли моңы тагын да меңләгән гасырлар дәвам итүен кайсыбыз гына теләми, ә бу нәрсә бүгенге эшебез, гамәлебез белән дә нык бәйләнгән.

Менә шундый сүзләр әйтер идем. Инде, ярамый, дип тапсагыз, басмагыз, артык шомартуны теләмәс идем. Үзегезгә карагыз, Сез сорагач, язарга булдым. 60 еллыкка Яхъя Абдуллинны, мине дә чакырырбыз, дигәнсез. Яхъя өйдә түгел, Казан тирәсендә ялда. Ул кайтып йөри. Мин риза. Шәт ул да кайтырга ризадыр, дип беләм.

«Шәһри Казан» газетасының пробный саны чыгачак бүген-иртәгә, игътибар итегез, анда минем бер әйбер басыла, шулай ук «Комсомолец Татарии»да да – икесе дә, миңа калса, бик проблемлы һәм нык кыю нәрсәләр.

Сәламнәр белән, тиздән очрашуга хәтле.

PS. Саба РК КПССта 11 кеше генә калды, дип язасыз. Озакламый ул үзе дә калырмы икән әле? Демократия белән берпартиялелек бергә яши алмый бит...

7 август, 1990 ел

Тәлгат туган!

«Крутушка»дан язган хатыгызны алдым. Бик тиз килеп җиткән. Парлап, хатыныгыз белән анда ялда икәнсез. Сезгә ялыгыз шифалы, күңелле булуын телим. «Крутушка»да бер тапкыр булганым бар. Матур урын. Кыш башы булгач, җәй көннәре кебек үк түгелдер. Хәер, кышның да үзенә күрә матурлыклары күп.

Минекен дә алгансыз икән. Мин аны ашыгыбрак язган булып чыктым. Минем «Язмыш, язмыш...» дигән кулъязманы Татарстан китап нәшрияты 1995 ел планына керткән. Президентыбыз киләсе елга Ватан сугышы тәмамлануга 50 ел тулу уңае белән барлык фронтовик язучыларның нәшриятка тапшырган әсәрләрен басарга акча бүлеп бирәчәген белдерде. Нәшрият директоры, шәт инде, Президент кушканны эшләр, дип уйлыйм.

Шуңа күрә Фәрит әфәнде Гыйльмиевкә мөрәҗәгать итеп торуның кирәге бетте, дип уйлыйм. Сайлаулар уңае белән аның хакында бер-ике сүз әйтү турында. Мин риза, ләкин бит мин, аның хакында нәрсә булса да әйтү өчен, ниндидер конкрет фактларга таянырга тиеш. Әгәр Сез миңа шундый фактларны хәбәр итсәгез, эш миннән тормас. «Болванка» язып җибәрсәгез, бигрәк тә яхшы булыр иде.

Соңгы вакытта сәламәтлек шәптән түгел. Менә ике атна авырып алдым. Минем квартирам бик салкын, суык көннәрдә идәндә су ката. Алыштыруда ярдәм итүләрен сорап караган идем, зур түрәләребезнең берсе үтенечемне отфутболит кына итте. Мин тормышта практичный кеше түгел.

Милләт, милләт, дип янып йөрүләремнең нәтиҗәсе күренмәгәч, матбугатта аны яклап язуларның кирәге, файдасы күренми, дип, бу эштән читләшә башладым. Бу соңгы 3-4 ел гел публицистика белән генә диярлек шөгыльләндем. Күпме фәнни хезмәтләр язылмыйча калды. Аларны язып та татарны уятып булмый, булмады, ахры. Хәзер күңелнең иң төшенке вакыты. Шартнамә милләтне элекке коллык хәленә кайтарды.

Бәлки истәлекләр язарга керешермен. Минем тормыш гаять авыр һәм гаять катлаулы булды, әле дә шулай. Әйтер сүзләр өелеп тора. Бу өлкәдә бер тәҗрибә дә ясап караган булдым. Октябрьдә мин дә ялда, Бәкер санаторийсында булдым. Шунда Табиев белән «дуслыгыбыз» турында бер истәлек язып, бер журналга тапшырдым. Кешеләргә ошаса, истәлекләр язарга күчәрмен бәлки. Анда, әлбәттә, Сабага да урын булыр, чөнки ул минем тормышымда шактый зур роль уйнады.

Алдан кычкырган күкенең башы авырта, диләр. Шулай булып чыкмаса ярар иде. Сәламәтлек кирәк.

Тәлгат туган! Игътибарыгыз, җылы, деловой хатыгыз өчен зур рәхмәт. Сезне, гаиләгезне (хатыныгызның исемен дә белмим бит) Яңа 1995 ел белән котлыйм, барыгызга да саулык-сәламәтлек, бик кирәкле эшегездә, Сабаны Республика күләмендә пропагандалауда да шулай тырышып эшләвегезне теләп калам.

«Саба таңнары» газетасы коллективын да чын күңелдән Яңа 1995 ел белән тәбрик итәм, бәхетле булыгыз, саулык-сәламәтлек сезгә, барыгызга да!

Олы ихтирам белән, районлашыгыз.

Декабрь, 1994 ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

АБДУЛЛА АЛИШ (1908-1944)



Абдулла Алиш. 1930 нчы еллар

Совет чоры татар балалар әдәбиятының күренекле вәкиле Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1941 елның июль аенда армиягә алынып, фронтка озатыла һәм солдат-радист сыйфатында Орел өлкәсендә барган оборона сугышларында катнаша. Шул елның 12 октябрендә Брянск шәһәре тирәсендәге канлы бәрелешләр вакытында чолганышта калып, алманнарга әсир төшә. 1941 елның кышын Литвадагы хәрби әсирләр лагеренда тотканнан соң, 1942 елның язында

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

фашистлар аны Чехословакиядәге Сандау шәһәренә күчерәләр. Ахырда ул Польшадагы Седльце шәһәренә, аннан Берлин янындагы Вустрауга килеп эләгә. Монда Алиш Алмания гаскәри көчләре составында татар әсирләреннән төзелгән «Идел-Урал легионы»нда антифашистик яшерен оешма әгъзасы Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, аларга кушылып, тиз арада яшерен оешманың иң актив әгъзаларының берсенә әверелә. Бераздан ул татар легионерлары өчен Берлинда рәсми чыгарыла торган «Идел-Урал» газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша һәм, шундагы урыныннан файдаланып, типография ысулы белән антифашистик листовкалар, өндәмәләр бастыруны җайга сала. «Идел-Урал легионы»ның алман офицерлары җитәкчелегендә беларус, украин, поляк, француз партизаннарына каршы сугышка җибәрелә торган гаскәри берәмлекләрен баш күтәрергә, партизаннар ягына чыгарга өндәгән бу листовкалар татар легионерлары арасында Абдулла Алиш аша, турыдан-туры аның катнашында таратыла. Җәлилчеләр оешмасының антифашистик актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә, татар әсирләреннән төзелгән батальоннарның яртысына якыны партизаннар ягына күчеп, партизан отрядлары белән бергә фашист гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша, ә легионерларның калган гаскәри берәмлекләрен алман командованиесе таратырга яисә чит илдәге төбәкләргә күчерергә мәҗбүр була.

Шагыйрь Абдулла Алиш. Җәлилчеләргә куелган барельефның бер өлеше

1943 елның августында яшерен оешманың эше ачылып, Абдулла Алиш һәм башка җәлилчеләр кулга алына, төрмәләргә ябыла. Яшерен оешманың үзәген тәшкил иткән унбер җәлилчене әүвәл Берлиндагы Моабит төрмәсендә тоталар, аннары Дрезден шәһәрендәге Плетцензее төрмәсенә күчерәләр. 1944 елның февралендә шунда Алишка һәм аның көрәштәшләренә суд була. Фашист хәрби суды аларны «дәүләткә каршы җимерү эше» алып баруда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә.

Шул елның 25 августында хөкем карары гамәлгә ашырылып, әсирлектә фашизмга каршы тиңсез көрәш алып барган унбер татар каһарманының (Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Әхәт Атнашев, Абдулла Баттал, Галләнур Бохараев, Фуад Булатов, Муса Җәлил, Фуад Сәйфелмөлеков, Әхмәт Симаев, Зиннәт Хәсәнов, Гариф Шабаев) гомере өзелә.

Рузәл Мөхәммәтша *әзерләде* ■

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009.

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Батыр йөрәкле Зәйнәп

Ильяс Салихҗан

Атасына охшап, Зәйнәп шулай кыюлыгы һәм ихтыяр көче белән алдырган. Ни генә димә, барыбер ирләрдән калышмый ул. Сабан туе кызулыгын гына искә төшерик. Халыкка бәйрәм, ә хокук саклаучыларга тыгыз эш көне ул. Олы Шырдан Сабан туе турында: «Шөкер, тыныч узды быел җыен!» – дип сөйлиләр икән, димәк, бу анда Зәйнәп кайткан дигән сүз.

Сугыштан соң үткәрелә башлаган халык бәйрәмнәрендә Шырдан егетләре Ходяшныкылар белән «көч сынашмый» калмаган. Ә менә Садыйк кызы күренсә – мәйданда тәртип: кызмача ир-ат күмәкләшеп тәпәләшә башласа да милиционер хатын, бернидән курыкмыйча төркемне ерып кереп, сугышны туктата алган. Кыдрач әтәчләрне аера белгән ул. Югыйсә, илленче еллар – күндәм холыклар заманы түгел. Егетләрнең күбесе сугыш дәһшәтендә йөреп, җиңеп кайткан. Менә шул батырларны да тыңлата алган ул...

МИН – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ГАДИ БЕР КЫЗЫ!

1

Зәйнәп Садыйкованың даны киң тарала. Шырдан-Норлат тирәсендә генә түгел, бүтән якта да яңгырый аның исеме. Тәртип тотуда, җинаятьләр ачуда фидакарь тырышлык куйган милиция капитанының сатылмавы-йомшамавы үзенекен итә. Ирләрчә чалбар киеп, атка атланып йөргән бу яшь хатынны Норлат белән чиктәш районнарда да таный башлыйлар. Хәтта күрше чуаш җирендә дә «Сәйнәп» исеме тәртип урнаштыру камчысыдай яңгырый.

Әйтергә кирәк, халык ышанычын казану – ул чактагы җитәкче даирәләрнең эшендә ирешә алган биеклекнең күренеп торган үлчәнеше. Норлат райкомы коммунист Садыйкованың кеше арасындагы абруена игътибар итми калмый. Даны күтәрелә барган хатынны үзләренчә файдаланырга карар итәләр.

Сугыш вакытында һәм аннан соңгы елларда тиңсез күп салымнар һәм заемнар белән таланган авыллар ахыр чиккә җитеп фәкыйрьләнә. Авыл хуҗалыгын күтәрү максатында шәһәрләрдән 30 мең кешене колхозларга җибәрергә кирәк дигән күрсәтмә туа югарыда. Чынбарлыкны дөрес аңлап ясалган адым бу, чөнки авылның кеше ресурсы да саеккан була. Очы-кырые күренмәгән авыр хезмәттән изаланган халыкның күмәк хуҗалыкны күтәрергә теләп януы да сүрелгән учакны хәтерләтә инде.

Атаклы милиционер Садыйкованы менә шул «30 меңчеләр хәрәкәте» дигән кузгалыш 1955 елда «Вахитов» исемендәге колхозга китерә. «Вахитов»ка – игенчелек,

---
Ахыры. Башы журналның 8 нче (2018) санында.

яшелчә үстерү һәм терлекчелек белән көн күрүче Күгеш, Айдар һәм Әрә авыллары керә. Моңа хәтле алар һәрберсе аерым хуҗалык булып, җирне аерым сөргән булалар. Район җитәкчелеге аларны берләштереп, зур колхоз ясый һәм рәис итеп, Зәйнәпне куя. Дөрес сайлана рәис. Батыр йөрәкле хатын бу эштә дә, бик күп гайрәтле ирләрне артта калдырып, бөтен Татарстанга таныла.

Бернинди махсус белем алмыйча милициядән икмәк үстерү эшенә күчүе гаҗәпләндерәдер, мөгаен. «Партия кая җибәрсә – мин шунда барырга тиеш!» дигән кагыйдә хәзерге заманда сәер яңгырый, әлбәттә.

Каһәр төшкән авыр еллар! Бөтен кузгалыш та кул көче белән тернәкләнгәнгә күрә, халыкны эшкә куа алу – җитәкченең булдыклылыгы итеп саналган. Абруең булса гына кешене тыңлата аласың. Дүрт йөзгә якын колхозчы катнашкан гомум эшне бүтәнчә ничек оештырасың ди?! Ә рәис Садыйкова нидән тотынган соң?

2

Халкы хәзер «Красный Восток»та хезмәт куйган, уңганлыгы белән аерылып торган бу авылларда Зәйнәп Садыйкованы яхшы беләләр. Аның белән бергә эшләгән чаклары бүгенгедәй хәтерендә картларның. Миңа шул чорда партком секретаре булган Камил абзый белән очрашып, Зәйнәп Садыйкова турындагы истәлекләрен язып алу насыйп булган иде: «Зәйнәпне, читтән килгән кеше кебек, өр-яңадан абруй яулау бурычы басмады. Бездә ул шәхесне яхшы беләләр иде инде. Икенчедән, дип әйтсәк, 1955 нче елларда халык та бүтән – эшкә карусыз иде. Аннары авыл кешесе рәиснең холкын тиз чамалады: Зәйнәп – тотынган эшенең төбенә төшмичә тукталмый, бернидән дә курыкмый торган көчле ихтыярлы җитәкче... Инде холкы, дигәч, шуны да әйтим – мин үзем дә гаҗәпләнә идем моңа – ул кешене аңлый белә, аның сәләтен таный иде.

Рәис һәр тармакны бригадаларга үзе бүлде һәм эшне оештыручы итеп, колхозчыны тыңлата алганны үзе табып куйды. Тракторчылар бригадасына, мәсәлән, Әкрәм абыйны бүтән авылдан чакырып китерде. Ул техниканың маен күп «ашаган» һәм ирләр арасында тиз танылды. Яшелчә үстерүчеләргә бригадир итеп Рәйхана апаны билгеләп тә отты. Уңышлы эшләп, бу апабыз хәтта Ленин ордены белән бүләкләнде! Бухгалтерына хәтле белгечнең рәтлесен сайлый белде. Шуңа күрәдер, дип уйлыйм, яңа рәиснең эше бик тиз үргә менде. Аңа кадәрле 6-7 центнер белән канәгатьләнсәк, ул килгәч, гектарыннан 12-14 центнер уңыш җыеп ала башладык. Күпләп сыер, сарык асрадык – анда да күтәрелеш. Яшелчәне әйтәсе дә юк инде. Шуның белән җиһанда танылды да инде Зәйнәп. Ни генә чәчмәдек: кәбестә, суган, чөгендер, кишер, помидор, кыяр, бәрәңге...

Хрущев заманы иде бит: нәрсә генә үстермәдек тә, нәрсә генә үрчетмәдек!.. Зур уңыш алабыз, дип, ярыша-ярыша эшләдек тә. Әрә елгасы буендагы тугайларда, язгы ташулар сугарган җирләрдә чәчәләр иде яшелчәне. Өч авылның да хатын-кызлары иртә таңнан елга буенда, билгеле. Бар эш тә кулга төшә. Җәй буе буадан көянтә белән су ташу, уңыш җыю һәм аны машиналарга төяп озату... Ир кеше нишләр иде икән шулхәтле чыр-чу белән?! Ә менә Зәйнәп хезмәтне оештырды. Тыңлата белә иде ул аларны. Үзе дә үрнәккә куярдай чапты инде: кояш белән бергә басуда иде рәис...»

3

...Язгы төн иртәнгә авыша. Авылда әле тынлык. Бары кошлар сайравы гына яңгырый.

Идарәдә ут яна. Анда Зәйнәп эш кәгазьләренә чумган. Аларга мәгънәле тәртип кертеп имзасын салгач, ул яшелчә басуына төшәчәк. Бүген кишер, чөгендер кебек яшелчәләрне чәчәргә кирәк. Җир әзер анысы. Тик менә бер звеноның җитәрлек тырышмавы гына эчне пошырып тора. Кичен шыпырт кына җиткерделәр аңа. Әлеге дә баягы Әрә звеносының таркаулыгы!

Эшне оештырганда һаман шул әрәнекеләр киреләнер. Элек-электән бай яшәгән бу авыл бүтәннәрдән нык аерыла. Икешәр катлы йортлар, берничә мәчет булган анда. Әйе, әрәлеләр үз көченә таянып, үзе өчен тырышып эшләргә өйрәнгән. Билгеле инде, андый кеше колхозда гомум оҗмах өчен тир түгәргә ашкынып тормый. Хатын-кыз җитәкче менә шул каршылыкны да җиңә.

Урлашулар бигрәк тә җенен чыгара рәиснең. Хәтта фермадан бүрек кадәр печән кыстырып кайтучыны да тотканчы артыннан куа. Югыйсә, андыйлар бу адымга өйдәге терлегенә ашатырга азык булмаганга, чарасызлыктан бара, чөнки элек өч авыл халкы печән чапкан болынлык сөрелеп, ул җирләргә яшелчә утыртыла башлый. Мәхкәмәгә җиткермәсә дә, кызган шәпкә кул уйнатмыйча да калдырмый рәис.

Төнлә дә уяу, төнлә дә сакта булды, дип сөйлиләр авыл картлары Зәйнәп турында. Яшелчә кырларын әйтәсе дә юк инде, зираттагы печәнне чабып китмәсеннәр өчен шунда куна торган булган ул. «Ничек курыкмыйсың син, Зәйнәп?» – дип сораган танышларына: «Мине әти язып биргән дога саклый!» – ди торган булган.

Әйе, үткәндәге милиция хезмәте гадәткә күчкән аның. Һәр җирдә дә тәртип тоту катылыгы нәкъ шундагыча. Җор телле Әрә халкының: «Безнең калхуз миллионер, персидәтел – милиционер!..» – дип такмаклавы юктан түгел, билгеле.

Гаҗәп, хуҗалык рәисе үзенә йорт та салдырмаган, Рәйхана апаларда фатирда торган. Үз тормышын кайгырта белмәгәч, бүтәннәргә дә яшәргә бирмәгәндер әле, дип уйлау дөреслеккә туры килми. Җитәкченең халыкка йорт салуда булышлык күрсәтүен һәркем искә ала. Садыйкова турындагы хатирәләрнең иң җылысыдыр бусы.

Йорт төзү, каралты-кура коруга биредәгеләр аеруча зур игътибар биргән. Хикмәт шунда: Күгеш, Айдар һәм Әрә авыллары янында бура бурардай агачлар үскән урман юк, шуңа күрә өй салучы кеше Иделгә йөрергә мәҗбүр булган. Судан җыеп юнәткәннәр буралык агачларны. Җәй көне, әлбәттә.

Колхозда эшнең иң кызган чагы бит, югыйсә. Садыйкова кешене бормаган, машина белән булышкан. Заманына күрә зур ярдәм бу.

– Болар бөтенесе диярлек шул юл белән күтәрелде, – дип искә алалар вахитовлылар тыштан искерсә дә ипле торган өйләргә күрсәтеп. – Хәзер үзебез дә аптырыйбыз: кичкә хәтле колхозда эшләп, төнгә Идел буена бүрәнә җыярга чабабыз. Су сеңдергән агачларны өстерәве ай-яй хәлне ала!.. Шуннан кайткач, иртүк тагын эшкә – ничек түзгәнбез без?!

– Ару-талу шулхәтле нык еккан – иртән торганда күзләр ачылмый, аларны тырнак белән тырнап ача идек!

...Халыкның маңгай тире гүя биредәге җирләргә уңдырыш тамчысы булып тама.

«Вахитов» республика буенча алдынгылар рәтенә күтәрелә. Яшелчә басуларында гектарыннан 212 центнер – помидор, 284 ц – кишер, 268 ц – чөгендер, 719 ц – кәбестә, 8,3 ц яшел борчак җыеп рекорд куя колхоз.

Саннардамыни хикмәт! Болай көчәнү – үзе батырлык! Моны уйлаучы булдымы икән? Кем өчен үстергәннәр икән соң алар бу кадәр яшелчәне? Нигә кирәк иде шулхәтле интегүләр?! Хәер, артык сорау бирү – ул еллар гадәте түгел.

4

Имәннең юан башы гади колхозчы җилкәсенә генә төшкән, дисәк, хакыйкатькә беркадәр хилафлык китерер идек. Эшне уңышка ирешерлек итеп оештыра белү дә таләп ителә бит әле. Кара эшнең үзәгенә җигелеп, булсын дип чапкан Зәйнәп шушы социалистик ярыш дигән ашкынуда танылa да. 1960 елда аңа – Ленин ордены, 1966 елда тагын бер Ленин ордены һәм Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

Хезмәт батыры – ул еллардагы гаять киң илнең иң мактаулы, иң дәрәҗәле исеме.

Зәйнәп Садыйкованы КПСС өлкә комитетында Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелү белән котлау. 1966 ел

Шулай итеп, Садыйк кызы 45 яшендә дан-шөһрәт биеклекләренең иң югарысын яулый.

Зәйнәп Садыйкова исеме бөтен илгә тарала. Газета-журнал битләрендә – аның фоторәсеме, радиода – аның тавышы... Хезмәт батыры, әлбәттә, СССР Югары Советы депутаты да. Шунда чыгыш ясаганда ул сүзен:

– Мин – татар халкының гади бер кызы! – дип башлый торган булган.

Киңрәк мәйданга чыккач, Садыйкова танылган кешеләр, җитәкче даирәләр белән еш аралаша. Казан, Мәскәү калалары түрәләре килеп олылыйлар үзен. Хәтта Үзәк Комитет әгъзасы Михаил Сусловның да биредә кунак булуын хәтерлиләр.

Кызык, рәиснең танылуы колхозга да файда китерә. Беренче чиратта, хуҗалык кирәк-яраклары, төрле запчасть кебек әйберләрне табуы җиңеләя. Шундый бер хәлне әле дә шаккатып сөйлиләр авылда.

Яшелчә кырына су үткәргәндә торба җитеп бетми. Зәйнәп Казанга телефоннан шылтырата, әмма анда да табылмый кирәклесе. Шулай да аңа торба эзләп бүтән өлкәләргә чыгып китәргә туры килми инде хәзер. Рәиснең теләген үтәргә ашыгып, Казан базасы торбаларны Мәскәүдән самолет белән үк кайтарта.

Танылган җитәкченең үзсүзлелеге дә көчәя. Бу турыда Оркыя апасының малае Җәүдәт абыйдан сорагач, ул:

– Бары тик аныңча булырга тиеш, каршы килеп кара!.. – диде һәм бер вакыйганы бәян итте: – Бермәлне Казанга алып барырга туры килде миңа аны. Үзенең «Волга»сы ватылган икән, бик ашыгыч, дип, минем йөк машинасына утырды. Вакыт аз, дигәч, бернигә карамыйча кудым. Ярар, шәһәргә килеп җиттек шулай җилләтеп. «Кремльгә илт – өлгермим киңәшмәгә!» – ди бу хәзер. Анда хәтле кереп булмый бит инде минем машинада. Аңлатам, үтенәм – тыңламый инде. Тәки үзенекен иттерде! Ленин урамы буйлап Кремльгә килеп җиттек бортовой белән! Ул министрлыгына чапты, ә минем машинаны милиция егетләре урап алды... Менә шундый иде аның холкы. Әгәр ул ак төсне кара дисә – аныңча була иде!

Данлы рәисләренең мондый холкы эштә кыенлыклар тудыруын да истә тотучылар бар. Ул инде күбрәк таләп итү белән генә чикләнә башлый. Тәкъдим, бәхәсләр белән

эшне оештыру онытылып бара. Ул әйткән – закон. Сүзен аяк астына салдыртмас өчен көч кулланудан тартынмавы да мәгълүм. Кәнсәгә чакыртылган ирләр дә аның кабинетына үзләре генә керергә куркып торганнар, дип сөйлиләр.

Хатын-кызның болай буйсындырырга тырышуы кемгә ошар икән? Ирләрне инде бигрәк тә әрләндерә мондый хикмәт. Халыкта җыела барган каршылык хисе тәмам тулып, 1967 елдагы сайлауда тышка бәреп чыга. Колхозчылар сайлау җыелышында бүтән кешене рәис итеп куярга теләк белдерәләр. Районнан килгән җитәкчеләрнең Садыйкованы калдыруны яклап чыгыш ясаулары да ярдәм итми. Ахыр чиктә тегеләр клуб сәхнәсенең арткы ишегеннән чыгып качарга мәҗбүр булалар...

«Вахитов»тан чыккач, ул Свияжск бистәсендә урнашкан мөгезле эре терлек симертүче «Идел буе» совхозын җитәкли башлый. Анда да тәртип урнаштыра Зәйнәп. Совхоз ике ел эчендә республикадагы шундый утыз алты хуҗалык арасындагы ярышта җиңеп чыга. Элек хуҗалыктан качып киткән руслар да: «Зәйнәп Садыйковна, зинһар, мине эшкә ал!» – дип, артыннан калмый ялынып йөри башлыйлар...

1970 елның 1 июнендә Зәйнәп ялга чыга. Инфаркт мәҗбүр итә. Әле илле яшь тулып кына килә үзенә... Нинди көчле ихтыярлы хатынга да бу тормыш җиңел бирелмәгән, күрәсең.

5

Зәйнәп Садыйкованың фоторәсемнәре күп сакланган. Бигрәк тә мактаулы елларыныкы.

Шуларны караганда, бер хәл аптырашта калдыра: җиңүченең шат елмайган чагы кайда соң? Барысында да әлеге дә баягы җитди корылык... Бөтен ил күккә чөйгәндә ничек сөенмичә түзгән ул? Нәрсә дә булса борчыганмы, эш-мәшәкать басканмы аны? Тормышының бу ягы белән дә кызыксындым, билгеле.

Безнең герой – хатын-кыз. Беренче ире сугышта ятып калган. Икенчесе белән бер ай гына яшәгән, дип сөйлиләр... Табигый инде, сорау туа: кайда соң аның яры, кем булган ул? Колхозга күчкәндә 34 яшь кенә тулган таза-матур хатынның йөрәген кем иркәләгән икән соң?

«Вахитов»та бергә хезмәт иткән иптәшләренең җаваплары бертөрле яңгырады:

– Ә без аңа хатын-кыз дип карамадык та. Ничектер, анда хатын-кыз йомшаклыгы сизелми иде. Ул – рәис, ул – җитәкче, ул – алда...

Зәйнәп Садыйкованың (сулда) «Идел буе» совхозы директоры булып эшләгән чагы. 1967 ел

Кичләрен пошанмый ничек ялгызы гына үткәргән, кышкы озын төннәрне, мәсәлән? Авылда эшләр кимегән чак бит ул.

Аракы эчеп юанмадымы икән, дигән шик тә кузгала, чөнки хәмер капкалавын күпләр хәтерли. Яшь чагында Зәйнәп кул астында эшләгән, аннары Норлатта яшәгән Хәмит абый мондый хәлне сөйләгән иде:

– Эчкәләгәнен беләм. Мавыгып китмәде, мавыкса, эшне алып бара алмас иде бит ул! Шулай да бер вакыйганы ишеткәнем бар. Кич клубка чыккач була ул. Кино башланганчы, егетләр, йөзәр грамм җибәрергә, дип, клуб артына җыела торган булганнар. Берсендә Зәйнәп килеп чыга шунда. Аптырап калган егетләр, чарасызданмы, аңа да сузалар стаканны. «Миңа ярым-йорты гына салма, тутырып бир!» – ди ул. Һәм тулы стаканны алып гөпелдәтә дә, бүреген иснәп, китеп бара. Клуб артындагылар телсез кала...

Рәисне иртә таңнан караңгы төнгә чаклы машинада йөрткән шоферы, әлбәттә, күбрәк белергә тиеш. Күгештә яшәүче Рәшит абый йөрткән аны «ГАЗ»икта.

– Беркеме юк иде, йөргән ирен белмим, – дип җавап бирде ул минем соравыма. – Ә җәмәгате булган! Хәтерлим. Бер җәй көнне читтән ир кеше эзләп килде аны. Таза, чибәр үзе. Икенче көнне Зәйнәп апа әйтә: «Рәшит, теге адәмне станцага төшереп куй!» – ди. Юлда сөйләшеп бардык. Аерылган ире булып чыкты юлдашым. Гали исемле үзе. Ай ярым чамасы гына бергә торган булганнар... Хәзер кушыласызмы соң, дип сораган идем, ул: «Нинди кушылу! Аңлашырга да теләмәде – шүшиләдә печән арасында төн кундым!» – диде.

– Рәшит абый, елаганы булдымы Зәйнәп апаның? – дип сорадым мин тагын.

– Елады, еламаган кая! Әллә ничә. Бигрәк тә беренче елларны Казанга йөргәндә. Теге кирәк, бу кирәк, дип, министрлыкка кергәч кире борып чыгаралар да үзен... Берсендә, тракторга ниндидер запчасть сорап баргач, атылып кире чыкты – күзләреннән яшь тама. «Кая, чыгар стаканыңны, Рәшит!» – ди, үзе биштәреннән шешә тартып алды. Ярты стакан аракыны гөпелдәтте дә, яшьләрен сыпырып, яңадан кереп китте. Бер сәгать торгандырмы, елмаеп килеп чыкты министрлыктан: «Кәгазьгә кул куйдылар!» – ди.

Күз яше дә – эше бармаганнан.

6

Танылган рәис Зәйнәп Садыйкова эз калдырган җирләрдә йөргәндә, мин, башлыча, ирләргә мөрәҗәгать итәргә тырыштым. Моның сере гади үзе. Хатын-кыз җитәкче, гадәттә, башка хатыннарга аеруча таләпчән була. Шуңа күрә шигем бар иде: иртә таңнан кичкә кадәр гаиләсеннән аерып колхоз өчен бил бөктергән башлыкны искә алганда хатыннар гаделлек саклармы икән соң? Әмма ялгышкан булып чыктым.

Хатын-кызның сердәше дә була бит әле. Героебызның шәхси тормышын белү теләге мине Зәйнәпнең яшьтәшләре белән дә танышырга мәҗбүр итте. Һәм уйламаганда оттым.

Күгеш, Айдар һәм Әрә авылларында яшәүче, алтмышынчы елларда рекорд куя-куя яшелчә үстергән колхозчылар хәзер инде әби яшендә, әлбәттә. Ни гаҗәп, таләпчән рәисләрен искә төшереп сөйләгәндә, берсенең дә йөзе караңгыланмады. Хәтта аның кырыслык күрсәткән очракларын да көлә-көлә хәтерләп бәян иттеләр. Аларның ачу сакламауларына аптырап торганда кинәт кенә миңа дөнья ачылды: бәхетле кешеләргә генә хас сыйфат бит бу!

Әйе, боларның бәхете тулы. Ипле өйләрдә җитеш көн күреп, бишәр-алтышар бала һәм оныклар үстереп рәхәт гомер итүче бу әбиләр, һичшиксез, бәхет дигән тормыш мәгънәсенә ирешә алганнар. Ә гаиләсе дә, сөеп юанырга баласы да булмаган Садыйкова...

Бәхет! Менә нәрсә җитмәгән икән безнең каһарман кызыбыз Зәйнәпкә! Орден-медальләр тагып фотога төшкән хатынга менә нинди елмаюлар йокмаган! Хезмәт даны гына чын бәхетне алыштыра алмаган шул. Нидәндер шулчак аның шигъри юллары искә килә. Егерме яшьлек Зәйнәпнең, 1941 елда ирегеннән мәхрүм ителгәч, зинданнан язган бер хатында шундый дүртьюллык бар:

Бәхет, гөлкәй, ник син шулай
Бер генә дә чәчкә атмадың?
Эзләмим мин хәзер, бәхет, сине,
Санламадың мине, килмәдең!

Әйтерсең, язмышын алдан күреп язган...

АЛМА АПА

1

Зәйнәпне һәрчак көткән өй булган ул. Туган авылы Олы Шырданда аның гаиләсе. Әтисе Садыйк абзый, әнисе Нәфисә абыстай һәм апасы Оркыя яшәгән нигез – Зәйнәпкә дә гомер буе төп йорт булып кала бирә. Андагылар өчен дә ул – әле эшкә генә чыгып киткән кадерле гаилә әгъзасы...

Үзе дә бик еш кайтып йөргән Норлатта, «Вахитов»та эшләгән чакларында. Әгәр читләтеп узарга туры килсә, апасына хатлар язып, хәлен белгертеп торган. Аның хатларын Оркыя апасының олы улы – Әхмәтовлар гаиләсе кыйммәтле ядкарь итеп саклый. Алар арасында 1953 елның 17 марты белән билгеләнгәне бар. Зәйнәп анда «Рамай» җырының сүзләрен һәм мондый җөмләләр язган: «... Бу көйне минем апам да яратырга тиеш. Чөнки ул мин яраткан нәрсәне ярата. Ә без аның белән туганнар да һәм якын дуслар да. Мин үзем дә аны бик яратам. Күрешүгә, бу җырны аңа тапшырам. Ә үзем ятлармын дип уйлыйм».

Апасы да, йөрәк сердәше дә булган шул Оркыя Зәйнәпкә. Менә кемгә күңелен ачкан ул! Авылга кайткач, кичләрен бергә утырырга яраталар апалы-сеңелле Садыйковалар. Чәйләр эчеп, озаклап гәпләшә алар. Шунда көлешәләр дә, елашалар да үзләре...

Кызганыч, Оркыя апа да мәрхүмә инде.

Зәйнәп Садыйкова (Алма апа). 1960 нчы еллар

2

Зәйнәп Садыйковага, 1970 елда ялга чыккач, Яшел Үзән каласында фатир бирәләр. Йөрәген инфаркт дигән мәкерле чир китереп кыскач, туганнары аны ялгыз калдырмаска тырышалар. Аеруча Гомәр белән Җәүдәт еш керәләр янына. Оркыя апасының малайларына Алма апа ул. Атаклы апасының соңгы елларын Җәүдәт яхшы хәтерли. Күп

сөйләштек без Җәүдәт абый белән Алма апасы турында. Берсендә сорыйсы иттем:

– Тормыш юлында аңа байтак каршылыкларны сындырырга туры килә, вакыт-вакыт корал тотып та... Ничек итеп бер дә пуля эләкмәде икән үзенә?

– Беләм ни саклаганын. Әти догасы коткарды, дип сөйли иде ул. Бабай аңа бөти язып биргән. Алма апа шуны күлмәк кесәсендә йөртә торган булган. Ә кышын бүрек кашагына яшергән. Бабайның догасына мин ышанам. Үзегез карагыз: бермәлне алар өендә янгын чыга. Ут көчәя. Яна-яна түшәмне тишеп, чормага ук үтә. Анда исә йомычка җәелгән – ялкын инде шуларны ялмый башлый. Менә-менә дөрләп китәр кебек. Ә киресенчә килеп чыга: ут, китаплар салынган сандык янына җитә дә, сүнә. Изге китаплар тылсымы бу! Мин шулай уйлыйм.

– Туктагыз әле, Җәүдәт абый! Доганың тәэсире булсын өчен, аңа ышанырга кирәктер бит. Ә Зәйнәп апа – коммунист!..

– Ышана иде, кешегә генә әйтмәде.

Чыннан да, Зәйнәп Садыйкова өчен хакыйкать шушы өйдә башлана. Димәк, күңелендә аның изге догага инану, эшендә – идеологиягә... Һәм әле ничек эшләгән бит! Хәер, ул гынамы? Партия оешмаларында хезмәт иткән замандашлары, олыгайгач, мәчет юлына кайттылар бит. Ул буынның фаҗигасе дә шундадыр, бәлки.

Зәйнәп Садыйкованың ялга чыккач ничек яшәвен сорадым.

– Тыныч тормышта нәрсә эшләдеме? – дип башлады сүзен Җәүдәт абый. – Ул бит бөтен көчкә чапкан мәлдә кинәт туктап калган ат кебек булды. Тик тора алмас иде. Эче пошудан интекте. Бераздан үзенә шөгыль тапты-табуын. Төрле үтенеч-гозер белән йөрүчеләргә ярдәм итә башлады Алма апа. Фатирда кеше өзелмәде. Кеше өчен тырышып, Казандагы түрәләргә үк барып җитә иде. Тыңлата белә иде ул аларны. Авылга кайтса да җыелалар иде аның янына, хәтта гариза сызып бирергә дә үтенеп киләләр иде.

Кызганыч ки, дошманнары да очрады. Милициядә эшләгән чагында эләктергән җинаятьче 1973 елда Алмаападан үч алды. Кыш көне, караңгы төшкәч, өчәүләп сагалап торганнар аны. Артыннан килеп, башына кастет белән сукканнар. Егылгач, кыйнаганнар өчәүләп, кабахәтләр. Кеше күреп кенә коткарып калалар апаны. Тунын, бүреген, бер орденын урлап качалар хөрәсәннәр!

Алма апабыз хастаханәдә дә тәүлектән артык һушсыз ятты. Шөкер, терелеп чыкты, гарипләнмәде алай. Кыерсытучыларны тиз таптылар, җинаятьләре өчен өчәр ел бирделәр инде. Шул кыйналудан соң Алма апа, ничектер, бигрәк тә күңелсезләнде. Аракыны еш каба башлады. Шуннан китте дә.

Берсендә, ул Свияжскида «откормычный совхозы»нда эшләгән чагында яшәгән фатирга керә. Хәмер дә кыстырган була, билгеле. Шешәне кухняда идәнгә куя. Шул почмакта ук кырмыска спирты салынган шешә дә тора. Менә бит, язмышың булгач, нишлисең! Аракы урынына ялгыш теге спиртны эләктереп, карамыйча гына эчеп җибәрә дә, ашказаны юлын һәм бөтен ашказанын яндыра. Бу хәл җитмеш җиденче елның май аенда булды. Хастаханәгә йөрдем. Табиблар, тикшергәч, операциягә алынмадылар. Әйе, Аллага тапшырылды. Чөнки йөрәге беткән, инфарктган соң көчкә генә тибә. Түзмәячәк, диделәр. Дәвалаган булдылар инде... 21 июньдә кич белән миңа: «Яшәп булмас, ахры, улым!» – дип әйтеп калды. Иртән килсәм, ул җан биргән иде. Озак басып тордым янында. Менә шулай Алма апасыз калдык. Авылда зиратта әби белән бабай янында җирләдек. Халык күп җыелды. Күгештән дә килделәр.

...Җир тетрәтеп эшләп дан яулаган Зәйнәп Садыйк кызы Садыйкованың гомере 1977 елның 22 июнендә өзелә. Ул елны аңа бары 56 яшь тула. ■

Сания

ШАГЫЙРЬНЕҢ СОҢГЫ МУЗАСЫ

Сәмига Сәүбанова

Халык арасында иҗат кешеләренең мәхәббәте турында гайбәтләр күп йөри. Бу шагыйрьләргә дә кагыла.

Мондый гайбәтләр Муса Җәлилне дә читләтеп үтмәгән. Дөресен әйтергә кирәк, алар буш җирлектә тумаган. Шигырьләренең музасын ул җирдән эзләгән, тапкан һәм, әлбәттә, гүзәллекне яраткан.

Аны белгән өлкән әдипләр бервакытны өлкә комитетына бик җитди сөйләшүгә барган чагында күңеленә ошаган бер хатын-кыз очрагач, юлын үзгәртеп, киңәшмәгә бармый калганын сөйләгәннәр иде. Ә бервакытны андый сөйләшүгә, аягына туфли кияргә онытып, өйдә кия торган башмак белән дә килгән.

Буе бәләкәй һәм тышкы кыяфәте белән артык күзгә чалынып тормавына карамастан, хатын-кызлар арасында Мусаның абруе зур булган. Аңа еш гашыйк булганнар, табынганнар. Шагыйрь үзе дә аларның мәхәббәтенә битараф булмаган – аларга багышлап күпме шигырьләр язган. Ул шигырьләрне аның гыйшкын раслаучы дәлил итеп кабул иткәннәр, горурланганнар.

Муса матурлыкны яраткан, яшьлектән, сафлыктан бик тиз әсәрләнгән. Илһамчыларның һәрберсенә үзенчә сокланган. Шагыйрь мәхәббәте матдилектән өстен. Бу – илаһи хис.

Кулыннан килсә, бөтен дөньяны кочарга әзер булган шагыйрьнең тормышта да никахлы өч хатыны, өчесеннән үз фамилиясен биргән законлы берәр баласы – Альберт, Люция, Чулпан дөньяга килгән.

Муса Җәлилнең кызы Люция белән без 1974 елның октябрь аенда бер-ике көн аерымлыгы белән генә ГИДУВта бәби таптык, бер палатада яттык. Нәкъ менә шул вакытта Василий Шукшин вафат булды. Моны ишеткәч, Люциядә истерика башланды. Алар бергә укыган һәм бик дус булганнар. Шуның кайгысыннан аның күкрәкләре шеште, баласын имезә алмады, температурасы 40 градуска хәтле күтәрелде, соңыннан күкрәкләрен яргалап бетерделәр.

Люциягә ул чагында 38 яшь, безнең яшь аермасы 10 ел иде.

Без аның кызына бергәләп исем сайладык. Люциянең башта Аэлита дигән исем кушасы килгән иде, соңыннан Лилианага тукталды. Баланың әтисе әрмән милләтеннән, рәссам булгач, шул исемгә өстенлек бирде.

Ул аның икенче ире иде. Беренче ире – татар егете, диплом темасы итеп урам бандитлары турында фильм төшерер өчен, алар компаниясендә үз кеше булып, аларның рухи дөньясын аңларга тырышып йөрүен белгәч, ачулары килеп, аның гомерен өзгән булганнар.

Соңыннан бу фильмны телевизордан мин дә караган идем. Үзе төшереп, баш рольне дә үзе башкарган ул егетнең йөзе гаҗәеп якты, иманлы иде... Исеме генә хәтердә калмаган.

Бәлки ул татар кино сәнгатен югары күтәргән шәхескә әверелер иде. Исән булса әгәр...

Озак еллар буена туган илендә хыянәтче исемен күтәреп йөргән шагыйрьнең тиңсез батырлыгы хакындагы хәбәр урау юллар аша бельгияле Андре Тиммерманстан килеп ирешкәч, Татарстан Язучылар берлегенә утыздан артык хатын-кыздан үзләрен Муса Җәлилнең беренче мәхәббәте дип уйлауларын хәбәр иткән хатлар алынуын ул чагында анда эшләүче шагыйрь Илдар Юзеев сөйләгән иде.

Кызганыч, алар турында мәгълүматлар җыю турында беркемнең дә башына килмәгән. Югыйсә, шагыйрь иҗатын өйрәнүчеләргә тормышының безгә билгеле булмаган мизгелләре турында күп мәгълүмат бирерләр иде.

Ул чагында: «Без шагыйрьнең бердәнбер мәхәббәте Әминә дип беләбез», – дигән хатларның берсен мин дә машинкада баскалап биргән идем.

Ә менә шагыйрьнең соңгы музасы – шыксыз декабрь салкыннарында сугыш дип аталган тәмугка зурлап озаткан һәм салкын окопларда ятканда да җанын җылыткан, аның белән чолганышка калганчы хатлар алышкан кыз, Казанда яшәп, озын гомер кичерде.

Мин аның белән озак еллар дуслашып, аралашып яшәдем. Телефоннан шылтыратып, бер-беребезнең хәлләрен көн саен диярлек белешеп тордык. Бервакытны бер айга якын телефон «дәшмәде», мин шылтыратканга да җавап бирмәде. Ни уйларга да белми аптырап беткәч, ниһаять, аның тавышын ишеттем.

– Ишекне ачып керүем белән сиңа шылтыратам. Югалткансыңдыр, хастаханәдә ятып чыктым. Сиңа хәбәр итә алмадым, гафу ит. Әле генә кайттым. Аякларымны дәвалап чыктым менә. Син беләсеңме, миндә гангрена була язды бит...

Бу хәбәрдән йөрәгем өзелеп төшкәндәй булды. Ә Сания апаның күңеле бер дә төшкәнгә охшамаган иде.

– Чир минем башка җитми торсын әле, куркып качты, – дип дәвам итте ул. – Мин бу аягым белән үзен әллә ничә тапкыр тибеп очырам, тиз генә килмәслек иттем әле аны.

Күңелемә җылы керде. Болай булгач, куркырлык берни юк. Сания апа үз аяклары белән йөриячәк. Чөнки аны берничә тапкыр Газраил сагалаганын беләм. Берсендә, унтугыз яшьлек чагында Әгерҗе комсомол райкомының беренче секретаре булып эшләгәндә, ат кузгалып китеп, арба тәртәсе күзенә килеп бәрелә. Терелүен терелә, әмма шуннан бирле аның бер күзе күрми торган булып кала. Икенчесендә, ангинадан йөрәгенә ревматизм бәрә, аннан да исән кала. Өченче тапкырында, Свердловск шәһәренә партия укуларына баргач, машина бәрдереп, ике аягын да сындыра. Бозлы суга да төшә, биек ярдан тирән суга да мәтәлә. Андый очракларны саный китсәң, исәбенә чыгарлык түгел. Соңгы елларда да, үзе әйтмешли, Аллаһы Тәгалә сынавын дәвам итә. Инде беттем, дигәндә генә үзенең ярдәм кулын сузып, бәладән тартып ала.

70 яшендә машина бәрдергәч, арттан килгән мотоцикл астында калып, аягы чәрдәкләнгәч, ел буе хастаханәдән чыга алмыйча, урын өстендә дә ятты ул. Аягына басты тагын. Гангрена куркынычы шуның галәмәте иде.

Аллаһы Тәгалә, дигәннән, Сания апа аңа артык ышанып яшәмәде. Үзе гомер буе партия системасында эшләгәч, диннәрне халыкны буйсындырып тоту чарасы дип исәпли торган иде. Бервакытта да бисмилла әйтеп, ашагач, амин тотканын хәтерләмим. Ә үзе кешеләргә бик ярдәмчел, кече күңелле, гомеренең соңгы көннәренә кадәр партияне сагынып, аны юкка чыгарган кешеләрне сүгеп яшәде. Ул Күктән беркайчан да кул кушырып ярдәм көтмәде, үз көченә генә таянды.

Әллә Сания апаның тормышка теше-тырнагы белән ябышуы Газраилне кире борылырга мәҗбүр иттеме икән?

Аны юатмакчы булып, үземнең дә кәефем юклыктан зарланган чакларымда:

– И-и, сиңамы соң әле алай дияргә, – ди торган иде. – Ул чагында миңа нишләргә кала инде?

– Мин дә яшь түгел инде, оныклар үстерәм, – дим.

– Менә мин гомер буена сәламәтлеккә туймадым. 19 яшемдә сыңар күз белән калгач, 2 нче төркем инвалидлык бирделәр, аннан соң йөрәгемә ревматизм булгач, 1 нче төркем инвалидлык алдым. Бу диагнозларны әти-әниләрдән дә яшердем. Кая монда эшләү турында уйларга? Ә гаилә корып, бала табу турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Хезмәттәшләрнең дә белгәне – белде, белмәгәне – юк. Алар гайбәт сөйләп йөри торган кешеләр түгел иде. Ә Казанга килеп эшли башлагач, берәүгә дә әйтмәдем. Кияүгә чыгып, Гаяз абыең белән 37 ел гомер иттем, бер күзем күрмәгәнне ул да белмәде. Күптән түгел күземә катарактадан операция ясатырга туры килгәч кенә оныгым Алеша бу турыда беренче тапкыр белде. Аңардан яшереп булмады – ул үзе табиб, операциягә җитәкләп ул алып килде. Хәзер инде син беләсең... Яшерүнең кирәге дә юк, тугызынчы дистәне ваклыйм бит мин...

Сания апа белән ни гомер аралаштым. Инде бөтен тормышын белеп бетердем дисәм, тагын бер ягы белән ачыла. Һәрвакыт шулай булды ул.

Гомумән, бик кызык кеше иде Сания апа. Берәр эш белән мавыкса, төбенә төшеп эшләде. Яратса, үлеп яратты. Гомеренең соңгы елларында радиода диктор булып эшләүче Тәлгать Хәмәтшинның тавышына гашыйк булды.

– Аның сөйләве җаныма тынычлык бирә, – ди иде. – Яшьлегемә алып китә ул. Күз алдыма озын буйлы, куе бөдрә чәчле, ут күзле булып килеп баса. Валлаһи, мин аңа үлеп гашыйк. Минем яшьтә яраталармыни, дип көләрсең инде. Ә мин яратмыйча яши алмыйм.

– Ул дикторның тәбәнәк кенә буйлы, пеләш башлы булуы, калын күзлек киюе дә бар бит, – дим.

– Юк, андый тавышлы кешеләр гадәттә нәкъ мин күз алдына китергәнчә булалар, – ди ул.

Кайчан карама, Рафаэль Ильясовның җырлавын тыңлар, аның тавышы язылган пластинкаларын бик кадерләп кенә тотар. Тик ни хикмәттер, без үлеп яраткан Илһам Шакировның җырлавына әз генә дә исе китмәде. Әгәр аның кулында булса, ул аңа бер мактаулы исем дә бирдермәгән булыр иде.

Хезмәте шундый булганга, Сания апага бик күп танылган кешеләр белән аралашырга туры килгән. Гомере буена партия оешмаларында, җитәкче урыннарда эшләгән, әдипләр, сәнгать әһелләре, галимнәр белән аралашып яшәгән. Белоруссия һәм Украина компартияләренең элеккеге беренче секретарьлары П.М.Машеров, В.В.Щербицкий белән яхшы танышлар, Азәрбайҗан президенты Г.Алиев белән дуслар булган. Г.Алиев Казанга эш белән килгәч, Сания ханымны эзләтеп таптырган.

Сания ханым бала чагында берничә ел Казанда Мәхмүдә апасында яшәгән. Ул чагында аларга татарның зыялы сәнгать кешеләре җыела торган булган, үзе белән бер яшьтәге Рөстәм Яхин да керергә яраткан. «Аларның пианинода уйнап җырлаганнарын тыңлый-тыңлый икебез дә йоклап киткәч, әнисе аны күтәреп алып чыгып китә торган иде, – дип искә ала иде ул. – Соңыннан әнисе мине улына килен итәсе дә килеп йөргән иде. Тик без гомер буе гади дуслар гына булып калдык. Рөстәмнең бүтән бер генә йөргән кызын да яратмады, шуңа соң гына өйләнде. «Хатыныңны яратасыңмы?» – дип сорагач: «Әнигә ярый инде», – дип кенә җавап биргән иде», – диде ул бервакыт бу турыда искә алганда.

Бертуганнар (сулдан уңга): Мәхмүдә, аның кызы Иншәр, Сания, Шамил, Саҗидә, Хәят. 1930 ел. Әгерҗе шәһәре

Муса Җәлил. 1941 ел

Сания апа сүзләреннән Рөстәм Яхинның яраткан кызының бүтән шәһәрдә гаилә корып яшәвен, Казанга килгәч, үзләрендә бергә җыелып очрашуларын да белдем.

Тормышның ачысын да, төчесен дә күргән бу көчле ихтыярлы, нык хатын Муса Җәлил белән танышлыгы турында сөйләгәндә, күзенә яшьләр тыгыла иде.

– Нинди кеше харап булды бит. Мин аның акланачагына ышандым. Аңа хыянәтче исеме тагылгач, миңа яхшылык теләптер инде, түрәләрнең берсе ул хатларны юк итәргә киңәш бирде. Тик мин тыңламадым. Муса Җәлил белән танышлыгымны бик зур бәхет санадым һәм беркайчан да бу фикеремнән кайтмадым.

Алар инде дәһшәтле сугыш барган чагында – 1941 елның декабрь аенда очрашалар. Минзәлә щәһәрендә политработниклар курсларын тәмамлаганнан соң, Муса Җәлил, Казан поездына эләгү өчен, ат белән Әгерҗе шәһәренә килә. Ул анда Ясәви Мәҗитов дигән кешеләрдә биш көн тора. Муса милләте белән чиркәс, әмма татар кызына өйләнеп, Әгерҗедә төпләнеп калган Ясәви абыйның кызы Мәхмүдә белән Казанда рабфакта укыган һәм хәзер Минзәләдә яшәп яткан дуслары, кунып чыгарсың, дип, шагыйрьгә этиләренең адресын бирә.

– Адресны онытсаң, аптырап калма. Чиркәсләр кайда яши, дисәң, сиңа кая барырга икәнен шунда ук әйтерләр, – дип өсти алар.

Әгерҗедә шагыйрьне кадер-хөрмәт белән каршы алалар.

Ясәви абзыйның төпчек кызы Сания үзләре белән яши икән. Бик чибәр, мөлаем, өлгер, тәвәккәл, заман белән бергә атлаучы туташ. Инде сугыш башлангач, медицина институтында укуын ташлап, Әгерҗегә кайткан, комсомол райкомының беренче секретаре вазыйфасын башкара.

...Ул көнне урамда бик салкын була. Гомумән, кырык беренче ел зәмһәрир салкыннары белән фашист илбасарларының бөтен планнарын бозган ел була. Өшегән битен бияләе белән уа-уа, кыз өенә төшке ашка йөгерә.

Ә өйдә әнисе аңа, серле генә иттереп, үзләрендә кунак булуын әйтә. Кызның моңа исе дә китми. Аңа хәтле дә Әгерҗегә йомышы төшеп килгән туган-тумача, дус-иш аларга еш туктала бит. Өй иркен, урын җитәрлек. Кыз, кухня ягында тамак ялгап алгач, зур якка чыга. Анда чәчен кыска иттереп алдырган, хәрби киемнән кечкенәрәк гәүдәле бер кеше басып тора. Аякларында күн итек. «Аяклары туңгандыр, мескенкәйнең», – дип аны жәлләп куя Сания һәм гадәт буенча:

– Исәнмесез! – дип эндәшә.

Ул да, елмаеп:

– Сәламне алдык, – дип, Мәхмүдә апасыннан да сәлам тапшыра.

– Шушымыни инде Мәхмүдәнең яраткан сеңелесе? – ди. – Апаң, бик булган сеңелем бар, дип, теленнән дә төшерми үзеңне.

Үзен мактауга күнекмәгән Сания әнисе янына чыга. Әнисе аның сугышка китәсен,

аңарчы үзләрендә куначагын әйтә. Сания яңадан чыкканда теге кеше китап шкафыннан «Алтынчәч» дигән китапны алып:

– Бу әсәр Сезгә ошыймы? – дип сорый.

Сания аны укырга өлгермәгән була. Ул моны яшереп тормый һәм үзенең шигырьләргә битараф булуын да өстәп куя.

Теге хәрби исә:

– Казанга барып операсын да тыңламадыгызмы? – дип төпченүен дәвам итә.

– Әйе, ул операны бик мактыйлар. Казанга баргач, карарга кирәк булыр, – ди дә кыз, эшенә ашыга.

Эштән кичке сәгать тугызларда гына кайта ул. Әти-әнисе, Саҗидә апасы өстәл кырыена тезелешеп утырганнар, теге хәрби кеше өстәл башында утыра, дәфтәрләрдән шигырьләр укый. Арада Мәхмүдә апасының кызы Иншәргә, улы Азатка багышланган шигырьләр дә була. Сания дә алар янына утыра. Аның күзе һәр шигырь астына язылган «Муса Җәлил» дигән сүзләргә төшә. «Алтынчәч» дигән китапта да шундый исем булганлыгы исенә төшә.

Шунда гына үзләре белән бер өстәл артында утырып, аларга шигырь укыган кешенең Муса Җәлил үзе булырга тиешлеге башына барып җитә. «Оятка калдым, – дип уйлый ул. – Район кадәр районның яшьләр башлыгы шигырьләр дә укымый икән, надан, дисә, нәрсә эшләрсең?!»

Шуннан соң кыз, тиз генә киенеп, укытучы Гөлсем апасына йөгерә. Ул аны тынычландыра һәм шагыйрьне сыйларга май, ярма, он, чүпрә биреп, өенә кайтарып җибәрә. Әнисе ул ризыкларга бик сөенә, чөнки сугыш вакыты бит, ризыкка кытлык чор. Сания, Саҗидә апасын чакырып, аңа да хәлне аңлата.

Бу төнне Мәҗитовларда шигырь бәйрәме озак дәвам итә. Ләкин Сания алар янына залга чыгарга кыенсына.

Икенче көнне кыз иртүк торып, тиз генә ашап-эчеп, эшкә китәргә уйлый.

Муса Җәлил дә уянган була. Минзәләдә чакта ук Мәхмүдә аңа сөйләгән үтә дә чая, үткен, бик булган сеңлесе менә нинди икән! Шагыйрьдә аның белән ныклап танышу теләге уяна һәм ул аны озата чыга. Юлда яшьләр тормышы, аның эше турында сораша. Кыз аның сорауларына җавап бирә һәм аңардан кайчан һәм нинди поезд белән китәсен сорый. Муса: «Өч көн торырга туры килер, эшелонның җыелып беткәнен көтәм», – ди.

Сания шагыйрьне истә калырлык итеп озату оештырырга була. Эшкә баргач, бу турыда комсомол активы һәм тимер юл бүлеге җитәкчеләре, политбүлек башлыгы, хәрби комиссар белән дә сөйләшә. Кич белән эштән кайтып керүенә шагыйрь абыйсы районның комсомол тормышы турында сорашуын дәвам иттерә, яшьләр тормышын өйрәнәсе килүен әйтә. Авылларга ничек йөрүе белән кызыксына. Сания ат бирүләрен, аның бик әкрен йөрүен, кайбер авылларда үзенең атны да узып чабуын сөйли. 30-40 чакрым ераклыктагы авылларга чыгып китүе турында әйткәндә, Муса абыйсы аңа соклануын яшерми. Ул киләчәктә Саниянең комсомол тормышы хакында хатлар язып торуын үтенә.

Шагыйрьнең, өч көн торырга туры килер, дигәне биш көнгә сузыла.

Бишенче көнне кичке сәгать бишләрдә Ясәви Мәҗитовның өендә шагыйрьне озату мәҗлесенә җыелалар. Сания шагыйрьнең махсус вагонда китәсен әйтә. Мәҗлес узгач, станциягә барсалар, тимер юлда бик күп халык җыелган була: райком кешеләре, комсомол яшьләр, эшчеләр һәм фронтка китәсе солдатлар. Поезд иртән үк килгән, солдатлар вагоннарга урнашканнар икән инде. Хәрби комиссар команда бирүгә, алар вагоннардан чыгалар. Тынлы оркестр озату маршын уйнап җибәрә. Митингны Сания ача, аннан бер-бер артлы бүтәннәр сөйли. Алар шагыйрьгә һәм сугышка китүче

солдатларга «Җиңеп кайтыгыз, бер генә фашистны да аяк атлатмагыз!» дигән теләк теліләр.

Муса үзен бу хәтле зурлап озатуларын һич көтмәгән була. Ул бу хәлгә бик сөенә, хәтта күзләрендә яшьләр күренә һәм рәхмәтен белдерә.

Вагонга утырганда ул Саниянең кулын кыса һәм җибәрмичә тора.

– Тиздән күрешергә насыйп булсын иде, – ди.

Алар Муса Җәлил хәбәрсез югалганга хәтле хат алышалар. Кыз шагыйрьнең район комсомоллары тормышы турындагы сорауларына бәйнә-бәйнә җаваплар язып тора. Соңгы хатында Муса үзләренең кыр почтасы адресы үзгәрәчәген, әлегә хат язмый торырга кирәклеген хәбәр итә. Шуннан хатлар өзелә.

Муса Җәлилнең атнасына ике тапкыр язган хатларының күбесе Саниянең Әгерҗедән Казанга күчеп килүе, ә йортларының соңыннан бүтән кешегә сатылуы сәбәпле югала. Ә исән калган кайберләрен Муса Җәлилне хыянәтче итеп санаган елларда да юкка чыгармый, саклый. Бер әдәбият әһеле, кызга яхшылык теләп, аларны юкка чыгарырга киңәш итә. Әмма Сания шагыйрьнең хыянәтче булуына ышанмый. Мусаның каһарманлыгы ачылгач, ул үзендәге хатларны, музейга куяр өчен, язучы Гази Кашшафка тапшыра. Ә менә бер хат гомер буе үзендә сакланды.

«Кадерле Сания!

Фронтта язган шигырьләремне җибәрүемне сорагансың. Алар миндә күп. Сугыш тынган араларда иҗат эше белән шөгыльләнәм. Казанда һәм Мәскәүдә рус һәм татар газеталарында, аерым китап булып сугыш елларында язган шигырьләрем басылып ята. Мин редакторлардан хат алдым, бер китабым инде производствога җибәрелгән. Фронтта язган бөтен шигырьләремне җибәрергә мөмкинлегем дә, вакытым да юк (алар кырыкка якын), бу хат белән җиде шигыремне сиңа истәлеккә җибәрәм: «Яз шатлыгы», «Төш», «Синең өчен», «Атака алдыннан»... Хат яз!

Минем адрес: Хәрәкәттәге армия, ППС номер 1550,
«Отвага» газетасы редакциясе.
Туганнарча сәлам.
Кулыңны ныклап кысам.
Муса Җәлил, 26 май. 1943 ел».

Әлеге шигырьләр шагыйрьнең дүрт томлыгында Сания Мәҗитова исеменә нигезләнеп бирелә.

Шагыйрь сугыш вакытында җиңүне якынайтуда комсомол-яшьләрнең роле турында поэма язганда, аның төп герое итеп, Санияне күздә тота. Кызганыч ки, аның бу нияте тормышка ашмый кала.

Сания апа сугыштан соң хәрби кешегә кияүгә чыгып, аның белән бәхетле тормыш кичерә. Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын, соңыннан Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлый. Эшеннән аерылмыйча медицина институтында укырга да җай таба. Табиблык аны эшләү өчен түгел, ә тормышта кирәк булуы белән кызыксындыра. Чөнки табибларның ялгыш диагноз куеп, дөрес дәва бирмәүләре аркасында ике апасы – Мәхмүдә белән Сәҗидә яшь кенә килеш вафат булалар. Берәр җире авырта башласа, танышлары, туганнары да аңардан киңәш сорыйлар иде. Ә үзен ул гомер буена дәвалады, үзе әйтмешли, «чирләре белән хезмәттәшлек килешүе төзеде».

– Миндә унбер төрле хроник авыру бар, – ди иде ул. – Бу чирләрнең берсе генә дә мине теге дөньяга әллә кайчан җибәрергә җитә. Табибларны да тыңлыйм, үземә дә ярдәм итәм, – дип әйтә иде ул.

Йөрәгендә ревматизм булгач, табиблар аңа бала тапмаска киңәш бирәләр. Шуңа

күрә ул кияүгә чыгарга бөтенләй дә уйламаган. 26 яшендә бергә эшләгән хезмәттәше Гаяз исемле егет белән таныштыргач та аңа бу турыда яшермичә әйтә. Әмма егет кызга беренче күрүдән үк баштанаяк гашыйк була. Аннан соң, КГБ системасында эшләгән кеше буларак, ул чагындагы булмаган гаепне дә табып, җәза тәгәрмәченә эләккән кешеләрнең балаларының фаҗигале язмышын күргәнгәдерме, аның өчен моның әһәмияте дә булмый.

– Һәр очрашу саен яңа костюм киеп килә иде, – дип искә алды ул танышкан вакытларын. – Бала табарга ярамый миңа, ярый торганны тап, – дип аяк терәп каршы торсам да, тәки ризалатты.

Соңыннан Сания апа белән Гаяз абый Мәхмүдә апасының кызы (Минзәләдә курсларда укыган чагында Муса Җәлил аңа да атап шигырь яза һәм ул шигырь шагыйрьнең дүрт томлыгына кертелгән) Иншәрнең беренче баласы Лилияне тәрбиягә алып үстерделәр. Лилия кияүгә чыккач, гомер буе гаиләсе белән Ленинград шәһәрендә яшәде. Краснодар каласында яшәп ятучы әнисе Иншәрне дә, Сания апаны да әнисе итеп санады ул. Яшь ярымлык чагыннан үзенә сыендырган, укыткан, кеше иткән, кияүгә биргән Сания әнисе янына оныклары белән кунакка кайтып, кулыннан килгәнчә ярдәм итеп яшәде.

Муса Җәлилнең кызы Люция белән телефоннан хәбәрләшеп, аны Сания апа белән очраштырырга тырышсам да, җае чыкмады. Бервакытны җыелып очрашырга да сүз куешкан идек, ул көнне авырып киткән булып чыкты, чәебезне аңардан башка гына эчәргә туры килде. Сания апаның аңа әйтер сүзләре дә бар иде. Чөнки фронттан язган хатларында, үзенең фаҗигале язмышын сизенгәндәй, Муса Җәлил кызы Люция турында да искә алган, Казанга килгән очракта, аның янына керер өчен адресын да язган, «шулай килеп чыкканы өчен анда калган кызым белән улым мине аңларлар микән», дип борчылган.

Аннан соң Люция туганы Альбертның вафат булу кайгысыннан тиз генә айный алмады, бүтән мәшәкатьләр килеп чыкты һәм безнең аралар өзелде.

Гомере буена партия оешмаларында эшләгән Сания апа үзгәреш чорын бик авыр кичерде, кабул итә алмады ул аны. Ул, коммунизмның чынлап та булырына ышанып яшәгән, шуңа хезмәт иткән кеше буларак, моңардан югалып калды. Берәүләрнең череп баюына аптырый, нык ачуы килә: «Нәрсәгә җыялардыр, балалары барыбер кадерен белмәячәк, юкка чыгарып бетерәчәкләр бит!» – дип аптырый, үзен мисалга китерә иде. Вакытында зур фатирлар алу мөмкинлеге үз кулында булса да, Октябрьская урамындагы 16 нчы йортта ике бүлмәле кечкенә хрущевкада гаиләсе белән яшәде. Ул фатирга картайган көннәрендә әтисе дә, Хәят апасы да, каенанасы да сыйды.

Әле ул фатирда зур пианинога да урын табылган. «Дуслар белән җыелып, чәй эчкәндә, Гаяз абыең, пианинода уйнап, җырларга яратты», – дип искә алды ул бәхетле көннәрен.

Идел буендагы җәйге дачалары да кешенекеннән артык түгел, тактадан гына корылган иде. Шуңа да карамастан, үзләре янындагы җиденче завод төтененнән качып, көннәр җылыну белән дачага күчеп, көз көне генә шәһәргә кайталар, ә көзге айларда Гаяз абый белән берәр санаторийга китеп, сәламәтлекләрен ныгыталар иде.

Сания апа, фатирларын зурайтуга караганда, үзләренә бирелгән дәвалану мөмкинлеген өстенрәк күрде. Гаяз абыйдан калгач, ул күп вакытын апасының кызы – чех егетенә кияүгә чыгып, Прагада яшәүче, үзе хөрмәтенә Сания исеме кушылган сеңлесендә, Мәскәүдәге дусларында үткәрде.

Соңгы елларын берүзе генә яшәсә дә, өендә телефоны шылтырап кына торды. Күршеләре дә күңелсезләнергә ирек бирмәде. Бер апасының Казанда яшәүче табиб онығы Алеша да аның янында гел булып, сәламәтлеген кайгыртып, күзәтеп, көн саен

диярлек янына килеп йөрде. Аякларында гангрена куркынычы булганга, елга икешәр тапкыр берәр ай хастаханәләрдә ятып чыгарга туры килә иде. Кирәк чагында ярдәм итәрдәй кешеләрне дә тапты.

Сания апа белән миңа да өч тапкыр «Васильево» санаторийсында булырга туры килде. Шул чакларда кешеләр белән бик тиз аралаша, киң күңелле, оптимист була алуы белән мине таң калдырган иде. Яше олы булуына карамастан, күңеле бер дә картая белми, һаман яшь, уен-көлке ярата, яшьләр белән дә бик тиз уртак тел таба иде ул.

Сания ханым – Муса Җәлилне сугышка озатып калган хатын-кызларның соңгыларының берсе. Аның турында төрле сүзләр йөргән. Имеш, ул Мусаның соңгы мәхәббәте булган. Сания Мәҗитова ул гайбәтләрне кире кага. «Уйлап кара әле, унтугызы да тулмаган саф кызның – район комсомоллары башлыгының – ул зур шагыйрь булса да, гаиләле, ничә балалы һәм үзеннән күпкә өлкән кеше белән ратышуы мөмкинме? Хатларымда, райком отчеты кебек, һәр эшләгән эшем турында тәфсилләп язуымны үтенә иде бит ул. Хәер, үз яшемдә булса да, кечкенә буйлы кешене ярата алмаган булыр идем мин. Шагыйрь буларак хөрмәт күрсәтү – башка хәл. Ә гомумән, мин 24 яшемә хәтле беркемне дә яратмадым. Тик аның салкын окопларда, хатларымны укып, миңа хатлар язуын күз алдыма китерсәм, рәхәтлек хисе кичерәм. Гомумән, бу очрашуны мин бик зур бәхет дип исәплим».

Анысы шулаен шулай, әмма шагыйрь исән булып, яу кырыннан исән-имин әйләнеп кайтса, алар дуслар булырлар, сугыш вакытындагы хәлләрне искә төшерерләр һәм Сания апа шагыйрьне бер генә әсәр язарга илһамландырып калмаган булыр иде.

Сания апа 2010 елның 30 апрелендә 87 яшендә вафат булды. Унтугызы да тулмаган кыз Әгерҗедә сугыш вакытында шактый эшләр башкарган, шуларның берсе артыннан йөреп, Казан шәһәреннән урын-җир, ятарга караватлар алып кайтып, беркем дә кушканны көтеп тормыйча, үз белдеге белән ятимнәр өчен ачтырган йорт хәзер инде балалар санаторийсына әверелгән – анда ел саен йөзләгән бала сәламәтлеген ныгыта.

Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер, диюләре дөрестер. Эшләгәне белән мактанып йөрмәгәнгә, аны әгерҗелеләр исән дип тә белмәгәннәр, гомеренең соңгы елларында гына эзләп табып, хәбәрләшкән, санаторийга аның исеме бирелүен хәбәр иткәннәр иде. Сүзләрендә торганнармы – анысын белмим. Тик Сания апа өчен ул мөһим булмады.

– Сугыш кына була күрмәсен, – дип кабатларга яратты ул. – Илләр генә тыныч булсын.

Гомеренең соңгы ун елында аның сыңар күзе дә томанлы гына күрде, шуңа үзенең яраткан шөгыле – китап укудан мәхрүм булды. Әмма бу турыда якыннарыннан башка кешегә сиздермәде, ялгызы гына урамда да йөрде, үзләренең йортындагы кибеткә ризык алырга да чыкты.

– Илне төрле якка тарткалап, талап, тәки бернәрсәсен калдырмадылар, – дип борчылды ул. – Безнең яшәвебезнең мәгънәсе бар иде, калган буыннар ничек яшәрләр? Халык та бик пассив, чит илдә булса, бездәгедәй җитәкчеләрне бер көн дә тотмаслар иде.

Чит илдә күп булганга, Сания апа андагы вазгыятьне яхшы белә иде.

Шуңа да карамастан, күпме генә чакырсалар да, үзенең кендек каны тамган, этиәнисе, якын туганнары күмелгән җирдән башка яши алмады ул, гайрәте чигеп киткән чакларында да, сагынып кире кайта торган иде.

Берәүләр дөньядан китә, берәүләр килә. Без, геройларны әллә кайсы чорлардан, әллә кайлардан эзләп, янибызда йөргән кешеләргә игътибар итмибез. Югыйсә, аларның күбесе турында бер генә түгел, әллә ничә роман язарлык бит.

Сания апа шундый кешеләрнең берсе иде. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Истә, һаман да истә!

Артистка Вера Минкинаның тууына 100 ел

Татарстан Республикасының (1968) һәм РСФСРның халык артисткасы (1977) Вера Егор кызы Минкина 1918 елның 9 сентябрендә Чистай районының Бахта авылында туа.

1938 елда Казан театр техникумын тәмамлый. Әүвәл Республика татар күчмә театрында, аннары 1952 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли башлый. Әлеге театрда 60 елдан артык хезмәт итә. Ул 93 яшендә 2010 елның 20 сентябрендә Казан шәһәрендә вафат була.

Уйнаган рольләре:

Мостай Кәрим «Кыз урлау» – Уңганбикә; Максим Горький «Дошманнар» – Полина; Кәрим Тинчурин «Зәңгәр шәл» – малай;

Туфан Миңнуллин «Гөргери кияүләре» – Палый; Туфан Миңнуллин «Әлдермештән Әлмәндәр» – Хәмдебану; Фәтхи Бурнаш «Яшь йөрәкләр» – Екатерина; Николай Островский «Җимерелгән бәхет» – Степанида; Туфан Миңнуллин «Моңлы бер җыр» – Ана; Флорид Бүләков «Әбиләргә ни җитми» – Хөлә; Хәй Вахит «Күк капусы ачылса» – Бибиәсма һ.б.

Татар мөгаллиме, җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм нашир Әхмәтһади Максудиның тууына 150 ел

Атаклы Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди (Әхмәдһади Максуди, Һади Максуди, Әхмәт Максуди буларак та билгеле) 1868 елның 28 сентябрендә Казан губернасы Ташсу авылында (хәзерге Биектау районына керә) Низаметдин мулла гаиләсендә туган. Бу гаиләдә татар дөньясының ике олуг шәхесе – Һади һәм Садри Максудилар туып-үскән.

Әхмәтһади Максуди Казанда беренче татар китапханәсен – «Китапханәи исламия»не оештыручы буларак та билгеле.

Әхмәтһади башта үз авылындагы этисе мәдрәсәсендә укый. 1881 елны ул Казанга килә, заманының мәшһүр мәдрәсәләренең берсе булган «Күл буе» яки «Галләмия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм сигез ел дәвамында шунда белем ала. Укып бетергәч, 1890-1892 елларда шунда мөгаллимлек итә. Мәдрәсә, мәгариф системасына җитди үзгәрешләр кертергә кирәклеген аңлап, Һади 1892 елда, татар мәгарифендә чын мәгънәсендә инкыйлаб ясап, татар әлифбасына 6 хәреф кертә һәм «Имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дигән кагыйдәсеннән файдаланып, үзенең «Мөгаллим әүвәл» әлифбасын бастырып чыгара. Әлеге дәреслек 1918 елга кадәр барлыгы 32 басма кичерә, татар балалары өчен генә түгел, ә казакъ, башкорт, кыргыз, үзбәк балаларының да уку китабы булуы белән уникаль күренешкә әйләнә.

Ул 1941 елның 28 июнендә вафат була. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЛМА – татлы җимеш бирә торган агач. Гомумтөрки сүз. Мәхмүд Кашгари сүзлегендә (XI гасыр) – *алымла*. Монгол телендә охшаш сүз – *альмын*. Глазов яклары сөйләшендә кыргый алма агачын *сагалма* диләр. «*Ихтимал, алма агачы Европадан таралгандыр*», – дип яза доктор Р.Әхмәтҗанов.

//Алымла ярымы – ярты алма. Җир алмасы – бәрәңге. *Кытай алмасы* – әфлисун. *Фарсы алмасы* – шәфталу, персик. *Алма коймак* – чокырлы-чокырлы итеп эшләнгән табада пешкән белен. *Күз алмасы. Бит алмасы.*

Ызгыш (җәнҗал) алмасы – яблоко раздора (русча). Борынгы грек мифында аллалар Фетиданы кияүгә биргәндә туйга Эрида дигән җәнҗал алиһәсен чакырмаганнар, дип сөйләнелә. Моңа ачуы чыккан Эрида туй мәҗлесендә утыручы алла һәм алиһәләр янына бер алма тәгәрәтеп җибәргән, имеш. Алмага: «Иң-иң чибәргә», – дип язу язылган була. Шуннан соң мәҗлестә утыручы алиһәләрдән – Гера, Афина һәм Афродита арасында алманың кемгә тиешлеге турында бәхәс купкан. Ахыр чиктә бу бәхәс канкоюлы Троя сугышына сәбәп булган, имеш.

Шигърияттә «алма» – хатын-кыз күкрәге. *Алмалы алъяпкыч* дигәндә, их-

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

тимал, хатын-кыз күкрәге күздә тотылган булыр. Андый алъяпкычның *тирәкле алъяпкыч* дигән атамасы да билгеле. // *Алмалы алъяпкычым әл дә бар сандык төбендә*. Сөйләм теленнән.

Гарәпчә алма – *төффах*.

АЛМАНИЯ – Германия. Гомумән алганда, тарихта *алманнар* герман кавеменнән бер халык булган. Бүгенге татарча басмаларда, төрекләргә ияреп, *нимес* яки *германлы* сүзен алман сүзе белән алмаштыру «процессы китте». Бер караганда, дөрес тә шикелле, чөнки моннан берничә йөз еллар элек руслар нимес (ягъни телсез, тел белми) дип инглизләргә дә әйткәннәр. Ләкин тарихилыкны җуймау өчен, әлбәттә, нимес (татарда гади сөйләмдә – *нимес, нимсә, нимеч/мимеч*) һәм алман сүзләрен бөтенләйгә сызып ташлауның кирәге юк. Әлбәттә, рус теле йогынтысыннан ерак торган элеккерәк чыганакларда алман сүзе актив, әйтик, 1953 елда Мюнхенда яшәгән татар-башкорт интеллигентларының Гаяз Исхакый килү уңаеннан үткәрелгән мәҗлес беркетмәсендә фәкать «алман» атамасы гына кулланылган. Шулай да «герман» сүзе төгәлрәк, шуңа күрә аның потенциалы зуррак шикелле. Шуны да әйтеп китик, 1943 елның апреленнән 1944 елның июленә кадәр Германиядә татар әсирләре тарафыннан Гариф Солтан мөхәррирлегендә нәшер ителгән ике телле журнал «Германча-татарча белешмә» дип атала.

Бүген мәшһүр интернетта «Википедия»нең, *дойч* (нимес) версиясе белән беррәттән, *алман* версиясе дә барлыгын әйтеп китү урынлы булыр. Кыскасы, «алман» сүзе «герман» сүзенә тәңгәл мәгънәле түгел.

«Алман» атамасын төрки «алма» сүзенә бәйләргә тырышу – нигезсез.

Борынгы чыганакларда Алемания/Алмания Көнбатыш Европаны да белдергән.

Алмания атамасы сирәк кенә бүгенге җитди фәнни әдәбиятта да очраштыра. //*Татарстан фәннәр академиясе төзелгәнгә кадәр ТӘҺТИ гуманитар һәм иҗтимагый гыйлемнәр буенча республика координация советын җитәкләде, якын һәм ерак чит илләрнең (шул җөмләдән, Төркия, Финляндия, Венгрия, Алмания, Англия, АКШ һ.б.) академик оешмалары һәм тюркология үзәкләре белән тыгыз иҗади элемтәләр урнаштырды.* Ким Миңнуллин. ■

Мюнхен

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ҺӘМ ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ ӘДӘБИЯТЫ ФОНДЫ

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе – дөньяда үзенә татар телендәге һәм татар төбәкләрен өйрәнүгә караган әдәбият туплау белән шөгыльләнүче бердәнбер җәмәгать китапханәсе. Ул шулай ук милли матбугат басмаларын, республикабыз турындагы документларны барлап, теркәп бара.

Республикада гына түгел, аннан читтә дә татарча һәм башка телләрдә басылып чыккан, Татарстанга һәм татар халкына кагылышлы уникаль документлар, тарихка һәм мәдәнияткә караган төпле хезмәтләр, белешмә әдәбият, статистик материаллар китапханә фондының асыл хәзинәсен тәшкил итә, әлеге басмалар татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү, кулъязмалар һәм сирәк китаплар, вакытлы матбугат бүлекләрендә саклана.

Әлеге фондның иң зур өлеше татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә тупланган. Биредәге татарча документларның күләме – 23268 исемдәге 83934 данә.

Бүлек фондын 1928 елдан 1939 елга кадәр латин шрифтында, ягъни «Яңалиф»тә, 1940 елдан инде кириллица белән басылган, һәрьяклы белем тармакларына караган татарча китаплар, бүтән телләрдән татарчага тәрҗемә ителгән әсәр-хезмәтләр, Татарстан һәм татар халкы турында русча басылган (шул исәптән 1917 елга кадәр) китаплар, татар әдипләренең русча чыккан, шулай ук Татарстанның русча язучы әдипләре иҗат иткән матур әдәбият әсәрләре, Татарика, аудио- һәм видеоязмалар, электрон басмалар тәшкил итә.

XVII-XVIII гасырларда Россиядәге кайбер уку йортларында татар телен өйрәтү һәм телнең үзен гыйльми өйрәнү башлана. Бу гамәлләр Казан университетының Шәрык бүлеме галимнәре башкарган тикшеренү һәм хезмәтләрдә дәвам иттерелә. Китапханәнең татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге Казан университетында эшләгән, татар телен өйрәнүгә зур өлеш керткән күренекле галимнәрнең хезмәтләрен саклый: М.А.Казембекның «Төрек-татар теленең гомуми грамматикасы» (1846), М.Мәхмүдовның «Татар телен өйрәнүчеләр өчен гамәли кулланма»сы (1857), А.Троянский язган «Кыскача татар теле грамматикасы»ның төзәтелгән һәм тулыландырылган басмасы (1860).

Татар теле грамматикасы буенча беренче төпле фәнни тикшеренүне башкарган Гыйбад Алпаровның (1888-1936), шулай Җамал Вәлиди, Шиһаб Рамазанов, Вәли Хан-

---

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

гильдин кебек авторларның тел гыйлеменә багышланган хезмәтләре бүген дә укучылар тарафыннан бик еш сорала.

Өч томнан торган, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты әзерләгән «Татар теле грамматикасы» академик басмасы 1992-1993 елларда татар һәм рус телләрендә дөнья күрде.

Милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге актив гамәлләр, мәдәниятара багланышларның үсеше элек-электән үк татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр төзүгә һәм бастырып чыгаруга нигез булган. Бүлек фондында шундый басмаларның аеруча кызыклылары һәм әһәмиятлеләре дә саклана: тюрколог, этнограф Н.Катанов тарафыннан төзелгән «Ф.Кәримев дәреслегенең 1 нче кисәге күләмендә, гарәп һәм рус



транскрипцияләрендә бирелгән кыскача татарча-русча сүзлек» (1912), Ваһапов төзегән дәреслек-үзөйрәткеч (16 нчы басма, 1907), С.Рахманкуловның шундый ук хезмәте (1912), 4 томлы «Русча-татарча сүзлек» (1955-1959), Мәскәүдә нәшер ителгән, 38000гә якын сүзне туплаган «Татарча-русча сүзлек» (1966), «Русча-татарча сүзлек» (1971), төрле фән тармакларына караган махсус терминологик сүзлекләр. 1977-1981 елларда – 3 томлы, 2005 елда бер томлы булып дөнья күргән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» – фундаменталь басмалар рәтендә. Сүзлекләр татар теленең фольклорда, матур әдәбиятта, фәнни хезмәтләрдә, фәнни-популяр һәм публицистик әсәрләрдә, XIX-XX гасырлар вакытлы матбугатында теркәлгән гаҗәеп бай сүзлек һәм фразеологик составын чагылдыра.

1999 елда – рус һәм 2002 елда татар телендә «Татар энциклопедик сүзлеге» басылып

чыгу, соңгы елларда татар телендә – 6 том һәм рус телендә 6 том «Татар энциклопедиясе» нәшер ителү – бик мөһим мәдәни һәм фәнни вакыйгалар.

Татарстанның халык язучысы, фольклорчы-галим, күп фәнни хезмәтләр авторы Нәкый Исәнбәт халык авыз иҗатын җыеп өйрәнүгә һәм системага салуга бөтен гомерен багышлый. Аның тарафыннан төзелгән, 3 томнан торган «Татар халык мәкальләре» (1959-1967), «Татар халык табышмаклары» (1970), «Балалар фольклоры һәм җырлысүзле йөз төрле уен» (1984), «Татар халык иҗаты» антологиясе (1951), 2 томлык «Татар теленең фразеологик сүзлеге» (1989-1990) – халкыбызның энҗе-асылташлары кебек кыйммәтле, гасырлардан-гасырларга барачак хәзинәләре. Бүлектә «Татар халык иҗаты» антологиясе (1951), фольклорчы, филология фәннәре докторы Хәмит Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» монографиясе, Алтын Урда тарихының XIV гасыр

ахырларында-XV гасыр башларындагы катлаулы һәм каршылыклы чорын сурәтләгән әсәр – татар халкының тарихи-эпик «Идегәй» дастанының берничә басмасы саклана.

Унике томны тәшкил иткән «Татар халык иҗаты» фәнни җыелмасы (1976-1988) татар халык авыз иҗатының бөтен билгеле жанрларын үз эченә ала. Әлеге хезмәтне русчага тәрҗемә итеп, 15 томда чыгару эше башланды.

Ә.Г.Кәримуллинның «Татар фольклоры. 1612-1981» дип исемләнгән аннотацияле библиографик күрсәткече зур игътибарга лаек. Күрсәткечкә басылып чыккан фольклор әсәрләре һәм татар халык авыз иҗаты жанрларын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр теркәлгән.

Күп гасырлык тарихы булган татар әдәбияты тамырлары белән ерак үткәннәргә тоташа. Урта гасырларда иҗат иткән шагыйрь Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы – Идел буе болгарларының дәүләтле чорыннан килгән әдәби сүзгә һәйкәл булырлык әсәр! 1983 елда ул кириллицада басыла һәм күптөрле фәнни, белешмә аппарат белән баетыла, шулай ук хәзерге татар теленә шигъри яраклаштырыла һәм рус теленә дә сүзгә-сүз тәрҗемәсе бирелә. Соңрак поэманың татар һәм рус телләрендә тагын берничә басмасы затлы бизәлешләр белән чыкты.

Алтын Урда чоры (XIII гасырның икенче яртысы-XV гасырның беренче яртысы) әсәрләре: Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (2003 елгы басма), Сәйф Сараиның «Китабе Гөлестан бит-төрки» (1999); Казан ханлыгы дәвере (XV гасырның икенче яртысы-XVI гасырның беренче яртысы) шагыйрьләренең иҗат җимешләре: Кол Шәрифнең «И күңел, бу дөньядыр...: газәлләр, кыйсса» (1997); Мөхәммәдъярның «Нуры содур: поэмалар, шигырь» (1997, беренче басмасы 1966 елда чыккан), XVIII-XIX гасыр әдипләре Габдерәхим Утыз Имәнинең «Шигырьләр, поэмалар» (1986); Габделҗәббар Кандалыйның «Шигырьләр һәм поэмалар» (1988) китаплары – фондның җәүһәрләре.

XIX гасырның икенче яртысында татар мәгърифәтчелек әдәбияты барлыкка килә, аның үсеше Шиһабеддин Мәрҗани (1818-1889), Хөсәен Фәезханов (1828-1866), Каюм Насыйри (1825-1902) һ.б. исемнәре белән бәйле.

1992 елда дөнья күргән 2 томлы «Татар поэзиясе антологиясе»ндә татар шигъриятенең иң күренекле үрнәкләре бирелгән. Шунысын да әйтергә кирәк, «Антология»нең 1956 елда – татар, 1957 елда рус телендә нәшер ителгән беренче басмалары да фондта бар.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең дөньядагы күп телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләре, классик әдипләр Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташларның үзләре исән чагында басылган китаплары, күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, танылган язучы, исеме һәм иҗаты 70 ел буе тыелуда булган Гаяз Исхакый һәм башкаларның әсәрләре фондта хөрмәтләп һәм кадерләп саклана.

Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә әдәбиятчы галимнәрнең язучылар иҗатына һәм татар әдәбияты үсешенә багышланган китаплары да урын алган. Алты томлы «Татар әдәбияты тарихы» (1984-2001) да кыйммәтле фәнни басма булып санала.

Татар халкының мәшһүр шәхесләре тудырган бай язма мирасны кайтару һәм аларның тормыш юлларын, эшчәнлекләрен яктырту максаты белән соңгы елларда аларга (Шиһабеддин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Фатих Кәрими, Әхмәтгәрәй Хәсәни, Габдрахман Сәгъди, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Муса Бигиев, Кәрим Тинчурин һ.б.), шулай ук татар халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә зур өлеш керткән башка милләт вәкилләренә (Карл Фукс, Михаил Худяков һ.б.) багышлап нәшер ителгән фәнни-биографик, тарихи-документаль басмалар китапханәгә килүчеләр тарафыннан еш сорала.

Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендәге фондның рус телендәге өлешен

25644 исемдәге 62546 данә басма тәшкил итә, алар арасында 1917 елга кадәр Казан матбагаларында басылганнары да шактый.

Туган якны өйрәнүгә караган әдәбият эчтәлеге белән киң кырлы, төбәк тормышының төрле якларын колачлый, аларда Казан һәм Казан губернасы тарихы аеруча җентекле тасвирланган. Шәһәр тарихына багышланган әһәмиятле китаплардан М.Рыбушкинның «Казан шәһәренең кыскача тарихы» (1 нче кисәк, Казан, 1848), «Казан күрсәткече» (Казан, 1840); П.Заринскийның «Борынгы, нигездә, XVI гасырдагы Казан очерклары» (1877); С.Шпилевскийның «Казан губернасындагы борынгы шәһәрләр һәм башка болгар-татар ядкәрләре (Казан, 1877); М.Пинегин төзегән «Казанның үткәне һәм бүгенгесе: шәһәрнең тарихы, истәлекләре һәм хәзерге халәте буенча очерклар» (СПб., 1890) китапларын атарга мөмкин.

Казан университеты профессоры, Казан татарлары мәдәниятен һәм көнкүрешен өйрәнгән К.Фукс китаплары зур кызыксыну уята. Аның бүлектә саклана торган «Казан шәһәре тарихы: рус һәм татар елъязмаларыннан» (5 нче басмасы, Казан, 1914) китабы рус историографиясендә беренче тапкыр татар чыганакларын куллануы белән игътибарга лаек.

Китапханә үзендә «Казан һәм казанлылар» (ике кисәктә, Казан, 1906-1907) җыентыгы, тарихчы һәм төбәк тарихын өйрәнүче, нашир Н.Агафоновның «Казан тарихыннан» (Казан, 1906) репринт басмасы, кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «Ике борынгы кульъязма нигезендә XVI гасырның билгесез язучысы төзегән Казан ханлыгы тарихы» (СПб., 1791), тарихчы, географ, икътисадчы, Петербург Фәннәр академиясенең беренче мөхбир әгъзасы П.Рычковның «Борынгы һәм урта гасырлар заманы Казан тарихы тәҗрибәсе» (СПб, 1767) китаплары саклану белән дә горурлана.

Казан уку-укыту округына, аерым алганда, Казан университетына, Казан рухани академиясенә, училище һәм гимназияләргә багышланган, гомумән, төбәктәге мәгариф эше үсешенә караган китаплар, төрле гыйльми җәмгыятьләр чыгарган «Казан Император университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» (1878-1929), «Татарны өйрәнү гыйльми җәмгыяте хәбәрчесе» (1923-1929), «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте хезмәтләре» (1930) кебек басмалар белән кызыксыну хәзер дә кимеми.

Татар музыкасы, рәсем сәнгате, архитектурасы, гамәли-кулланма һәм бию сәнгате турындагы китаплар да бик кадерләп саклана. Алар арасында П.Дульскийның рус һәм татар рәсем, бизәү, архитектура сәнгатьләрен тасвирлаган басмалары («Казан тарихы истәлекләре», Казан, 1914; «Казан татарлары сәнгате», Мәскәү, 1925 һ.б.); Ф.Вәлиевнең татар орнаменты, татар һәм Идел буе болгар рәсем сәнгате һәм архитектурасы өлкәсендәге төпле академик тикшеренү материаллары; нәфис сәнгатьнең төрле юнәлешләре буенча монографияләр һәм күмәк хезмәтләр һ.б. бар.

Китапханәгә килүчеләр киң хронологик кысаларда – борынгыдан, урта гасырлардан хәзерге чорга кадәр – тарихның төрле фәнни тармакларына: чыганакчылыкка һәм историографиягә, археологиягә, шул исәптән эпиграфикага һәм нумизматикага, этнографиягә, антропологиягә караган бик күп китаплар белән таныша ала.

Казан шәһәренең 1000 еллыгына багышлап чыгарылган фәнни хезмәтләр, материаллар һәм документлар җыентыклары, альбомнар, соңгы дистә елда нәшер ителгән 7 томлы «Татар тарихы», «Tartarika: атлас» (2005), «Тартария атласы: Евроазия иске карталарда» (2007), «Тартарика: этнография» (2008), «Татарстан мәдәнияте җәүһәрләре» (2004), 6 томлык «Татар энциклопедиясе» китапханә киштәләрендә лаеклы урын алды.

Дәвамы бар ■

«МУЛЛА ЧИШМӘСЕ»

26 июль көнне Арча районының Кушлавыч авылында «Таттелеком» АҖ генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин һәм аның егетләре тарафыннан төзекләндерелгән «Мулла чишмәсе»н ачу тантанасы булды. Әлеге чара «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасының районда узган «Арча төбәгеннән чыккан язучыларның әсәрләрендә чагылдырылган йола һәм гореф-гадәтләрнең бүгенге көнкүрештә кулланылышы» дигән күчмә утырышына туры килде. Игътибарыгызга шунда катнашучыларның берничә чыгышын тәкъдим итәбез.

Әсфәндияр Бикчәнтәев,
Кушлавыч авылының имам-хатыйбы:
«ТУКАЙ МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ РУХЫН ТАСВИРЛАГАН»

– «Мулла чишмәсе» бизәлгән, каралган урын гына түгел, ә чын мәгънәсендә сәнгать үрнәге. Әлеге эшне башкарган кешеләргә Аллаһы Тәгалә хәерле гомер биреп, аларга дөнья вә ахирәт мәртәбәләренә ирешергә насыйп итсен. Элек туристларны, килгән кунакларны, Кушлавычны бик күрсәтмичә, Кырлайга гына алып бара торганнар иде. Соңгы елларда районыбызда мәдәният йортлары, музей, китапханә һәм мәчетләргә караш тамырдан үзгәрде. Төзекләндерү эшләре дә күп башкарылды. Ниһаять, чират чишмәгә дә килеп җитте. Бәлки бездән үрнәк алып, үз төбәгенә кайтып та мондый изге эшне башкарырга теләүчеләр булыр. Татар халкы гомергә менә шулай бүгенге кебек дус-тату яшәсен иде, йа Раббым! Бөек Тукаебызның язганнарын укып хозурланабыз. Тукай һәр шигырендә үз хәлен генә түгел, ә милләтебезнең хәл-әхвәлен, аның рухын, борчуларын тасвирлаган.

Рөстәм Гомәров,
«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры урынбасары:
«ЧИШМӘЛӘР ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ҺӘЙКӘЛЕНӘ ӘЙЛӘНСЕН!»

– Кушлавыч – татар халкы өчен данлыклы авыл. Беренчедән, ул – бөек шагыйребез Габдулла Тукайның киндек каны тамган җир. Икенчедән, әти-әнисе, әби-бабалары яшәгән авыл. Генераль директорыбыз Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин – татар халкы өчен бик күп эшләр башкарган шәхес. Аның ярдәме белән Иске Казан, Гани Сафиуллин, Мәрҗани музейлары булдырылды, зиратлар сакланып калды. Тәртипкә китерелгән чишмәләрнең генә дә саны егермедән артык. Бу елның апрель аенда «Таттелеком» АҖнең иҗат төркеме – Лотфулла Шәфигуллин һәм аның ярдәмчесе Рөстәм Зәкуанов, бөек шагыйребез исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булганнан соң: «Бу премиянең акча өлешен Габдулла Тукай исеме белән бәйле изге урыннарны төзекләндерүгә тотачакбыз», – дип әйткәннәр иде. Җитәкчебез үз сүзендә торды. Менә күрәсез: алдыгызда чишмә, ә аңа яңа гына салынган басма-күпер аша чыгып килдегез. Тимер киртә белән әйләндереп алынган Кушлавыч мәчете нигезе яныннан да уздыгыз. Болар барысы да – Лотфулла Нурислам улының шәхси акчаларына, аның премиясенә һәм кардәш, дус-ишләре ярдәме белән башкарылган эшләр. Без Арча җирендә аның белән эшләвебезгә горурланабыз. Аңа чын йөрәктән олы рәхмәтебезне белдерәбез. Лотфулла Нурислам улының хыялы шул: «Бу чишмәләр татар халкының һәйкәленә әйләнсен иде!» Әлеге чишмә суыннан елга-диңгезләр хасил булган кебек, татар халкы да гел артып торсын. Бөтен дөньяда яшәүче милләттәшләребез шушы урынга даими килеп, биредә дога кылсын да, Габдулла Тукайга йөрәк түрендәге рәхмәтләрен әйтеп, аның шигырьләрен күңелдән укый торган булсыннар иде. Шушы күпер аша чыгып, бирегә килгән яшь буын да бу чишмәнең изге урын икәнен белсен!

Безнең мирас №9 сентябрь 2018

Кадрия Идрисова,
«Ак калфак» бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының рәисе:
«ЧИШМӘЛӘР АВЫЛГА КАБАТ ЯШӘҮ КУӘТЕН КАЙТАРАЧАК»

– Без бүген газиз Тукаебызга гомер биргән җирдә басып торабыз. Беренче адым – чишмә буена килүебез. Аның «Мулла чишмәсе» дип төзекләндерелүе безнең дә җаннарыбызга дәва. Һәр татарның теләге – Тукай туган җиргә килү, Тукай туган җирне күрү, Тукайлы халык белән аралашу. Без, «Ак калфак» бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җыены әгъзалары бүген бу теләгебезгә ирештек. Лотфулла Нурислам улының командасына, бу чишмәгә кабат яшәү яме, яшәү дәрте, аңа яшәү куәте бирүчеләргә, без – «Ак калфак»лылар һәм Бөтендөнья татар конгрессы бик тә рәхмәтле. Чишмәләр авылга яшәү куәтен кабат кайтарачак. Яшәү көче – чишмәләрдә. Үзебезнең хатын-кызларыбызга еш әйтәм: кая гына барсагыз да – туган авылларыгызда булсынмы яки башка җирдәме, чишмәләрне барларга, аларны чистартырга, төзекләндерергә бурычлысыз. Һәр җирдә чишмәләрне карау эшенә кабат-кабат тотынырга кирәк. Бүгенге вакыйга алда кылыначак саваплы эшләребезгә этәргеч булсын иде. Арчалыларга рәхмәт! Үзегезнең дәртегез, бетмәс көч-куәтегез белән безне монда тартып китердегез. Бердәм яшик! Татар аналары булып калыйк һәм милләт балалары үстерик! Бу – татар хатын-кызларына Аллаһы Тәгалә тарафыннан тапшырылган изге бурыч. ■

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

«КЫЗЫЛ БОРЧАКЛЫ» МАТУР КИЕЗ ИТЕКЛӘР

Кукмарада киез итек эше белән шөгыльләнүчеләрне бу хезмәткә алынучы башка төбәк эшмәкәрләреннән аерып торган бер өстенлек бар, ул да булса, сыйфатка, бизәлешкә аеруча әһәмият бирү.

Революциягә кадәр Кукмара фабрикаларында ак киез итекләрне, гадәттә, «кызыл борчаклы» бизәкләр белән бизәп басканнар. Ул итекләр бик кыйммәт торган һәм аларны бәйрәмнәр вакытында бай кешеләр генә киеп йөргән. Кайбер төбәкләрдә Кукмара итекләрен «кукмараныкылар» яки «кухмараныкылар», дип йөрткәннәр. Киез итек куныччлары бизәкле булганнарын исә, фабрикант Комаров хөрмәтенә, «комаровныкылар» дип атаганнар. Чигүчеләр, әлбәттә, татар хатын-кызлары булган. Алар төрле бизәкләрне, вак-вак итеп, бер чәнчемләп кулдан эшләп эрләгән йонны кызылга буяганнар. XX гасыр башларында чиккән бизәкләрне йон белән тегү дип йөрткәннәр.

Кукмарадагы барлык фабрикаларда да кукар киез итекләрен дә басканнар. Кукар атамасы Вятка (Нократ) губернасындагы Кукарка бистәсе исеменнән алынган. Әүвәл

М.В.Боскин. «Ярминкәдә».
Бабайның аякларында «кызыл борчаклы» Кукмара киез итекләре!

итекләрне шунда эшкәрткәннәр. Хәзерге вакытта Кукарка Киров өлкәсенә карый. Бер район Родыгино исемен йөртә.

Кукмара итекләренең уңыш казануы өч сәбәпкә бәйле: чыдамлы, чиста эшләнгән, яхшы басылган. Әгәр дә кайсы да булса фабрикантның киез эшләнмәләре (каталары) нинди дә булса күргәзмәдә зур бәя алса, әлбәттә, итекләрнең дә бәясе бермәбер күтәрелгән.

Кукмара итекләре Россиянең бик күп төбәкләрендәге ярминкәләрдә, аеруча Мәкәрҗә ярмикәсендә күпләп сатылган. Сату-алуны исәпкә алып барганнар. Шундый бер исәпкә алу язмасында (1898) мондый мәгълүмат бар: «Иң югары сортлы итекләрне Казан губернасыннан – Мамадыш өязендәге **Кукмара** авылыннан китереп саталар. Ул итекләр ак йоннан тагы да ап-ак итеп эшләнгән. 30 мең пар итек алып килеп, аны 60 меңгә 4 сатучы сата».

1908 елда Кукмара сатучылары Мәкәрҗә ярминкәсендә 300 меңлек товар сата.

Революциягә кадәр эшләнгән Кукмара киез итекләре. Кукмара төбәкне өйрәнү музее коллекциясеннән.

«У нас поезжаные все не бедные, на всех *валенки кукморские*, тулупчики боярския, шапочки бобровыя, перчаточки козлыя, шарфики вязаны, головки примазаны, на поле выезжали, коней установляли, а меня, дружку, вперёд посылали, спросит и расспросит и чего для нас попросить».

В.Крупин. Вятская тетрадь. М.1987, с.261.

«Антон Яковлевич надел плисовые шаровары, красную, вышитую женой рубаху, перепоясался зеленым поясом с кистями, обул *кухмарские расписные валенки*, которые очень берёг и выходил в них только по большим праздникам».

А.Кобелев. От зари до зари. Оса, 1993, с.45.



«Бабам итекләре»

ФОТОХАТИРӘ

Кукмара киез-киез итек комбинатының элекке генераль директоры Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин



Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев комбинат продукциясе белән. 2016 ел

Комбинат территориясенең бүгенге күренеше

Легендар хоккейчы В.А.Третьяк белән очрашу

Яшь модельерлар

Язманы ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

АВГУСТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru, tatar-congress.org/ru сайтларында

● 1 август көнне Татарстан Республикасы Президенты «Бөтендөнья татар конгрессы» төбәкара иҗтимагый оешмасы Башкарма комитеты рәисе Ринат Зиннур улы Закировны «Дуслык» ордены белән бүләкләү турындагы Указга кул куйды.

● 1-5 август көннәрендә Казан шәһәрендә VIII Бөтендөнья татар яшьләре форумы узды. Чарада 30 чит илдән, Россиянең 60 төбәгеннән һәм Татарстан районнарыннан барлыгы 1000 делегат катнашты.

● 4 август көнне Арча шәһәрендә Халыкара «Татар кызы-2018» бәйгесе финалчылары билгеле булды. Алар – Алина Нигъмәтуллина (Ленинград өлкәсе), Зиләрә Кәримова (Литва), Гүзәл Габдрахманова (Татарстан), Адилә Зәбирова (Мәскәү), Ризидә Мигъранова (Чиләбе), Энҗе Бәйрәмова (Австрия), Илнара Надыйрова (Оренбург), Диләрә Гыйльметдинова (Удмуртия), Диләрә Кәримова (Ульяновск), Әлмирә Таҗетдинова (Свердловск), Динә Габдрахманова (Казакъстан), Зәринә Шаһиәхмәтова (Красноярск).

● 3-5 августта Тубыл шәһәрендә «Наследие» өлкә төбәкара иҗтимагый оешмасы җитәкчелегендә, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар Конгрессы, Тубыл шәһәр хакимияте, Шәһәр Думасы, Шәһәр иҗтимагый палатасы һәм эшмәкәр Дамир Ибраһимов ярдәме белән, «Искер җыены» халыкара фестивале утте.

● 5 август көнне Әстерхан шәһәренең яшь тамашачы театрында «Ялкын» халык ансамбленең 30 еллыгына һәм аның җитәкчесе Галия Ажгильдеевага 70 яшь тулуга багышланган иҗади кичә булып узды.

● 9 августта Буада театр һәм сәнгать әһелләре, драматурглар җыелды. 4 сәхнәдә дүрт экспериментлы тамаша күрсәтелде.

● 15-17 августта Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәре узды. Чараның төп вакыйгасы Мәскәү Халыкара музыка йортында Татарстан сәнгать әһелләренең гала-концерты иде. Анда Мәскәү мэры Сергей Собянин, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев та катнашты.

● 20 август көнне «Безнең мирас» һәм «Казан утлары» журналлары хезмәткәрләре Шанхайдан килгән кытай студентлары – булачак журналистлар һәм аларның мөгаллимнәре белән очрашты. Очрашуда кытай татарлары, Кытай архивларындагы татар тарихи чыганакларын өйрәнү һәм «Безнең мирас» журналы сәхифәләрендә бастыру турында да сүз булды.

● 21 август көнне республикабызның 1424 мәчетендә Корбан гаете намазы укылды. Корбан чалу өчен 70 урын оештырылып, шуларның 18е Казанда эшләде.

● 21 августта Казанда Кремль яры буендагы яңа мәчеттә Корбан бәйрәме уңаеннан беренче намаз укылды.

● Чиләбе өлкәсенең Кунашак районындагы Уелга күле ярында алтын белән йөгертелгән ат җигү әсбаплары һәм хайван сөякләре табылды. Галимнәр бу табышның безнең эрага кадәр X гасырга караганлыгы турында белдерә.

● «Юлбасма» нәшрияты тарафыннан татар ашлары рецептлары тупланган «Хатирә. Татар бәхете рецептлары» дип исемләнгән басма дөнья күрде. Китапның авторы — Алинә Садриева.



Мирасворд



8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: ышна, Әнвәр, Укчы, «Матәм», мал, фәрд, «Кәтәнә», ыру, Бәширов, мән, галл, Ги, айбагыр, күәс, әр, мукшы, мәрә, Фәизов, Кот, Наилә, «Идегәй», намә, ияр.
Өстән аска: Гариф, шикмә, бай, чар, әлбә, «Авылдашлар», инк, «Хонда», кыргыз, ваем, Рио, игәр, Әхмәтов, Мәллә, кур, Әйди, «Ватаным», Үкәк, шәҗәрә, Рим, ун, сырт.

Рәис Габдулла төзеде.

Әхмәд Ясәви мавзолее. Казакъстан Республикасының Төркестан шәһәре

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / сентябрь

915 ел элек (1103)

Бөек төрки суфи-шагыйрь Әхмәд Ясәви (1103-1166) дөньяга килә.

640 ел элек (1378)

Туктамыш хан Идегәй морзаның атасы Балтычак бине җәзалап үтерә.

260 ел элек (1758)

Казанда беренче гимназия ачыла. Урта Идел буенда (университет ачылганчы) ул бердәнбер югары уку йорты булып исәпләнә. Анда төрле елларда Сәгыйть, Исхак һәм Ибраһим Хәлфиннар белем бирә.

240 ел элек (1778)

22 сентябрьдә Оренбург шәһәрендә бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мәхкәмәи шәргыя» (рәсми исеме: «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе») ачыла.

145 ел элек (1873)

Православ тюрколог-миссионер Евфимий Малов җитәкчелегендә махсус «Миссионерский противомусульманский сборник»ның беренчесе Казанда басылып чыга.

105 ел элек (1913)

Петропавел (Кызылъяр) каласында татар һәм казакъ телләрендә атнага өч тапкыр «Ишим даласы» исемле газета чыга башлый.

100 ел элек (1918)

10 сентябрьдә Кызыл Армия Казанны акгвардияче һәм ак чехлардан азат итә.

95 ел элек (1923)

Берлин шәһәрендә татар мөһаҗирләре тарафыннан «Азат шәрекъ» исемле әдәби һәм иҗтимагый-сәяси журналның тәүге саны чыгарыла.

80 ел элек (1938)

13 сентябрьдә артист Ситдыйк Айдаров (1895-1938) вафат була.

75 ел элек (1943)

«Совет әдәбияты» журналының сентябрь-октябрь айлары санында Мирсәй Әмирнең «Мөстәкыйм карт йокысы» исемле хикәясе дөнья күрә.

10 ел элек (2008)

25 сентябрьдә Башкортстанның Дүртөйле районында күренекле татар шагыйре Нажар Нәҗмигә һәйкәл ачыла.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. СЕНТЯБРЬ 2018

Историческое наследие: «Гаухаршад». О.Иванова; «Судьба Казанского ханства». Б.Хамидуллин; «Изречения Ризаэддина Фахреддина»; «Реализация татарского языка». Х.Габидуллин; «Ичкинские татары». Р.Исакаев; «Татарский учёный, открывший Японию». Ф.Байрамова; «Род Ризы казия». Р.Шагиев; «Ахмат бай». Ризаэддин бине Фахреддин.

Наследие эмиграции: «Гаяз Исхаки в Польше». Л.Галиева; «Мусульманский конгресс 1931 года». Г.Исхаки.

Татарский мир: «Учёный Рустам Утямешев». Р.Магдиев.

Тюркский мир: «Чуваши». З.Башири.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Яркая звезда нашей литературы». А.Хасанов.

В глубине памяти: «Отважная Зайнап». И.Салихджан; «Последняя муза поэта». С.Саубанова; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Родник муллы»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. SEPTEMBER 2018

Historic heritage: «Gaukharshad» by O.Ivanova; «The fate of Kazan khanate» by B.Khamidullin; «Sayings of Rizaiddin Fakhreddin»; «The problems of Tatar language's usage» by Kh. Gabidullin; «The Ichken Tatars» by R.Isakaev; «The Tatar scientist having discovered Japan» by F.Bayramova; «The kin of Riza kaziy» by R.Shagiev; «Akhmat bay (richman)» by Rizaiddin bine Fakhreddin.

Emigrants' heritage: «Gayaz Iskhaki in Lagstan» by L.Galieva; «The Muslim congress of 1931» by G.Iskhaki.

Tatar world: «Scientist Rustam Utyameshev».

Turkic world: «The Chuvashes» by Z.Bashiri.

Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov.

Literary heritage: «He/She was a bright star on the literary stage» by A.Khasanov.

In the deepest store of memory: «Braveheart Zaynap» by I.Salikhdjan; «The last muse of the poet» by S.Saubanova; «Still keeping in the memory, still keeping!».

The word is a decoration of language: «The national terms' glossary» by A.Timergalin.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «The well of mullah»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

Лотфулла Габделмән улы Фәттахов

1918 елның 27 сентябрендә Горький өлкәсендәге Анда авылында туа.
Казан сынлы сәнгать училищесын (1939) тәмамлый.
Бөек Ватан сугышы ветераны.
СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1946), СССР Дәүләт премиясе лауреаты (1951), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1958), РСФСРның халык рәссамы (1980).
Казан шәһәрендә яшәп, иҗат итеп, 1981 елның 17 июнендә вафат була.

«Яңа буралар», 1959. Киндер, майлы буяу

«Совет хакимиятенең беренче елларында», 1967.
Киндер, майлы буяу

«Сабан туе», 1957. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Казиле мәчете

Хәсән Туфан фатихасы белән... Илгизәр Фазлуллин
Казиле мәчете. Энҗе Гайнетдинова, Лилия Закирова
Аһәңи ләззәт чыганагы. Риф Гатауллин
Зәй һәм Кенәле елгалары буендагы авыллар. Булат Заһиров
Телебезне кадерләп саклыйк. Рүзәл Юсупов

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
• *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*